# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2023 4 (40)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «2023–2030 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программалары кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т.,
СӘЛАХОВА Ә.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

**БУ САНДА**

**ТЕЛ БЕЛЕМЕ**

*Вәлиева М.З., Миңнуллин Б.К.* Иске татар язма чыганакларында саннарның кулланылышына хас стилистик үзенчәлекләр. . . . . . 7

*Сафина Э.И.* Татар орнитонимнары мисалында зоологик таксоннарны системага салу проблемасына карата . . . . . . . . . 17

*Булатова М.Р.* Балтач һәм нократ сөйләшләрендәге исем сүз төркемнәренә күзәтүләр *(Киров өлкәсенә уздырылган экспедиция материаллары буенча)* . . 23

*Әюпов М.М., Сафина Р.Р.* Рус-татар машина тәрҗемәчесе өчен параллель текстларның мәгълүмат базасын әзерләгәндә очрый торган авырлыклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29

**ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ**

*Шәрипова А.С.* XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар драматургиясендә мифологизм һәм символизм *(М. Гыйләҗев иҗаты мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 35

*Габидуллина Ф.И.* М. Фәйзуллинаның фәнни эшчәнлегендә Муса Җәлил иҗаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42

*Бәдретдинов Р.Ф.* Язучы Афзал Таһировның тормыш һәм иҗат юлына күзәтү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49

**ХАЛЫК ИҖАТЫ**

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Татар эпос-дастаны: төп үзенчәлекләре, бүгенге торышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57

*Җәүһәрова Ф.Х.* Татар халык йола иҗатында яшәү һәм үлем берлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67

**ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ**

*Гайнанова М.Р.* Садри Максуди һәм I Төрек тарих конгрессы . . . 80

*Сәлахова Э.К.* Тәтеш өязе татар авыллары мәктәп-мәдрәсәләре тарихыннан (XIX гасыр уртасы – XX гасыр башы) . . . . . . . . . 90

**МИЛЛИ МӘГАРИФ**

*Гыйльмуллин Р.А., Хәкимов Б.Э., Шәехов М.Р.* Гамәли семиотика институтының заманча лингвистик ресурсларын укытуда куллану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102

**СӘНГАТЬ**

*Улемнова О.Л.* Алабугада III биеннале нәтиҗәләре . . . . . . . . 107

*Кириллова Н.М.* Илһамчысы – тормыш *(сынчы Л.А. Зиминаның (1933–2018) тууына 90 ел тулу уңаеннан)* . . . . . . . . . . . . . . 114

**АРХЕОГРАФИЯ**

*Гәрәева Н.Г.* Казан коллекцияләрендә Урта Азиядә күчерелгән кульязма Коръәннәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127

**ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР**

*Гали Рәхим.* «Дим буенда» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Кадирова Э.Х.* Фәнгә багышланган гомер *(тел галиме Илида Басыйр кызы Бәшированың юбилее уңаеннан)* . . . . . . . 142

*Шәрипов Ә.М.* Тюрколог-галим Марсель Бакировка 90 яшь . . . 150

*Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М.* Татарстан галимнәренең фәнни-методик мирасы: Сәгадәт Мөгаллим улы Ибраһимов *(галим-методистның тууына 95 ел)* . . . . . . . . . . . . . . . . 157

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Яхин Ф.З.* Китап күзәтү: татар мәдәнияте һәм дастаннар (Л.Х. Мөхәммәтҗанованың «Эпическая культура татар: дастаны» китабына бәяләмә) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

## В НОМЕРЕ


### ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Валиева М.З., Миннуллин Б.К.* Стилистические особенности употребления имён числительных в старотатарских письменных источниках . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

*Сафина Э.И.* О проблеме систематизации зоологических таксонов на примере татарских орнитонимов . . . . . . . . . . . . 17

*Булатова М.Р.* Именные части речи балтасинского и нукратского говоров татарского языка *(по материалам экспедиции в Кировскую область)* . . . . . . . . . 23

*Аюпов М.М., Сафина Р.Р.* Проблемы, встречающиеся при подготовке информационной базы параллельных текстов для русско-татарского машинного переводчика . . . . . . . . . . . 29

### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Шарипова А.С.* Мифологизация и символизация в драматургии конца XX – начала XXI века *(на примере творчества М. Гилязова)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35

*Габидуллина Ф.И.* Творчество Мусы Джалиля в научной деятельности М. Файзуллиной . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42

*Бадретдинов Р.Ф.* Жизненный и творческий путь татарского писателя Афзала Тагирова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49

### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос-дастан: основные особенности, сегодняшнее состояние . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57

*Завгарова Ф.Х.* Единство жизни и смерти в похоронно-поминальной обрядности татар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67

### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Гайнанова М.Р.* Садри Максуди и I Турецкий исторический конгресс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80

*Салахова Э.К.* Развитие образовательной системы на территории Тетюшского уезда Казанской губернии *(середина XIX – начало XX века)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90

### НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Гильмуллин Р.А., Хакимов Б.Э., Шаехов М.Р.* Применение в образовательном процессе лингвистических ресурсов Института прикладной семиотики АН РТ . . . . . . . . . . . . 102

### ИСКУССТВО

*Улемнова О.Л.* III Елабужская биеннале уникального рисунка: предпосылки и итоги . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107

*Кириллова Н.М.* Источник вдохновения – жизнь *(к 90-летию со дня рождения скульптора Л.А. Зиминой (1933–2018))* . . . . . 114

**АРХЕОГРАФИЯ**

*Гараева Н.Г.* Рукописные списки Корана из Средней Азии в собраниях Казани . . . . . 127

**НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ**

*Гали Рахим.* «Дим буенда» («На берегах Дёмы») . . . . . 138

**ПЕРСОНАЛИИ**

*Кадирова Э.Х.* Жизнь, посвященная науке *(к юбилею языковеда И.Б. Башировой)* . . . . . 142

*Шарипов А.М.* 90 лет ученому-тюркологу Марселю Бакирову . . 150

*Шакурова М.М., Гиниятуллина Л.М.* Научно-методическое наследие татарстанских ученых: Сагадат Мугаллимович Ибрагимов *(к 95-летию со дня рождения ученого-методиста)* . 157

**НОВЫЕ КНИГИ**

*Яхин Ф.З.* Татарская культура и дастаны (рецензия на книгу Л.Х. Мухаметзяновой «Эпическая культура татар: дастаны») . . . . . 162

**НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ**

УДК 811.512.145

***М.З. Вәлиева,***
***Б.К. Миңнуллин***

# ИСКЕ ТАТАР ЯЗМА ЧЫГАНАКЛАРЫНДА САННАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫНА ХАС СТИЛИСТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР

Статья посвящена разработке вопросов функционирования имен числительных в текстах старотатарских письменных памятников XVII–XVIII вв. и в текстах татароязычной арабографической периодической печати начала XX века. Актуальность темы обусловлена необходимостью комплексного изучения стилистических особенностей имён числительных как средств лингвистического создания публицистического стиля, а также особенностей передачи внешнего мира и внутреннего портрета героев, их эмоционально-психологических состояний, которые являются важными элементами интерпретации текстов старотатарских письменных источников XVII–XVIII вв. и татароязычной арабографической периодической печати начала XX века. Используясь в текстах письменных источников татарского языка, имена числительные участвуют в реализации двух основных функций: информационной и эмоционально-экспрессивной.

**Ключевые слова:** старотатарские письменные памятники, татарская периодическая печать, старотатарский письменный литературный язык, язык периодической печати, стилистические особенности, имя числительное.

The article is devoted to the development of issues of the functioning of numerals in the texts of Old Tatar written monuments of the XVII–XVIII centuries and in the texts of the Tatar-language Arabographic periodicals of the early twentieth century. The relevance of the topic is due to the need for a comprehensive study of the stylistic features of the names of numerals as a means of linguistic creation of a journalistic style, as well as the peculiarities of transmitting the external world and the inner portrait of the characters, their emotional and psychological states. They are important elements of the interpretation of texts of Old Tatar written sources of the XVII–XVIII centuries and Tatar-language Arabographic periodicals of the early twentieth century. Being used in the texts of written sources of the Tatar language, the names of numerals participate in the implementation of two main functions: informational and emotionally expressive.

**Keywords:** the Old Tatar written monuments, the Tatar periodical press, the old Tatar written literary language, the language of the periodical press, stylistic features, the numeral.

Сан – микъдар төшенчәсен, предметларның санын, данә исәбен белдереп килә торган мөстәкыйль сүз төркеме [Татар грамматикасы, 2002, б. 74]. Саннар морфологик категория буларак телдә мөһим һәм кирәкле сүз төркемнәренең берсе булып саналса да, аларның стилистик мөмкинлекләре шактый чикләнгән. Әдәби стильгә караган

текстларда саннар чагыштырмача сирәк кулланыла, шул ук вакытта фәнни, иҗтимагый-публицистик стильләрдә саннарга зур игътибар бирелә. Бу аңлашыла да, чөнки әлеге стильләргә төгәллек, актуальлек, рәсмилек, документальлек һ.б. шундый таләпләр хас. Публицистик стильдә шуларга мәгълүматның укучыга тәэсир итәрлек дәрәҗәдә эмоциональ-экспрессив, үткен булуы һәм тиз арада җиткерелергә тиешлеге өстәлә. Күп кенә очракларда әлеге таләпләрне саннардан башка тормышка ашыру мөмкин түгел. Шуларны күздә тотып, әлеге мәкаләдә саннарның кулланылышына хас стилистик үзенчәлекләрне публицистик стильдә иҗат ителгән иске татар язма истәлекләре нигезендә яктырту максат итеп куелды. Мәгълүм булганча, тел күренешләренә бәйле үзгәрешләр берничә чорның язма истәлекләрен чагыштырма планда тикшергәндә аеруча ачык күренә. Шуңа да саннарның кулланылышына хас стилистик үзенчәлекләр иҗтимагый-публицистик стильнең формалаша башлавы һәм үсеше тарихында зур әһәмияткә ия булган XVII–XVIII гасырлар язма истәлекләре (Мөслиминең «Тәварихе Болгария», билгесез авторның «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәрләре) һәм XX гасыр башы вакытлы матбугаты («Борһане тәрәккый», «Кояш», «Вакыт» газеталары) нигезендә каралды.

Югарыда искәртелгәнчә, публицистик стильнең татар телендә үсеш ала башлавын галимнәр XVII–XVIII гасырлар белән бәйләп карыйлар. Берничә гасыр дәвамында татар җәмәгатьчелегенең, галимнәренең игътибарын үзенә җәлеп иткән язма истәлекләрдән Мөслиминең «Тәварихе Болгария», билгесез автор тарафыннан иҗат ителгән «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәрләренең тел үзенчәлекләре, аларның халыкка мәгълүмат бирү максатыннан язылуы бу язма чыганакларның публицистик рухка якын стильдә иҗат ителгәнлеген күрсәтә. Әлеге әсәрләрдә тарихи вакыйгалар сурәтләнсә дә, аларның тарихи чыганак буларак карала алмавы, әмма язма истәлекне әдәби-тарихи жанрга кертергә мөмкин булуы узган гасырда ук галимнәр тарафыннан исбатлана [Усманов, 1972, б. 134–156]. М. Әхмәтҗанов Мөслиминең Чыңгыз империясе төзелү, Дәште Кыпчак, Нугай урдасы, Болгар дәүләтләренең тарихын, күренекле ханнарның шәҗәрәләрен, билгеле тарихи шәхесләр, зур шәһәрләрнең исемнәрен, урыннарын яхшы белүен, тирән мәгълүматлы кеше булуын җентекләп яза [Татар әдәбияты тарихы, 2022, б. 401]. Галим шулай ук Мөслиминең шул чорда барган тарихи вакыйгаларга булган мөнәсәбәтен «фәкать публицистик жанрда гына белдерү мөмкин булганлыгын» искәртә [Әхмәтҗанов, 2012, б. 65]. М. Әхмәтҗановның бу хактагы фикере И.Б. Бәширова хезмәтләрендә үстерелә, ул «бу рисаләне үз чоры әдәби теленең үзенчәлекле публицистик жанры дип әйтү дөрес булыр», дип искәртә [Бәширова, 2018, б. 64].

Шул рәвешчә, татар теленең публицистик стиленә караган беренче үрнәкләр XVII–XVIII гасырларда дөнья күрсә, татар вакытлы матбугаты киң колач алып үсә башлаган XX гасыр башларында публицистик стиль тәмам формалашып җитә. Татар халкының тор-

мыш-көнкүрешен, тарихын яктыртуда зур роль уйнаган «Борһане тәрәккый», «Кояш», «Вакыт» газеталары моның матур үрнәге булып тора. Әлеге газеталар татарлар күпләп яшәгән Казан, Әстерхан, Оренбург кебек зур шәһәрләрдә милләтне берләштерү, милли үзаңны үстерү, татар халкының иҗтимагый-сәяси карашларын формалаштыру юнәлешендә зур эш алып бара һәм телнең шул чордагы үсешүзгәрешен иң тулы яктырткан төп басмалардан санала [Миннуллин, 2022, с. 4–6].

Әлеге язма истәлекләрнең, вакытлы матбугат үрнәкләренең һәрберсенең тел-стиль үзенчәлекләре арасында саннар зур әһәмияткә, актив кулланылышка ия булулары белән аерылып тора. Галимнәр фикеренчә, саннар сөйләмдә иң элек мәгълүматны объектив һәм дөрес җиткерү өчен хезмәт итә, шулай ук аерым очракларда алар, билгеле бер контекстка бәйле рәвештә, көчле сөйләм экспрессиясе чыганагына да әверелергә мөмкин [Голуб, 2023, с. 244]. Димәк, публицистик стильдә саннар төп ике вазифа башкара дип карый алабыз: мәгълүмат бирү һәм эмоциональ-экспрессив функцияләр.

Саннарның мәгълүмати функциясе дигәндә, нигездә, язмада урын алган саннар аша фактик мәгълүматларны дөрес итеп җиткерү, тасвирлана торган объектның саны-исәбе билгеләнү, вакыйга-күренешләрнең вакыты күрсәтелү күздә тотыла. Чынбарлыкны саннар ярдәмендә чагылдыру, аны бәяләү, мөнәсәбәт белдерү публицистик стильнең бер үзенчәлеге булып тора.

XVII–XVIII гасырларның иске татар язма текстларында әлеге функция, беренче чиратта, ел-көн исәбен күрсәтә торган саннарның стилистик кулланылышында чагылыш таба: *Тарих Һиҗрәте рәсулүллаһи ғаләйссәламнең туғызынчы сәнәсендә Хут йолдызында, Рамазан мөкәррәмәнең туғызынчы көнендә Болғарда ул заманда хан аталмыш кемсәнә Айдар хан ирде* [Мөслими, 1999, б. 25]. *Андин соң тарих мең дә сиксән туғызда ирде, асманда – һаwада бер йақты ләгән йолдыз пәйда булды, көндин йақтылығы артды, тәмам қырық көнгәчә торды* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 1]. *Андин соң тарих мең дә унйидедә ирде, кенәз Митрий йағый булды, тавық йылы ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 91]. *Тарих һиҗрәтнең туғызынчы йөз икенче йылы ирде, эт йылы ирд*е [Мөслими, 1999, б. 47]. Әлеге мисаллардан күренгәнчә, Идел буе татарлары вакытны белдерү, еллар исәбен атау өчен саннарны гына түгел, берәр хайван атамасы белән әйтелә торган 12 еллык циклдан да файдаланганнар. Галимнәр фикеренчә, елларны 12 хайван циклы белән атау Идел буе Болгар дәүләте төзелгәнче үк гуннардан үтеп кергән булырга тиеш [Беркутов, 1987, с. 11]. XVII–XVIII гасырларның иске татар язма истәлекләрендә дә елларны шул традиция нигезендә атау өстенлек итә: *Сәфәрнең йегерме алтынчы көнендә, тарих һиҗрәтнең илле алтынчы йылы ирде, қуй йылында мөбарәк җомға кичәсендә иде* [Мөслими, 1999, б. 11]. *Андин соң тарих мең дә илле өч тә ирде, кенәз Михайла Фидорович хан булды, қуй йылы ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 91]. Әмма шунысын

да онытырга ярамый, куй елы һәм хәмәл елы дигәндә, ике төрле календарь күздә тотылырга мөмкин. Беренчесе «12 еллык хайван циклы» булса, икенчесе – кояш ел хисабына туры килә торган «Хәмәл хисабы» календаре. Соңгы календарьда яңа ел башы Нәүрүзгә, ягъни 12 йолдызлыкның өченчесенә – сарык бәрәне (гарәпчә хәмәл, русча овен) аена – мартка туры килә [Дәүләтшин, 1999, б. 175–176]. Югарыда китерелгән мисалларда да шул хакта сүз бара. Димәк, Мөсliминең «Тәварихе Болгария» әсәрендә «Хәмәл хисабы» календаре күздә тотылса, «Дәфтәре Чыңгызнамә»дә «12 еллык хайван циклы» календаре кулланылган булырга мөмкин. Гомумән, елларны унике еллык цикл белән атау «Дәфтәре Чыңгызнамә» стиленә хас үзенчәлекләрнең берсе булып тора. Автор ел атамаларына тирән мәгънә сала, ел исәбе, аларның атамалары хакында күп мәгълүмат бирә: *Андин соң тарих мең дә йегерме дүртдә ирде, Җанали йагый булды, сычкан йылы ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 91]. *Андин соң йәнә беләсез кем, Чыңгыз хан пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллалаһу галәйһи вә сәлламнең тарихындан соң биш йөз кырык тугызынчыда ирде, туңгыз йылында Зөлкәгдә айында анадин тугды* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 81].

Ел-ай хакында мәгълүмат бирә торган саннар ярдәмендә автор вакыт исәбен генә күрсәтеп калмый, ә укучының игътибарын шул рәвешчә әсәрнең үзәгендә булган персонажларга, күренешләргә җәлеп итә, вакыйгалар агышын анык итеп, билгеле бер эзлелектә күз алдына китерергә ярдәм итә: *Ул көймә берлә бер йыл киттеләр, диңгездән гайрене күрмәделәр* [Мөслими, 1999, б. 21]. *Имде Тумавыл Мәргән егерме йыл ханлык сөрде, андин соң Дуйын Бәйан унтугыз йыл ханлык сөрде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71].

XX гасыр башында ныклы үсеш алган публицистик стильдә, аеруча газета текстларында саннарның кулланылу активлыгы, тематикасы күзгә күренеп арта, стилистик мөмкинлекләре дә киңәя. XX гасыр башы вакытлы матбугатында, ягъни публицистик стильгә караган язмаларда саннар ел-вакыт исәбен белдерү белән генә чикләнми, ә татар халкының тормыш-көнкүреше белән бәйле барлык өлкәләрне дә яктырта башлый. Мәсәлән, түбәндәге мисалларда саннар тарихи вакыйгаларга бәйле рәвештә ел исәбен шактый төгәл күрсәтүгә хезмәт итә: *Бундан башка Әнвәр Паша 1916 нчы йылга йәшләрне чакырмыйча йәнә 8000 мең кеше чыгара аладыр* [«Төрки сугышы», «К.»[1], 1915, № 699]. *1906 нчы йылгы запаснойларны өч көн мидәтендә килеб җитәргә хезмәткә чакырылды* [«Төрк-юнан мөнәсәбәте», «В.»[2], 1913, № 1302]. Илдә барган яңалыклар турында хәбәр иткәндә, авторлар ел исәбен игътибарга алмыйча, ай-көн белән бәйле мәгълүматны гына күрсәтергә мөмкин. Бу очракта санны белдерә торган лексик бермәлекләр ай атамаларын, көн исәбен белдерә торган санал-

[1] «К.» – «Кояш» газетасы.
[2] «В.» – «Вакыт» газетасы.

мыш сүзләр белән янәшә кулланыла*: Беренче июньдә кич Тифлиста Иран консулы извозчик илә қайттығы вакыт...* [«Русия хәбәрләре», «Б.т.»[1], 1907, № 116]. *Андрийановы магазинында ундүртенче октәбрдән башлаб зур дешовка башланды* [«Зур дешовка», «К.», 1913, № 259,]. *8 нче ийүнгә каршы төндә өченче мәхәллә мәсҗетенең йозақларын ватыб, 4–5 данә кийез йурғанлар урлағанлар* [«В.», 1909, № 480, «Әтраф хәбәрләре»]. *«Нордлитс» дигән инглиз көймәсе 24 нче мартда мина белән батырылды* [«Япониядә», «К.», 1915, № 664].

Вакыт көн, ай яки ел исәбе белән чикләп күрсәтелгән очракта вакыйгалар барган вакыт аралыгы хакында тулаем мәгълүмат бирү максатыннан да саннар киң кулланыла: *Прававо̆й государствада халықның балалары дүрт-биш йыллар салдат булыб йөрмәйенчә бәлки бер йыл йәки сигез ай ғына хезмәт итәргә тийеш* [«Прававо̆й государство», «Б.т.», 1906, № 32]. *Унбиш көндән бирле тоташ һичбер йаңғырсыз көн булганы йуқ* [«Минзәлә өязендән», «К.», 1913, № 148].

Саннарның мәгълүмат бирү функциясе XX гасыр башы вакытлы матбугатында вакыйгаларның вакыт исәбен күрсәтү белән генә чикләнми, ә башка төр күренешләрне тасвирлау барышында да җәлеп ителә. Мәсәлән, түбәндәге очракта шәкертләр хакындагы язмада саннар шәкертләргә бәйле мәгълүматны яктырту максатыннан урын ала: *Мужской гимназийаның 5 нче класс шәкертләре берлән шул классның учителе арасында дәғва чыққан вақытда күкерт шикелле қабынырга торған 5, 6, 7, 8 нче класс шәкертләре ... забастовка йасаганлар* [«Хаҗитархан хәбәрләре», «Б.т.», 1906, № 38].

Шул рәвешчә, XX гасыр башы вакытлы матбугатында нинди генә язма булмасын, кыска гына мәкаләдә дә, очерк яисә бәянда да саннар чынбарлык турындагы мәгълүматны төгәл җиткерү, укучыны илдә барган вакыйгалар-яңалыклар белән таныштыру максатыннан киң кулланыла: *Иген игәрлек җир берлән болынлық икесе бергә 4 дисәтинәдән артыграк тийәдер* [«Русиядә никадәр җир бар?», «Б.т.», 1906, № 51]. *Узган ун ай эчендә эчендә Турғай областена 45 мең 791 яңа хохол күчеб килгән* [«Мәхмүд бай Хөсәеневнең иганәсе», «В.», 1910, № 563].

Публицистик язмаларда, аеруча яңалыкларда кыска гына җөмләләр белән күп мәгълүмат бирү максаты куелганлыктан, бер җөмлә эчендә саннар тезелеп китәргә, берничә күренешкә бәйле вакыйгалар тасвирланырга мөмкин. Андый очракларда кабатлаулардан котылу, җөмләне җыйнак итү өчен еш кына саннар янындагы саналмышлар төшеп кала яисә махсус кыскартыла. Мәсәлән, түбәндәге очракта фаҗигалы хәбәр турында мәгълүмат биргәндә, кеше лексик берәмлеген берничә тапкыр кабатламас өчен сан исемләштерелеп, *1190 ы* дигән формада кулланыла: *Талаңган 137 мең семйаның 159 мең санындан 937 кеше үтерелгән, 1190 ы җәрәхәтләнгән* [«Русия хәбәрләре», «Б.т.», 1906, № 38].

---

[1] «Б.т.» – «Борһане тәрәккый» газетасы.

Саннарның экспрессив функцияләре дигәндә, саннарның теге яки бу текст стилендә экспрессивлык тудыру, укучыга эмоциональ тәэсир итү, күренеш-вакыйгаларга серлелек бирү, персонажның образын барлыкка китерү һ.б. максатларда кулланылышы күздә тотыла. XVII–XVIII гасырларның иске татар язма истәлекләрендә бу максатлардан төрки халыкларда аерым символик мәгънәгә ия булган саннар киң кулланыла. Алар текстта үзенә бертөрле стилистик вазифа башкаралар, еш кына стилистик сурәтләү чарасы буларак та җәлеп ителәләр. Мәсәлән, шундый символик саннарның берсе – *кырык: Андин соң тарих мең дә сиксән туғызда ирде, асманда – һавада бер йақты ләгән йолдыз пәйда булды, көндин йақтылығы артды, тәмам қырық көнгәчә торды* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 1]. *Андин соң көймә төзеделәр, қырық кыз – қызықай берлә, күк күгәрчен берлә, алтын қузый берлә, тутый қош берлә, сүнмәс чырағы берлә, Тура тағындин Төн диңгезенә алтын көймәгә салыб йибәрделәр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 70].

Символик саннар арасында җиде санын да очратырга мөмкин. Күренекле тюрколог Ә.Р. Тенишев фикеренчә, җиде саны төрки халыкларда дини күзаллауларда, мәкаль-әйтемнәрдә, халык авыз иҗаты сюжетларында, астрономик терминнарда һ.б.да еш очрый торган гаҗәеп саннарның берсе булып тора [Тенишев, 2006, с. 633]. XVII–XVIII гасырлар иске татар язма истәлекләрендә әлеге сан табигать күренешләрен, ханнар тормышын бәян иткәндә кулланыла. Шул рәвешчә, вакыйгалар агышына серлелек бирелә, укучының игътибары җәлеп итеәлә: *Йәгни бу иқлимдә, йәгни йитенче уралда мәтләғыш-шәмс wә һәм кичә wә көндезнең сәгатьләре мөхтәлифдер* [Мөслими, 1999, б. 19]. *Ачықсаңыз китәрсезләр, бәнем кальгам эчендә йите йыллық азығымыз бардыр див җаваб йазды* [Мөслими, 1999, б. 42].

Дини ышануларда, халык авыз иҗатында ниндидер бер көчкә ия булып саналган *өч* саны да *өч угыл, өч әүлия* һ.б. кебек сүзтезмәләр составында килеп, текстның эмоциональ тәэсир итү көчен арттыра, образлы тасвирлау чарасы булып тора: *Минем өч углым Бүдән Чар, Қағыйн Чар, Салчут халқыны белмәс булдылар, золым, көч қыйлырлар, сүзем дыңламаслар* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 72]. *Буләрдә бер қаенлық арасы чоқырның югарысында менгәндә, сул қабырғасында өч әүлийәи ғыйзамның қабере вардыр* [Мөслими, 1999, б. 33].

Саннар еш кына герой-персонаж, яки язмада тасвирлана торган зат хакында күзаллау булдыру максатыннан да файдаланылырга мөмкин. Мәсәлән, түбәндәге очракта язмада сурәтләнгән геройга хас сыйфатлар саннар ярдәмендә күпертеп-гиперболалаштырылып тасвирлана, әлеге затның гадәти генә булмавына басым ясала: *Диңгез углы димәклә мәшһүр иде вә җитмеш ике төрле телдән белер ирде* [Мөслими, 1999, б. 21]. Тирә-юнь табигатьне, башка күренешләрне сурәтләгәндә дә саннар ярдәмгә килә. Мәсәлән, әлеге мисалда диңгезнең искиткеч зурлыгы, аның башка диңгезләрдән аерылып торуы да сан-

нар белән җиткерелә: *Ул диңгездә йегерме мең атау вардыр* [Мөслими, 1999, б. 22]. Укучыны гадәти чынбарлыктан аерып, вакыйгаларга илаһилык бирергә теләгән очракларда да автор саннарга мөрәҗәгать итә: *Анларның әгдаде йөз сиксән мең мөзәккәр, йөз сиксән мең мөәннәстер* [Мөслими, 1999, б. 24].

XX гасыр башы публицистик стиле саннарның кулланылышы ягыннан аеруча үзенчәлекле. Бу чорда текстның саннарга бай булуы, аларның башка сурәтләү чаралары белән үрелеп баруы авторның максатына, язманың жанрына, күләменә дә бәйле булуы күренә. Яңалыклар тасвирланган кыска текстларда саннар зур әһәмияткә ия булып, мәгълүмати вазифа башкарса, интервьюларда, очеркларда саннарның эмоциональ-экспрессив функциясе беренче урынга чыга. Мәсәлән, вакыйгаларны, аеруча язманың үзәгендә торган геройларның язмышы белән бәйле фаҗигалы күренешләрне тасвирлаганда, геройның яшен искәртү, аның ни дәрәҗәдә яшь, бала булына ишарә итү дә укучыга эмоциональ яктан көчле тәэсир итә, аны вакыйгалар агышы артыннан ияртеп, бәянның эченә алып керә. Түбәндәге мисалда геройның гыйбрәтле язмышы, укучының яшен дә күрсәткәнлектән, аеруча фаҗигалы кабул ителә: *Мин җиде-сикез йәшләрдә булганмын – әнкәйем үлде. Әткәй аңардан биш йыл элек үлгән* [«Гөлчәһрә», «В.», 1910, № 700].

XX гасыр башының вакытлы матбугат басмаларында саннарның мәгълүмати функциясе еш кына аларның эмоциональ-экспрессив вазифасы белән бергә үрелеп бара. Мәсәлән, түбәндәге мисалда гаскәрләр арасындагы аерманың ни дәрәҗәдә зур булуын саннар ярдәмендә биреп, автор укучының хисләренә тәэсир итә. Бу очракта саннарның күренешләрне күпмедер дәрәҗәдә каршы куеп тасвирлауда, ягъни антитеза кебек сурәтләү чарасын барлыкка китерүдә дә катнашуын искәртергә кирәк: *Напалийонның һөҗүм итәчәге әwәлдән мәглүм булса да безнең тарафдан ике җыл эчендә аның 600 мең гаскәренә қаршы барлығы 200 мең гаскәр хәзерләнде* [«Сугыш бәйрәме», «В.», 1912, № 1027].

Гомумән, вакыйга яисә күренешкә генә түгел, ә кешегә бәя биргәндә, аны персонаж буларак ачканда да саннарның стилистик мөмкинлекләре зур. Мәсәлән, алдагы мисалда кеше образын *дүрт айаклы җанвар* образы белән каршы куеп, автор сурәтле тасвирлауга ирешә: *...үземнең дүрт айақлы җанварлардан айырмам фәқәт кеше кийеме кийенеб йөрүдән генә ғыйбарәт идене аңлаб һаман иске тормышқа дошмалана ғына бара идем* [«Үткән гомерем вә караңгылык. Хәзерге хәлем вә шатлык», «Б.т.», 1906, № 51].

Юмор-сатира белән тасвирлана торган күренешләр саннар ярдәмендә тагын да үткенрәк итеп җиткерелә. Мәсәлән, сарыкның бәясен чагыштырып бирү аша автор шактый оста гына итеп муллага үзенең мөнәсәбәтен дә белдереп ала: *70 тийен булуб торган сарық тиресе муллалар бәхетенә генә төсле Ғәйет алдыннан ғына сумның йугары йағына күтәрелде* [«Әтраф хәбәрләре», «К.», 1914, № 549].

Күренешләрне саннар ярдәмендә гиперболалаштырып сурәтләү дә язучы стилен образлы итүдә зур әһәмияткә ия. Мәсәлән, түбәндәге очракта автор вакыйгаларның ни дәрәҗәдә дәһшәтле булуын *мең мәртәбә* тезмәсен кабатлап бирү ярдәмендә тагын да көчәйтеп тасвирлый: *Бу қадәр қотчыққыч дәһшәтле вақыйғаларны күз алдына китереб қуйсақ, мең мәртәбә йазу, мең мәртәбә ишетү дә аз булыр* [«Б.т.», 1907, № 75].

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, XX гасыр башы вакытлы матбугатында, ягъни публицистик стильдә саннарның кулланылышы стилистик яктан шактый үзенчәлекле, күпкырлы булуы белән аерылып тора. Кайбер төр саннарның төрле грамматик формаларда кулланылышы да шушы чорның публицистик стиленә хас үзенчәлекләрнең берсе. Мәсәлән, чама саннарын барлыкка китерүдә һәм лексик, һәм грамматик ысуллар җәлеп ителә, ягъни чама саннарының кулланылышында синонимик вариантлылык чагылыш таба. Биредә ике сан янәшә кулланылып, яки *-ларда/-ләрдә, -лап/-ләп* кебек кушымчалар ялганып, *кадәр, артык* кебек ярдәмлек сүзләр белән ясалган чама саннарын да очратырга мөмкин. Мондый синонимлык авторның язу стиленә бәйле булырга да, кабатлаулардан котылу өчен кулланылырга да мөмкин: *Прававой государствада халықның балалары дүрт биш йыллар салдат булыб йөрмәйенчә бәлки бер йыл йәки сигез ай ғына хезмәт итәргә тийеш* [«Прававой государство», «Б.т.», 1906, № 32]. *10 йәшләрендә вакытта Симферополь гимназийәсенә кергән* [«В.», 1914, № 1598 «Тәрҗеман» газетасы»]. *50 ләб кешеләрне бәйләб бер дә ашықмайынча 3840 рублә ақчасыны алыб чығыб киткәнләр* [«Чиләбедә яңа елны каршы алу кичәсе», «В.», 1914, № 1632]. *1150 қәдәр кеше килеб хәзерге университет эчендә митинглар йасамый торырға қарар бирделәр* [«Русия хәбәрләре», «Б.т.», 1906, № 28]. *1500 дән артык вәкил бар. Мөселманлар 40–50 кешедән ғыйбарәт иде* [«Мәскәү киңәш мәҗлесендә», «В.», 1917, № 2271].

Болардан тыш, XVII–XVIII гасырларның иске татар язма истәлекләрендә дә, XX гасыр башының иҗтимагый-публицистик стилендә дә аеруча киң кулланыла торган саннарның булуын искәртергә кирәк. Мәсәлән, *бер* саны шундыйлардан. Әлеге сан атамасы язма истәлекләрдә предметның төгәл санын, нәрсәнең дә булса күләмен белдерүдән бигрәк, җөмләгә билгелелек төсмере бирү, җөмлә кисәкләрен логик яктан бәйләү яки фикерне гомумиләштереп атау кебек стилистик максатлардан җәлеп ителә: *Ул заманда Мәккәдә хәзрәте Ибраһимның сохофы илә ғамәл қылғучы бер әгләм wap иде, исеме Әйүб иде* [Мөслими, 1999, б. 18]. *Шәһәрдәге һәммә граждан бик уңайсыз бер хәлдә қалды* [«Оренбургта күңелсез вакыйгалар», «В.», 1917, № 2247]. *Бу олуғ суғыш бөтен Йаврупада бер инқыйлаб фикере туғдырган шикелле, киләсе тормышка да үзенең эзләрен бик нық калдырыр шикелле күренә* [«Нимес хатынлары», «К», 1910, № 613]. *Хәзергәчә хөкүмәт вәкилләре мөселманлар иң сәғадәтле бер милләт дийәргә йарата иделәр бит!* [«Г. Думаның 26 февраль җыелышында

Садри әфәнде Максудов нотыгы», «Б.т.», 1911, № 139]. *Шахтадагы мөселман эшчеләр тормышына даир Шәриф әфәнде Камал каләме илә йазылмыш гыйбрәтле бер хикәйәдер* [«В.», 1910, № 700].

Шул рәвешчә, XVII–XVIII гасырларга караган иске татар язма истәлекләрендә саннар, нигездә, мәгълүмат бирү, ел-чор исәбен җиткерү, предмет-күренешләрне тасвирлаганда аларга серлелек, илаһилык төсмерләре өстәү һ.б. максатлардан файдаланыла. XX гасыр башы вакытлы матбугатында саннарның стилистик үзенчәлекләре тагын да киңәя. Алар бу чор язмаларында һәм мәгълүмати, һәм экспрессив функцияләр башкарып, эчтәлекне статистик мәгълүмат белән тулыландыралар, стилистик яктан әсәрнең телен образлы сурәтләүләргә баетып, укучыда кызыксыну уяталар һ.б. Фактик материалдан күренгәнчә, саннар ярдәмендә бирелгән мәгълүмат еш кына иң җитди язманың да стилен җиңел, тиз-шома укылышлы итә, ә укучыда тагын да көчлерәк эмоцияләр уята, ышандыра. Кыскасы, язма текстларда вакыйгалар барышын, вакыт агышын төгәл күрсәтүдә, персонажның эчке сыйфатларын ачуда, теге-яки бу үзенчәлеген образлы тасвирлауда, сөйләмгә эмоциональлек-экспрессивлык бирүдә, әсәрнең телен йөгерек итүдә һәм башка төр стилистик вазифалар башкаруда саннарның әһәмияте искиткеч зур.

**Әдәбият**

Әтраф хәбәрләре // Вакыт. 1909. № 480.

Әтраф хәбәрләре // Кояш. 1914. № 549.

*Әхмәтҗанов М.И.* Татар шәҗәрәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 408 б.

*Бәширова И.Б.* Төрки-татар әдәби теле нәзарияте. Казан, 2018. 315 б.

*Беркутов В.М.* Народный календарь и метрология булгаро-татар. Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. 95 с.

Борһане тәрәккый. 1907. № 75.

Вакыт. 1910. № 700.

Г. Думаның 26 февраль җыелышында Садри әфәнде Максудов нотыгы // Борһане тәрәккый. 1911. № 139.

*Голуб И.Б., Стародубец С.Н.* Стилистика русского языка и культура речи. М.: Юрайт, 2023. 456 с.

Гөлчәһрә // Вакыт. 1910. № 700.

*Дәүләтшин Г.М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 512 б.

Дәфтәре Чыңгызнамә // Мирастан биш сәхифә: XVII–XIX гасырлар әдәбитарихи ядкярләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 37–96.

Зур дешовка // Кояш. 1913. № 259.

Мәскәү киңәш мәҗлесендә // Вакыт. 1917. № 2271.

Мәхмүд бай Хөсәеневнең иганәсе // Вакыт. 1910. № 563.

Минзәлә өязендән // Кояш. 1913. № 148.

*Миннуллин Б.К.* Специфика морфологического оформления текстов татарской периодической печати начала XX века. Казань, 2022. 336 с.

*Мөслими.* Тәварихы Болгария / басмага әзерләүче С. Гыйләҗетдинов. Казан: Иман, 1999. 100 б.

Нимес хатыннары // Кояш. 1910. № 613.

Оренбургта күңелсез вакыйгалар // Вакыт. 1917. № 2247.
Прававой государство // Борһане тәрәккый. 1906. № 32.
Русия хәбәрләре // Борһане тәрәккый. 1906. № 28.
Русия хәбәрләре // Борһане тәрәккый. 1906. № 38.
Русия хәбәрләре // Борһане тәрәккый. 1907. № 116.
Русиядә никадәр җир бар? // Борһане тәрәккый. 1906. № 51.
Сугыш бәйрәме // Вакыт. 1912. № 1027.
Татар әдәбияты тарихы. Т. II. Казан: Татар. кит. нәшр., 2022. 462 б.
Татар грамматикасы. Т. II. М.: ИНСАН, Казан: ФИКЕР, 2002. 448 б.
Тәрҗеман газетасы // Вакыт. 1914. № 1598.
*Тенишев Э.Р.* Символика чисел // Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков, пратюркский язык-основа. М.: Наука, 2006. С. 629–647.
Төрки сугышы // Кояш. 1915. № 699.
Төрк-юнан мөнәсәбәте // Вакыт. 1913. № 1302.
Үткән гомерем вә караңгылык. Хәзерге хәлем вә шатлык // Борһане тәрәккый. 1906. № 51.
*Усманов М.А.* Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. Казань: КГУ, 1972. 318 с.
Хаҗитархан хәбәрләре // Борһане тәрәккый. 1906. № 38.
Чиләбедә яңа елны каршы алу кичәсе // Вакыт. 1914. № 1632.
Япониядә // Кояш. 1915. № 664.

***Вәлиева Миләүшә Зәки кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Миңнуллин Бәхтияр Ким улы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, бүлек мөдире*

УДК 811.512.145

***Э.И. Сафина***

# ТАТАР ОРНИТОНИМНАРЫ МИСАЛЫНДА ЗООЛОГИК ТАКСОННАРНЫ СИСТЕМАГА САЛУ ПРОБЛЕМАСЫНА КАРАТА

В статье на материале татарского языка представлены результаты лингво-этимологического анализа группы орнитонимов с компонентом *күгәрчен* ‘голубь’, используемым для обозначения птиц нескольких семейств и отрядов. В ходе исследования была предложена новая тематическая терминологическая система, которая, по мнению автора, соответствует наиболее поздней – современной – классификации; также были сопоставлены наименования *төн күгәрчене* ‘козодой’, *дала күгәрчене* ‘рябок’, *саджа, дала күгәрчене* ‘саджа’, проведён этимолого-исторический анализ этих лексических единиц. Автор приходит к выводу о том, что орнитоним *күгәрчен* ‘голубь’ с незначительными семантическими и фонетическими изменениями употребляется во многих тюркских языках. В татарском языке птица получила название по цвету своего оперения – от слова *күк* ‘голубой’. Эта же схема номинации использовалась в узбекском, чувашском, башкирском и других языках. Статья является частью серии авторских научных исследований, посвящённых происхождению и историческому функционированию орнитонимов в разных тюркских языках.

**Ключевые слова:** татарский язык, терминология, орнитоним, орнитологическая лексика, этимология.

The article presents the results of linguistic and etymological analysis of a group of ornithonyms with the component kүrərchen ‘pigeon’, used to denote birds of several families and groups. In the course of the study a new thematic terminological system was proposed which in the author’s opinion corresponds to the most recent – modern – classification; also the names of ton kүrərchene ‘goatherd’, dala kүrərchene ‘grouse’, saja, dala kүrərchene ‘saja’ were compared, the etymological and historical analysis of the origin of these lexical units was carried out. The author comes to the conclusion that the ornithonym kүгəpərchen ‘pigeon’ with insignificant semantic and phonetic changes is used in many Turkic languages. In Tatar the bird was named after the color of its plumage – from the word kүk ‘blue’. The same nomination scheme was also used in some other languages. The article is a part of the author’s series of scientific studies devoted to the origin and historical functioning of ornitems in different Turkic languages.

**Keywords:** Tatar language, terminology, ornithonym, ornithological vocabulary, etymology.

Бер атаманың берничә төрле кошны белдерү өчен кулланылуы – орнитонимнар системасында еш очрый торган күренеш. Гадәттә, үз якларында сирәк очраган, әллә ни таныш булмаган кошларны халык шуларга охшаш башка кошларның исемнәре белән атый башлый. Башта сөйләм телендә генә кулланылган атама, фәнни терминологиягә кереп китәрлек уңышлырак варианты табылмаган очракта, әдәби телдә һәм терминнар системасында урын ала.

Башка семьялык кошларының атамалары составында еш кулланыла торган шундый кош исемнәренең берсе – *күгәрчен* орнитонимы. Борынгы төрки *kökürčkän* [Древнетюркский словарь, с. 313] атамасына ук барып тоташа торган *күгәрчен* зоонимы башка төрки телләрдә түбәндәге фонетик вариантларда очрый: аз. *göyərçin*, башк. *күгәрсен,* каз. *көгершін,* карач.-балк. *кёгюрчюн,* кырг. *көгүчкөн*, кумык. *гёгюрчюн*, төрек. *güvercin*, чув. *кăвакарчăн*, к.-калп. *көгершин*, чаг. *köverčken*, алт. *коголјын*, төркм. *гогәрчин* һ. б. Этимологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, атама күгәрченнәрнең төсен белдерә торган *күк* ‘голубой’ тамырыннан ясалган [Севортян, с. 57–58; Сравнительно-историческая..., с. 174; Сафина, 2006, с. 36–37].

Фәндә кабул ителгән систематика буенча, әлеге атама *күгәрченсыманнар* отрядына кергән кошларны белдерергә тиеш. Бу отрядның берничә семьялыкны берләштерә торган зур төркем булуын исәпкә алганда, тикшерелә торган орнитонимның әлеге отряд эчендә генә дә ни дәрәҗәдә киң кулланышлы булуын күз алдына китерү авыр түгел. Шуңа өстәп, әле башка семьялык кошларына да *күгәрчен* компоненты кергән атамалар бирелгән. Мисал өчен, рус телендә *козодой* дип йөртелә торган кош татар теле сүзлекләрендә *төн күгәрчене* дип теркәлгән (*төн күгәрчене* ‘козодой’, *төн күгәрченнәре* ‘козодоевые’, ‘настоящие козодои’, *төн күгәрченесыманнар* ‘козодоеобразные’).

Төрки телләрдәге терминнар белән чагыштыру башка халыкларның *козодой* кошын белдерү өчен бүтән атама сайлавын күрсәтә. Мисал өчен, аз. *keçisağan*, чув. *тур качаки*, каз. *тентекқұс*, кырг. *чегирткечи*, алт. *аларткы*, төр. *çobanaldatan* һ.б. Бары тик башкорт телендәге *төн күгәрсене* ‘козодой’ атамасы гына татар телендәге вариант белән аваздаш.

*Төн* сүзе кушылу әлеге кошларның яшәү рәвешенә бәйле. «*Төн күгәрченесыманнар* – филогенетик яктан ябалаксыманнарга якын торган кошлар отряды. Кыска томшыклы, ләкин авыз кисеме зур һәм күбесенең авыз кырыенда кыллары бар. Эңгер-меңгердә һәм төнлә актив кошлар. Бөҗәкләр белән тукланалар, аларны очканда тоталар. Тавышсыз очалар. Барлыгы 93 төре исәпләнә» [Биологический..., с. 272].

Составында *күгәрчен* орнитонимы булган актив кулланылышлы *дала күгәрчене* атамасының барлыкка килүенә әлеге кошларның семьялык, отряд исемнәрендәге үзгәрешләр йогынты ясавы ихтимал. Билгеле булганча, орнитологларның эзләнү-тикшеренү нәтиҗәләре нигезендә, кайбер кошларның семьялыгы яки отряды үзгәртелергә мөмкин. Кошның башка отряд яисә семьялыкка кертелүе турындагы мәгълүмат иң элек биологларның фәнни хезмәтләрендә һәм алар төзегән белешмәлекләрдә чагыла. Әлеге фәнни материалларга нигезләнеп, орнитоним биологик терминнар сүзлегенә кертелә.

Отряд, семьялык үзгәрү күренешен һәм әлеге үзгәрешләрнең ни рәвешле сүзлекләрдә чагылуын татар телендә *дала күгәрчене* дип йөртелә торган *рябок* кошы мисалында карап үтик. Билгеле булганча, элек әлеге кошлар *рябковые* (*рябки*) семьялыгыныкы дип санала

иде [Азбука природы: Птицы, с. 41]. Төрле елларда төзелгән биология терминнары сүзлекләрендә *рябок* орнитонимы *дала күгәрчене* [Биологический..., с. 505; Азбука природы: Птицы, с. 41], *рябковые (рябки)* семьялыгы – *дала күгәрченнәре* [Азбука природы: Птицы, с. 41] дип бирелгән. Ә 1998 елгы сүзлектә алар *дала күгәрченнәре* 'рябковые' семьялыгына түгел, *күгәрченсыманнар отрядына* карый дип күрсәтелә [Биологический..., с. 505]. Соңрак кабул ителгән систематикада бу кошлар аерым отрядка (*рябкообразные*) керә дип санала. Шулай итеп, отряды – *рябкообразные,* семьялыгы – *рябки,* ә кош – *күгәрчен.* Дөресрәге, *дала күгәрчене* (*чуар күгәрчен* дигән варианты да бар). Тышкы яктан күгәрченнәргә охшаганлыктан, рус телендәге *рябок* дип йөртелә торган кошлар *степные голуби* дип тә теркәлгән. Нәкъ менә шул атама, калькалашып, *дала күгәрченнәре* буларак татар телендә урын алган. Иң мөһиме, *степные голуби* – халык телендәге варианты, фәнни әдәбияттагы атамасы – *рябок.*

Гади формалары халык телендә, ягъни, әдәби телдә кулланылганда бернинди кыенлык, уңайсызлык сизелмәсә дә, бер семьялыкка яки отрядка карый торган кошларны бөтенләй башка отряд-семьялык исемен кулланып атау орнитонимнар системасында эзлексезлек китереп чыгара. Мисал өчен, *рябок* кошына татарча *дала күгәрчене* яки *чуар күгәрчен* дию әлеге кошларның төрләрен күрсәткәндә кыенлык тудыра. Ул очракта *рыжешапочный рябок, желтогорлый рябок, белобрюхий рябок, чернолицый рябок, полосатый рябок, чернобрюхий рябок, ночной рябок, пятнистый рябок* кебек орнитонимнарны татар теленә бер-бер артлы берничә сыйфат кулланып, *җирән бүрекле дала күгәрчене*, *сары муенлы дала күгәрчене*, *ак корсаклы дала күгәрчене* яки *җирән бүрекле чуар күгәрчен*, *сары муенлы чуар күгәрчен*, *ак корсаклы чуар күгәрчен* һ.б. дип тәрҗемә итәргә тиеш булабыз. Һәр ике очракта да *күгәрчен кошлар* семьялыгына керә торган кошларны билгеләү өчен кулланылырга тиешле *күгәрчен* орнитонимыннан файдаланабыз булып чыга. *Рябок*ны *күгәрчен* термины белән атау аны *күгәрченсыман кошларның* бер төре дип уйларга нигез бирә, ыру-төр мөнәсәбәтләрендә буталыш барлыкка китерә. Чөнки *күгәрчен кошлар* семьялыгына керә торган күгәрченнәрнең төрләре бик күп һәм аларның атамалары да сыйфатлар ярдәмендә ясала. Чагыштыру өчен: *көрән күгәрчен* 'голубь бурый', *күгелҗем урман күгәрчене* 'клинтух', *күк күгәрчен* 'голубь сизый', *кыя күгәрчене* 'голубь скалистый' һ. б. Димәк, санап үтелгән мисаллар – күгәрченнәрнең төрләре, ә *дала күгәрчене* (рябок) – бөтенләй башка семьялыкка караган кош булып чыга. Фәнни билгеләнештә төгәлсезлекләрне булдырмау өчен, алга таба *рябок* орнитонимының татар телендәге варианты итеп *болдырык* атамасын куллану дөресрәк булыр. Россия Федерациясе кошлары исемлегендә *саджа* (Syrrhaptes paradoxus) *рябкообразные* (Pterocliformes) отрядына кертеп карала [Коблик, Редькин, Архипов, с. 128]. Әлеге орнитоним 2018 елда дөнья күргән «Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге»ндә төр атамасы составында да, семьялык, отряд исемнәре буларак та теркәлде: *болдырык кошлар*

‘рябко́вые’ – pteroclididae (семьялык), *болдырыксыманнар* ‘рябкообра́зные’ – pterocliformes (отряд) [Сафина, 2018, б. 24–25, 91].

Сүзлекләргә күзәтү ясау да *болдырык кошлар* семьялыгына караган кошларны белдерү өчен татар телендә элек терминнарның эшләнеп бетмәгән булуын күрсәтте. Мисал өчен, әлеге семьялыктагы тагын бер кош – *саҗҗа* (саджа) орнитонимы сүзлекләрдә теркәлмәгән диярлек. «Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек»тә *саджа обыкновенная, копытка* атамасы *дала күгәрчене, саджа* дип тәрҗемә ителгән [Биологический..., с. 508]. *Копытка* орнитонимы *саджа* атамасының синонимы итеп китерелсә дә, әлеге сүзлектә *копытка* термины аерым бирелми. 2001 елда басылган «Русча-татарча, татарча-русча биология терминнары сүзлеге»ндә копытка (саджа) – *дала күгәрчене* [Азбука природы: Птицы, с. 28], саджа – *саджа, дала күгәрчене* [Азбука природы: Птицы, с. 41]. Мисаллардан күренгәнчә, биредә дә төрлелек күзәтелә. Бер урында *дала күгәрчене* дип тәрҗемә ителсә, икенче урында *күгәрчен* үк булып киткән (*саджа тибетская (горняк) – Тибет (тау) күгәрчене* [Азбука природы: Птицы, с. 41]. Татар телендәге башка лексикографик чыганакларда әлеге орнитоним бөтенләй очрамый. Булган сүзлек материаллары рус телендәге *рябок* һәм *саджа* кошларын аерым-аерым белдерү өчен татар телендә терминнар булмавын күрсәтә. Аларның я икесе дә *дала күгәрчене* дип бирелә, я икенчесе өчен, тәрҗемә ителмичә генә, рус орнитонимы кулланыла. Шуларны исәпкә алып, «Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге»нә латин телендә фәнни атамасы *Syrrhaptes paradoxus* булган әлеге кошның татарча варианты *саҗҗа* дип кертелде [Сафина, 2018, б. 53, 99, 109, 143].

Сүз алып барыла торган *саҗҗа* һәм *болдырык* терминнарын генетик яктан карыйк. *Саджа* термины татар теленә рус теленнән кабул ителгән һәм беренче тапкыр 1998 елгы «Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек»тә теркәлгән [Биологический..., с. 508]. Әлеге термин башка телләргә дә кергән: белорус., литв. *sadža*, серб. *саџе*, хорв. *sadže*, укр. *саджа*, словен. *sadža*, словак. *саджа* [Аникин, с. 472]. Галимнәр *саджа* орнитонимының төрле халыкларда төрлечә аталуына игътибар итә. «Кытайлар – *саджа,* кыргызлар – *бульдерюк*, руслар – *степной рябок*, Әстерхан аучылары *копытка* дип йөртә» [Россиков, с. 5190]. Орнитонимның чыганак теле кытай теле дип уйларга нигез бар. Кытай теленең этимологик сүзлеге мәгълүматларына караганда, орнитоним 沙鸡 *shājī* < 沙[的] *shā[de]* «ком төсендәге» һәм 鸡 *jī* «тавык», ягъни «ком төсендәге тавык» дигәнне белдерә [Этимологический словарь китайского…, 1984]. Казакъ телендә терминның *сажы* ‘копытка’ варианты кулланыла. Ул, рус теленнән алынып, казакъ теленә яраклаштырылган яисә кытай теленнән турыдан-туры кабул ителгән булырга мөмкин [Бектаев, с. 393].

*Болдырык* лексемасы татар телендәге чыганаклардан иң элек И. Березгинның «Словарь татарского языка с начертанием слов русскими буквами, с повторением их по-татарски и с переводом на русский язык» сүзлегендә теркәлгән. Анда ул *булдурук* بولدوروق «степной

рябок» [Березгин, с. 39] дип бирелә. Сүзлеккә, татар теле материалларыннан тыш, гомумтөрки сүзләрнең дә күп кертелүен исәпкә алсак, бу аңлашыла да. Димәк, орнитоним Урта Азия һәм Кавказ буйларында яшәүче төрки халыклар телендә актив кулланылган һәм аларның сүзлекләрендә чагылыш тапкан дип уйларга нигез бар [Сафаров, Сафина, с. 178]. Мисал өчен, рус телендәге *рябок*, *саджа* яки *рябчик* сүзләрен белдерү өчен түбәндәге атамалар кулланылган: к.-калп. *булдырық*, каз. *бұлдырық*, кырг. *булдурук*, үзб. *булдуруқ*, аз. *büldürük*.

Татар телендәге чыганакларда *болдырык* сүзе 1972 елгы «Русча-татарча биология терминнары сүзлеге»ндә *саджа* орнитонимының тәрҗемәсе буларак теркәлгән [Русско-татарский…, с. 105]. Алга таба әлеге термин татар теленең терминологик [Сафина, 2018, б. 24–25] һәм аңлатмалы сүзлекләрендә [Татар теленең аңлатмалы..., т. 1, б. 562] урын алган. Зоонимның төрле вариантлары рус теле сөйләшләрендә дә кулланылган. Рус теленең диалектологик һәм этимологик сүзлекләре шул хакта сөйли: *билдерюк* [Словарь русских..., с. 291], *больдурук* [Шипова, с. 86], *булдюрюк* [Аникин, с. 140].

Кыргыз галиме К. Сейдакматов *булдурук* сүзе *чуар* дигән мәгънәне белдергән *булдур* тамырына *-ук* аффиксы кушылудан барлыкка килгән, дигән фикердә [Сейдакматов, с. 67]. Орнитонимнарның күбесе кошларның нинди төстә булуыннан чыгып ясалганлыгын исәпкә алсак, бу фараз дөреслеккә туры килә кебек. Татар теле сөйләшләрендә *болдыру* фигыленең ‘рябить (о воде)’ мәгънәсендә кулланылуы әлеге фикерне тагын бер кат ассызыклый [Татар теленең..., б. 128]. Димәк, атаманың гомуми семантикасы *чуар* дигән мәгънәне белдерә һәм бу, чынлап та, рус телендәге *рябок* атамасына туры килә.

Китерелгән мисаллар орнитонимның билгеле бер кошка туры килү-килмәвен белү өчен күпме эзләнү-тикшеренүләр үткәрергә, чагыштырулар ясарга кирәк икәнлеген күрсәтә.

Шулай итеп, терминнар системасы гел үзгәрештә. Аны хәзерге чорга яраклаштырып яңарту, камилләштерү омтылышы һәрдаим ясалып торырга тиеш. Составында *күгәрчен* орнитонимы булган кош атамаларын системага салырга тырышуның максаты да шул иде. Эзләнүләрдән күренгәнчә, төрки телләр өчен уртак булган *күгәрчен* орнитонимы *күгәрченсыманнар* отрядына карамаган кошларны белдерү өчен дә актив кулланыла. Бу зоонимик терминологиядә эзлексезлеккә китерә. Күгәрчен кошларның төрләре күп булуын (*урман күгәрчене* ‘горлица’, *кыя күгәрчене* ‘голубь скалистый’ һ. б.) күздә тотып, *болдырык кошлар* семьялыгына караган һәм кайбер чыганакларда *дала күгәрчене* буларак теркәлгән зоонимның *болдырык* формасын, *саджа, дала күгәрчене* буларак теркәлгән атаманың *саҗа* вариантын татар теленең орнитологик системасы өчен уңышлырак булыр дип саныйбыз.

**Әдәбият**

Азбука природы: Птицы. Русско-татарский, татарско-русский словарь биологических терминов / сост.: А.Б. Халидов, В.И. Гаранин. Казань: Магариф, 2001. 95 с.

*Аникин А.Е.* Этимологический словарь русских диалектов Сибири. Новосибирск, 2000. 772 с.

*Бектаев К.* Большой казахско-руский, русско-казахский словарь. Алматы, 1995. 703 с.

*Березгин И.П.* Словарь татарского языка с начертанием слов русскими буквами, с повторением их по татарски и с переводом на русский язык. Уральск: Уральская обл. тип., 1914. 253 с.

Биологический русско-татарский толковый словарь: ок. 10000 слов / под ред. д-ра биол. наук Ф. Г. Ситдикова, канд. биол. наук Р.К. Закиева. Казань: Магариф, 1998. 656 с.

Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 676 с.

*Коблик Е.А., Редькин Я.А., Архипов В.Ю.* Список птиц Российской Федерации. М.: Товарищество научных изданий КМК. 2006. 256 с.

*Россиков К.Н.* Саджа Syrrhaptes paradoxus // Русский орнитологический журнал. 2019. Т. 28. № 1845. С. 5186–5197.

Русча-татарча биология терминнары сүзлеге / Төз. О. Ж. Курмаев җитәкчелегендәге коллектив. Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. 168 б.

*Сафаров Р.Т., Сафина Э.И.* Систематизация некоторых названий птиц в татарском языке (на примере семейства рябковых) // Теоретическая и прикладная лингвистика. 2021. 7 (3). С. 175–182.

*Сафина Э.И.* Названия птиц в татарском языке и их лексикографирование. Казань: Дом печати, 2006. 160 с.

*Сафина Э.И.* Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге. Казан: ТӘһСИ, 2018. 184 б.

*Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков: Общетюркские и межтюркские основы на буквы «В», «Г», «Д». М.: Наука, 1978. 349 с.

*Сейдакматов К.* Кыргыз тилинин кыскача этимологиялык сөздүгү. Фрунзе: Илим, 1988. 334 б.

Словарь русских народных говоров. Выпуск 2. Ба – Блазниться. М.; Л.: Наука, 1966. 316 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Лексика. М.: Наука, 1997. 800 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. I том: А–В / Р.Р. Абдуллина, А.М. Сәгыйтова, Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, О.Н. Галимова, А.Ф. Гайнетдинова, Г.Ф. Фәтхетдинова, Ф.И. Таһирова, И.И. Сабитова, Э.И. Сафина, Ф.М. Газизова. Казань, ТӘһСИ, 2015. 712 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

*Фридман Ю. С., Коблик Е. А.* О названиях птиц в дословном переводе с европейских языков // Русский орнитологический журнал. 2013. Т. 22. № 853. С. 573–582.

*Шипова Е. Н.* Словарь тюркизмов в русском языке. Алма-Ата, 1976. 392 с.

Этимологический словарь китайского языка: в 4-х т. Гонконг: Изд-во Шаньу Иньшугуань, 1984. Режим доступа: http://www.sibagu.com/china/pteroclididae.html

Этимологический словарь тюркских языков. Общетюркские и межтюркские основы на буквы «Л», «М», «Н», «П», «С». М.: Восточная литература, 2003. 446 с.

***Сафина Эльвира Ирфат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81'282

***М.Р. Булатова***

# БАЛТАЧ ҺӘМ НОКРАТ СӨЙЛӘШЛӘРЕНДӘГЕ ИСЕМ СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕНӘ КҮЗӘТҮЛӘР
## (Киров өлкәсенә уздырылган экспедиция материаллары буенча)

Статья посвящена характеристике языковых особенностей татар Кировской области. В работе рассматриваются некоторые именные части речи (имя существительное и местоимение) балтасинского и нукратского говоров среднего диалекта татарского языка. Материал подготовлен по результатам комплексной экспедиции, проведённой в 2018 г. Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ по татарским населённым пунктам Кировской области РФ.

**Ключевые слова:** татарский язык, диалектология, средний диалект татарского языка, балтасинский говор, нукратский говор, морфология, комплексная экспедиция.

The article is devoted to the characteristics of the linguistic features of the Tatars of the Kirov region. The paper considers some nominal parts of the speech (noun and pronoun) of the baltasin and nukrat subdialects of the middle dialect of the Tatar language. The material was prepared based on the results of a comprehensive expedition undertaken in 2018 by the Institute for Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan in the Tatar villages of the Kirov region of the Russian Federation.

**Keywords:** the Tatar language, dialectology, middle dialect of the Tatar language, baltasin subdialect, nukrat subdialect, morphology, complex expedition.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, дөньяда татарларның телен, әдәбиятын, халык иҗатын, музыкаль һәм тасвирый сәнгатен югары фәнни дәрәҗәдә өйрәнә торган гыйльми-тикшеренү үзәге буларак, милләттәшләребез яшәгән төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештыра. Комплекслы рәвештә өйрәнгәндә, тел, әдәбият, фольклор, сәнгать юнәлешенең төбәк хәзинәсендә булган барлык төр байлыгы – буыннан буынга тапшырыла килгән авыз иҗаты үрнәкләре, йола-гадәтләре, музыкасы, кием-салымы, йорт-каралты бизәкләре, тел үзенчәлекләре, эпиграфик һәм археографик мирасы – һәрберсе барлана һәм җентекләп анализлап бәяләнә. Халкыбызның рухи һәм милли-мәдәни мирасын туплауны дәвам итү максаты белән 2018 елда Киров өлкәсе татар авылларына фәнни экспедиция оештырылды. Өлкәнең өч районындагы 25 торак пунктта тикшеренүләр алып барылды: Слободской районының Нократ (Арслан, Касыйм, Ильяс авыллары), Малмыж районының Аджим, Исәк, Иске Йөрек, Актүбә, Никольский, Татар Кумбашы, Рожки, Яңа Йөрек, Шәгабән, Үрнәк, Кәлнә, Яңа Смәел, Салкын Чишмә авыллары һәм Малмыж шәһәре, Нократ Аланы районының Иске Пенәгәр, Ямул, Чумачар, Яңа Пенәгәр, Казанка, Урта Шөн, Түбән Шөн, Сасмак авыллары.

Киров өлкәсенең татар авылларында татар теле урта диалектының ике сөйләше таралган: Слободской районында – нократ, Малмыж һәм Нократ Аланы районнарында – балтач сөйләшләре.

**Балтач сөйләше.** Малмыж һәм Нократ Аланы районнарында яшәүче милләттәшләребез тел үзенчәлекләре ягыннан татар теле урта диалектының балтач сөйләшенә карый. Гомумән, балтач сөйләше Татарстанның төньяк-көнчыгышында, Киров өлкәсенең һәм Удмуртиянең көньягында (Шушма һәм Бурец елгалары бассейны) таралган. Нократ Аланы өлешчә Татарстанның Мамадыш районы белән чиктәш булганга күрә, биредә бераз мамадыш сөйләше үзенчәлекләре дә чагылыш таба.

Балтач сөйләше – казан арты сөйләшләре арасында әдәби телгә иң якын торганы. Шулай да бу сөйләштә дә диалекталь үзенчәлекләр юк түгел. Балтач сөйләшенең грамматик төзелеше, фонетик һәм лексик системасы тел белгече, диалектолог Д.Б. Рамазанова тарафыннан «Татар халык сөйләшләре» китабында тасвирлана [ТХС, б. 38–42].

Архив материаллары нигезендә һәм төбәктә яшәүче халыклар белән аралашу нәтиҗәсендә биредәге татарларның күбесенчә Татарстанның Балтач районыннан күчеп килгәнлекләре ачыкланды. Шулай ук Кукмара, Арча районыннан да килеп төпләнгәннәр. Бу күчеш төрле вакыт аралыгында булган. Мәсәлән, Малмыж районының Иске Йөрек, Татар Кумбашы авыллары XVI гасыр урталарында ук (1554 елларда) барлыкка килгән. Арча районы Мәтәскә авылы һәм Балтач районы Түнтәр авылының күп кенә гаиләләре, Явыз Иван чукындыруыннан качып, бу җирләрдә төпләнгәннәр. Малмыж районының Актүбә авылына исә XX гасыр башларында (1935 елларда) күмәкләштерү вакытында Балтач районыннан күчеп килүчеләр күп булган. 1950–1960 елларда, Исәк авылына Балтач районының Югары Сәрдек һәм Түбән Сәрдек авылларыннан килеп утыралар.

**Нократ сөйләше** Нократ (Вятка) елгасының бер тармагы булган Чепца елгасы бассейнында таралган. Шуңа күрә сөйләш вәкилләрен Чепца буе татарлары дип атау да бар.

Административ бүленеш буенча бу территория Киров өлкәсенең Слободской районына һәм Удмуртия республикасының Юкамен, Глазов, Балезино районнарына керә, элек исә Вятка губернасының Слободской һәм Глазов өязләренә караган.

Нократ сөйләше вәкилләренең тарихы шактый үзенчәлекле һәм катлаулы. Тарих һәм археология материаллары күрсәткәнчә, алар яши торган җирләр борынгы чорда Болгар дәүләте составына кергән, монгол яуларыннан соңгы чорда исә болгарларның төньякка борынгы удмурт җирләренә күчеп утырган булулары турында мәгълүматлар бар.

Сөйләш вәкилләренең бер өлеше – Чепца елгасының югары агымында, Удмуртиядәге авылларда яшиләр. Бу сөйләшкә караган авыллар арасында иң зурысы – Балезино районындагы Кистем авылы. Тарихи материаллардан күренгәнчә, Кистем халкы, җир аз булу сәбәпле, Киров өлкәсендәге Нократ (русча Карино) авылыннан аеры-

лып чыгып, әлеге урынга килеп утырган. Бу авылның сөйләше дә шул ук Нократ авылы сөйләшеннән аерылмый диярлек. Шуңа күрә, фәндә сөйләш нократ-кистем сөйләше дигән исем белән дә билгеле [ТХС, б. 140].

Киров өлкәсенең Слободской районына караган Нократ авылы элек бик зур булган, үзе берничә авылны – Олы Ил яки Югары авыл (Югары Карино), Түбән авыл (Түбән Нократ), Ильяс авылларын берләштереп торган. Югары авыл үзе дә Дәүләтьяр һәм Митюк авылларына, Түбән авыл исә Арслан, Абаш, Касыйм, Юач авылларына бүленгән булган. Хәзер бу авыллар бик кечкенә калган.

Нократ сөйләшенең үзенчәлекләре фәнни яктан шактый нык өйрәнелгән. 1920 еллар азагында күренекле галим Җ. Вәлиди Нократ иленә диалектологик экспедицияләр уздыра һәм нократ-кистем сөйләше турында әһәмиятле мәгълүматлар теркәп калдыра; Л. Җәләйнең «Татар диалектологиясе» дигән китабында да нократ сөйләше турында материаллар, фәнни күзәтүләр китерелә [Валиди, с. 135–144; Җәләй, 1947, б. 32–38].

Нократ сөйләше бик әтрафлы итеп, тиешле фәнни югарылыкта һәм бөтен тулылыгы белән тел белгече Н.Б. Борһанова тарафыннан өйрәнелә, кандидатлык диссертациясе языла [Бурганова, 1953].

Диалектологлар Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Ф.Й. Йосыповларның да әлеге сөйләшкә багышланган хезмәтләре бар. Ф.С. Баязитова Нократ якларын аеруча нык өйрәнә (1986, 1988, 2002 еллардагы экспедицияләрдә катнаша), нократ сөйләшенең грамматик төзелеше, лексик системасы, бу төбәкнең матди-рухи мәдәнияте турында бай материалларны үз эченә алган китап чыгара һәм әлеге сөйләш үзенчәлекләрен «Татар халык сөйләшләре» дип аталган хезмәттә дә бәян итә [Баязитова, 2006; ТХС, б. 140–155].

Тел үзенчәлекләрен лингвистик география методы белән өйрәнү нәтиҗәсендә, нократ сөйләшендә дүрт урынчылык билгеләнгән: нократ, кистем, глазов (юкамен), бисермән-керәшеннәр урынчылыклары. Киров өлкәсенең Слободской районы татар авыллары нократ урынчылыгына карый.

2012 елда Удмуртия Республикасына оештырылган фәнни комплекслы экспедиция вакытында Нократ сөйләшенең кистем, глазов (юкамен) урынчылыклары М.Р. Булатова тарафыннан да өйрәнелә. Һәм аның шул төбәк вәкилләренә хас тел үзенчәлекләрен яктырткан һәм гореф-гадәт, көнкүреш материалларын туплаган хезмәтләре басылып чыга [Рамазанова, Булатова, 2021, б. 98–149].

Нократ сөйләше татар теле урта диалектының борынгылык шактый яхшы сакланган кызыклы бер сөйләше булып санала. Бу сөйләштә тарихның тирән катламнарын ачарга ярдәм итә торган фонетик, морфологик, лексик үзенчәлекләр, йолалар һәм гореф-гадәтләр сакланып калган. Йолаларга, мифологиягә һәм ырымнарга караган, туганлык мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр, кием-салым атамалары, әлеге сөйләшнең татар телендәге казан арты, пермь, керәшен,

касыйм сөйләшләре белән, шулай ук көнбатыш (мишәр) диалекты сөйләшләре белән дә зур уртаклыгы булуын күрсәтә.

Тарихи сәбәпләр аркасында, татар халкының төп өлешеннән территориаль яктан аерымланып, удмуртлар һәм руслар арасында яшәп калганлыктан, нократ сөйләше вәкилләренең гореф-гадәтләрендә әлеге халыклар белән уртаклыклар барлыкка килгән.

Балтач һәм нократ сөйләшләре төп грамматик категорияләр, аларның ясалышы һәм мәгънәләре буенча татар әдәби теленнән, нигездә, аерылмый. Шуның белән бергә кайбер үзенчәлекләр дә күзәтелә. Исем һәм алмашлык сүз төркемнәрен карап узыйк.

**Исемнәр**. Нократ сөйләшендә иркәләү кушымчасы (*-кай*/*-кәй*) әдәби телдән аермалы буларак, *-куᵒй* формасында әйтелә: *Камкуᵒй* – әд. Камиләкәй, *әткуᵒй* – әткәй, *әңкуᵒй* – әнкәй, *җанкуᵒй* – җаныкай, *Бибкуᵒй* – Бибекәй һ.б.

Әлеге сөйләштә III заттагы исем, алмашлык, сыйфат һәм саннарга икешәр тартым кушымчасы ялгану үзенчәлекле (*-ы-сы*/*-е-се): аның исемесе* – әд. аның исеме, *арыш ынысы* – арыш оны, *икесегез* – икегез, *барсыбызны* – барыбызны, *берсебез* – беребез, *өчесебез* – өчебез, *сет эстесе* – сөт өсте һ.б.

Бу күренеш бик сирәк кенә балтач сөйләшендә алмашлыкларда һәм кайбер сүзләрдә күзәтелә. Мәсәлән: *Йегет йортона төшкәндә қызның үз әйберсе* (әйбере) *булырға тийеш. Монсысы* (монысы) *минем өй. Ансысын болай пешерәбез: әче қамырны җәйәбез дә, ул қабара.*

Икеләтелгән тартым кушымчасын ялгау татар теле урта диалектының минзәлә, златоуст, турбаслы, бөре [Булатова, 2021, б. 48], мамадыш, пермь, керәшен сөйләшләренә һәм көнбатыш (мишәр) диалекты сөйләшләренә дә хас.

Балтач сөйләшендә I һәм II зат тартым кушымчалы исемнәрнең төшем килеше кыпчак тибында да, угыз тибында да формалашырга мөмкин: *бозаwымы* / *бозаwымны* – әд. бозавымны, *үлчәwеңе* / *үчәwеңне* – үлчәвеңне һ. б.

Нократ сөйләшендә *-нан*/*-нән*/*-дан*/*-дән* чыгыш килеше кушымчалары *-дин*/*-дән* рәвешендә дә әйтелә: *синдин* – әд. синнән, *кешедин* – кешедән. Мәсәлән: *Бик йуғары бездин, мынау таулар эстендин йердән су киләә.*

Балтач сөйләшенә караган кайбер авылларда кеше исемнәре кыскартыла. Мәсәлән, Яңа Пенәгәр авылында кеше исемнәрен тулы көе, ә Иске Пенәгәрдә кыскартып әйтәләр: *Маһри* – әд. Маһрибикә, *Рәхи* – Рәхимулла, *Самыйқ* – Сәмигулла, *Нурый* – Нурәхмәт, *Бәдәр* – Шәмсибәдәр, *Заһи* – Заһидулла, *Исмәй* – Исмәгыйль һ.б.

Исем-исем сүзтезмәләре нократ сөйләшендә күп очракта кушымчасыз гына кулланыла: *кез кен* – әд. көз көне, *дур татар аwыл* – зур татар авылы, *айақ кийәм* – аяк киеме, *қазан кеше* – казан кешесе, *шэкәр савыт* – шикәр савыты, *ураза бәрйәм* – ураза бәйрәме, *йер алма баз* – бәрәңге базы, *аwыл қалық* – авыл халкы, *тау бит* – тау бите, *Қорбан бәрйәм* – Корбан бәйрәме һ.б. Шулай ук: *тез ала* –

тездән алып. Мәсәлән: *Мин үрәнмә келим ғәрәп телгә.* – Мин гарәп телен өйрәнергә телим.

Бу күренеш урта диалектның пермь һәм көнчыгыш (себер татарлары) диалекты сөйләшләренә дә хас. Сирәк кенә минзәлә (яңавыл урынчылыгы), бәрәңге, златоуст, бөре, чистай, темников сөйләшләрендә дә очрый.

Иялек һәм төшем килешендәге исемнәр һәм алмашлыкларга *-қысы / -кесе* кушымчалары ялгап сөйләү нократ сөйләшенең төп морфологик үзенчәлекләреннән берсе дип әйтергә мөмкин: *анынқысы йаwлық* – әд. аның яулыгы, *безнекесе эш* – безнең эш, *қызымнықысы шал'* – кызымның шәле, *анынқысы кулмик* – аның күлмәге, *синенкесе йер* – синең җирең, *безненкесе йер алма* – безнең бәрәңге һ.б.

Әдәби телдән аермалы буларак, бу формалар аергыч ролендә дә киләләр: *аwылнықы оланнар* – әд. авыл балалары, *минеңкесе қыз* – минем кыз, *безнекесе аwыл* – безнең авыл, *күршенеке малай* – күрше малае, *Қазаннықы қатын* – Казан хатыны, *қыз-қатыннықы күлмәк* – хатын-кыз күлмәге һ.б.

Нократ сөйләшендә саннар белән ачыкланып килгән исемнәр, әдәби телдән аермалы буларак, күплектә яраша. Мәсәлән: *Ике киленнәр (әд. ике килен) белә тырдық, берги тырдық. Беш кешеләр* (кеше) *тее урамға китте.* Чагышт.: шулай ук урта диалектның пермь сөйләшендә дә.

**Алмашлыклар.** Зат алмашлыклары: *мин / мэн, син / сэн, ыл / ул / у, без, сез, алар.*

Нократ сөйләшендә *шул* күрсәтү алмашлыгы урынына *ул, бу, алай, былай, андай* (шушы, шулай, шушылай, шундый) алмашлыклары да кулланыла. Мәсәлән: *Андай (әд. шундый) тырмышта тырдық. Ул уқ арада без ди килдек – Шул ук арада без дә килдек.*

Балтач сөйләшендә I һәм II зат алмашлыклары юнәлеш килешендә *мийа, сийа* вариантында да очрый. Бу күренеш бигрәк тә дөбьяз сөйләше белән чиктәш авылларда күзәтелә. Мәсәлән: *Мулла абзый әйтеп қалдырды моно мийа* (әд. миңа).

Чагышт.: *мийа / мийә, сийа / сийә* формалары Башкортстан татарлары сөйләшләренә (байкыбаш, минзәлә, кормантау, тепекәй, турбаслы һ.б.) [Булатова, 2021, б. 97], шулай ук норлат, дөбьяз, эчкен, пермь, нагайбәк, сафакүл һәм себер татарлары сөйләшләренә дә хас.

Балтач сөйләшендә *без, сез* алмашлыкларының иялек килеше *безен, сезен* рәвешендә дә ясала. Мәсәлән: *Монда безен* (әд. безнең) *әтиләр никахқа төштөләр. Безен аwыл тығыз утырған була, бер төркөм кеше йаңға урынға күчеп утыра. Сезен нәнә* (әни) *паласлар да суқты ул.*

Нократ сөйләшендә тагын түбәндәге алмашлыклар билгеле: *ана, мынау / мына, теге / тее / те, у / ул, бу; нинди, қасы, ничә / нэчэ, қай ки / қайа ки* – әд. каядыр, *ни / нә / нимэ / нәстә* – нәрсә, *әлдә нәмәстә* – әллә нәрсә, *беттегесе* – бөтенесе, *кемсә / кемки* – кемдер, *ники* – нидер, нәрсәдер, *қайки* – кая да булса. Мәсәлән: *Малларны қай ки салдылар*

(каядыр куйдылар). *Кемкидә* (кемдә булса да) *бардыр ул китаплар. Нәрсә* сорау алмашлыгының *нәстә* варианты ике сөйләштә дә иркен кулланыла. Мәсәлән: *Бер абыстай әбилеккә* (кендек әбисенә) *әйт-те: бер нәстә* (нәрсә) *бирмәсәләр дә, сабын булса да сорап ал, диде. Өмә йасыйлар: кем мүк сала, кем башқа нәстә. Ашқа башта нәстә салыйм? Сондықта түлләр, шторалар, өйгә нәстә кирәк – бэтенесен түйәп апардық..*

Балтач сөйләшендә III зат һәм күрсәтү алмашлыкларының юнәлеш килешендә борынгы *-ар/-әр* кушымчасы саклана. Мәсәлән: *Моңғар (моңа) да дучмақ салып қайтарыйқмы? Зиһенне шуңғар бир-гәндер Ходай – қорәнне қай төшөннән ачсам, шуннан уқыдым. Бездән йырақ қына түгел буыннар утырта торған әби барийы, аңғар (аңа) йөрөрләр ийе. Йөзлөк белән туған бала бик сирәк була ул, аңғар (аңа) тиз күз тийә дийә торғаныйы нәнә.*

Сөйләштә *шуңа, моңа, тегеңә* алмашлыкларының юнәлеш киле-ше *-арға/-әргә* кушымчасы белән дә ясала. Мәсәлән: *Шоңарға (шуңа) дип қамыр ашы әзерләп қуйдым. Тегеңәргә (тегеңә) дә ошаған микән.*

Шулай итеп, Киров өлкәсенә оештырылган комплекслы экспе-диция барышында милләттәшләребезнең сөйләм үзенчәлекләренә игътибар ителде, алар анализланды. Бу төбәктә татар теле урта диа-лектының нократ һәм балтач сөйләшләре таралган. Диалекталь үзен-чәлекләр булуга карамастан, сөйләшләрдә исем сүз төркемнәре, баш-ка сүз төркемнәре кебек үк, нигездә, татар әдәби телендәгечә. Әйтеп узуыбызча, балтач сөйләше – казан арты сөйләшләре арасында әдәби телгә иң якын торганы. Нократ сөйләшендә тарихның тирән катлам-нарын ачарга ярдәм итә торган, иске татар язма әдәби теленә хас бул-ган үзенчәлекләр ныграк сакланып калган.

**Әдәбият**

*Баязитова Ф.С.* Нократ сөйләше. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш һәм йола терминологиясе, фольклор. Казан, 2006. 240 б.

*Булатова М.Р.* Татарские говоры Башкортостана: ареальный аспект. Казань: ИЯЛИ, 2021. 136 с.

*Бурганова Н.Б.* Языковые особенности каринских и глазовских татар: авто-реф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1953. 16 с.

*Валиди Дж.* Наречие каринских и глазовских татар // Труды общества изу-чения Татарстана. Казань, 1930. С. 135–144.

*Җәләй Л.* Татар диалектологиясе. Казан, 1947. 136 б.

*Рамазанова Д.Б., Булатова М.Р.* Тел – милләтнең җаны (Татар теле урта ди-алектының нократ сөйләше) // Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары. Казан, 2021. 2 нче басма. 400 б. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән). Б. 98–149.

Татар халык сөйләшләре: Ике китапта. Беренче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. / Казан: Мәгариф, 2008. 463 б.

***Булатова Миңнира Рәхим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81'33:811.512.145

***М.М. Әюпов,***
***Р.Р. Сафина***

# РУС-ТАТАР МАШИНА ТӘРҖЕМӘЧЕСЕ ӨЧЕН ПАРАЛЛЕЛЬ ТЕКСТЛАРНЫҢ МӘГЪЛҮМАТ БАЗАСЫН ӘЗЕРЛӘГӘНДӘ ОЧРЫЙ ТОРГАН АВЫРЛЫКЛАР

В статье описываются проблемы, возникающие при подготовке данных для базы данных русско-татарских параллельных текстов и предлагаются пути их решения. База данных русско-татарских параллельных текстов в дальнейшем используется для обучения русско-татарского машинного переводчика.

**Ключевые слова:** русско-татарский машинный переводчик, база данных, татарский язык.

The article describes the problems that arise when preparing data for a database of Russian-Tatar parallel texts and suggests ways to solve them. The database of Russian-Tatar parallel texts is subsequently used to train a Russian-Tatar machine translator.

**Keywords:** Russian-Tatar machine translator, database, Tatar language.

«Татсофт» (https://translate.tatar/) рус-татар машина тәрҗемәчесе [Khusainov, Suleymanov, Gilmullin, 2020, p. 251–261] аерым сүзләр яки фразаларны түгел, ә бөтен җөмләне «аңлап» тәрҗемә итә торган иң беренче нейросеть машина тәрҗемәчеләре исәбенә керә. Хәзерге вакытта «Татсофт» үз аналоглары арасында (Яндекс һәм Google) тәрҗемә сыйфаты буенча иң яхшысы булып тора. Мондый системаны эшләү өчен зур күләмдә параллель җөмләләр (дистәләгән, йөзләгән миллион пар җөмләләр) таләп ителә. Дөньякүләм киң таралган инглиз, кытай телләре кебек зур телләрдән аермалы буларак, татар теле аз ресурслы телләргә керә һәм, шуңа бәйле рәвештә, рус-татар машина тәрҗемәчесен ясаган вакытта параллель текстларның мәгълүмат базасын тутыру иң катлаулы мәсьәлә булып тора. Әлеге мәсьәләне хәл итү өчен безнең тарафтан мәгълүмат җыю, эшкәртү һәм киңәйтү ысуллары һәм технологияләре эшләнде.

Машина тәрҗемәчесен өйрәтү өчен рус-татар параллель текстларының мәгълүмат базасын туплау түбәндәге этапларны үз эченә ала:

– рус һәм татар телләрендә текстлар җыю;

– текстларны җөмләләргә бүлү һәм ике телдәге параллель җөмләләрне үзара тигезләү;

– параллель җөмләләр белән тәрҗемә итүнең дөреслеген тикшерү;

– җөмләләрдә булган пунктуацион, грамматик, синтаксик һәм башка хаталарны төзәтү.

## Рус һәм татар телләрендә текстлар җыю

Рус-татар параллель текстларының мәгълүмат базасын туплау эшенең беренче этабында бер телдәге электрон текстларны һәм ул текстларның икенче телгә тәрҗемәләрен җыярга кирәк. Китапларны, журналларны һәм башка басма продукцияне цифрлаштыру – текстлар җыюның бер ысулы. Безнең тикшерү күрсәткәнчә, татар телендәге күпчелек басма продукциясенең электрон нөсхәсе юк, булган очракта да – тулы түгел. Яки, әсәрнең электрон нөсхәсе бер телдә булса, икенче телгә тәрҗемәсе кәгазьдә генә теркәлгән. Шуңа күрә текстлар җыю өчен басма чыганаклардан файдалану зарурлыгы туа. Алга таба бу эшне башкару этапларын карап китик.

Иң элек (беренче адым) кирәкле әсәрнең сканлаштырылган нөсхәсен табарга яки, әгәр яхшы сыйфатлы нөсхә булмаса, әсәрне сканлаштырырга кирәк. Аннан соң (икенче адым) әсәр танып-белү махсус программалары ярдәмендә эшкәртелә. Өченче адымда тексттан ярымавтомат рәвештә алга таба кирәк булмаган мәгълүмат (мәсәлән, рәсемнәр, бит номерлары) алына. Безнең тарафтан әлеге ысулны кулланып, 283 926 бит текстның электрон нөсхәсе эшләнде.

Электрон параллель текстларны тулыландыруның икенче ысулы – булган интернет ресурслардан файдалану. Аларга мөрәҗәгать иткәндә, анда тәкъдим ителгән материалның бертөрле түгел икәнен истә тотарга кирәк. Шулай ук бу чыганакларның ышанычлы булуына инану сорала. Бу ысулны куллану өчен татар һәм рус телләрендә бертөрле эчтәлектәге текстлар булган интернет ресурслардан автомат рәвештә мәгълүмат җыя торган программа эшләнде. Ул түбәндәге мөмкинлекләргә ия:

– татар һәм рус телләрендәге текстларны җыеп алу;

– җыелган текстлар арасында «татар телендә тәрҗемә» һәм «рус телендә тәрҗемә» бәйләнешләрен табу.

Әлеге программа ярдәмендә рус һәм татар телләрендә бәйләнешле 617 754 пар бит җыелды.

Электрон текстларны тулыландыруның өченче ысулы – татар җөмләләре җыелмасын ясалма арттыру. Моның өчен төрки морфотәрҗемәче, татар теленең барлык тел күренешләрен максималь исәпкә алып, башкорт, кырым татар телләре өчен бераз үзгәртеп яңартылды. Нәтиҗәдә, кагыйдәләргә нигезләнеп эшләүче башкорт-татар, татар-башкорт, татар-кырым татар һәм кырым татар-татар машина тәрҗемәчесе төрки телләрдә электрон корпусларны арттыру мөмкинлегенә ия булды. Ясалма алынган өстәмә электрон корпуслар машина тәрҗемәчесен өйрәтү өчен кулланыла, бу татар-рус һәм рус-татар машина тәрҗемәчесенең сыйфатын яхшыртырга ярдәм итә.

## Текстларны җөмләләргә бүлү һәм параллель җөмләләрне тигезләү

Рус һәм татар телләрендәге параллель текстларның күбесеннән тәрҗемәсе туры килгән өлешләре турындагы мәгълүматны турыдан-

туры алып та булмый. Беренчедән, тәрҗемә ителгән һәм оригинал текстлардагы сүзләр арасында бер генә мәгънәле туры килү булмый, шулай ук грамматик төзелештә аерымлыклар, берничә мәгънәле сүзләр очрый. Икенчедән, бер җөмләнең тәрҗемәсе берничә җөмлә белән бирелә, һәм, киресенчә, берничә җөмлә бер җөмлә белән тәрҗемә ителә ала. Ниһаять, тәрҗемәдә төгәлсезлекләр булырга мөмкин, иң зур төгәлсезлек – төшеп калган сүзләр [Хакимов, Шаехов, 2021].

Шуңа күрә текстларны җөмләләргә бүлү – катлаулы мәсьәлә. Аны җөмләнең башын һәм ахырын күрсәткән синтаксик билгеләрне кулланып хәл итәргә мөмкин. Аерым тел лексикасы турындагы мәгълүматны – кыскартылмалар исемлеген һ.б. файдаланырга да була. Бусы – четереклерәк ысул.

Параллель җөмләләрне тигезләгәндә, җөмләләрдә сүзләрнең килү тәртибе лексик бәйләнешләрне табу өчен төп мәгълүмат чыганагы буларак кулланыла. Машина тәрҗемәчесе эшенең уңышы җөмләләрне тигезләү төгәллеге дәрәҗәсенә бәйле.

Параллель текстларны тигезләү өчен, беренче адымда ABBYY Aligner 2.0 программасы кулланылды. Ул төрле телләрдәге текстларда бер-берсенә туры килгән җөмләләрне таба, аларны үзара чагыштыра һәм автомат рәвештә тигезләнгән өлешләрне билгели. Аннан соң, икенче адымда, тигезләү вакытында киткән хаталарны төзәтү һәм нәтиҗәнең сыйфатын яхшырту өчен, тигезләнгән текстлар кулдан карап чыгылды. Әлеге эш кысаларында барлыгы 954 829 параллель җөмлә тигезләнде.

## Параллель җөмләләрдә тәрҗемә ителүнең дөреслеген тикшерү

Сыйфатлы тәрҗемә оригинал текстның мәгънәсен төгәл тапшырырга тиеш. Яхшы сыйфатка ирешү өчен, гадәти тикшерүдән тыш, түбәндәгеләрне исәпкә алырга кирәк:

– терминнар барлык текстларда да бер үк төрле тәрҗемә ителергә тиеш;

– әгәр сүзнең берничә язылыш варианты булса, алар бердәм язылышка китерелергә тиеш;

– саннарның язылышы аерым тел кагыйдәләренә туры килергә тиеш.

Шулай ук җөмләләрдә хаталар юклыкка инану өчен, пунктуацион, грамматик һәм орфографик хаталарны төзәтеп чыгу сорала.

Әлеге эшләр кулдан башкарылды.

## Мәгълүмат җыйганда очраган кыенлыклар

Рус-татар параллель текстларын туплаган вакытта бик күп авырлыклар белән очрашабыз. Аларның кайберләренә тукталып үтик.

Сканлаштырылган текстларны махсус танып-белү программалары ярдәмендә эшкәрткәндә, ышанычлы булмаган һәм танып белү программасы сүзлегендә булмаган сүзләр очраса, орфографик хаталар

барлыкка килә. Аерым килергә тиешле сүзләрнең кушылып язылуы – танылган текстларда шулай ук киң таралган очрак. Мондый хаталарны автомат рәвештә төзәтеп булмый, текстны кулдан карап чыккан вакытта гына аларны ачыкларга һәм төзәтергә мөмкин. Мондый төзәтүләрне ABBYY Aligner 2.0 программасы ярдәмендә параллель җөмләләрне тигезләгәнче башкарырга кирәк, чөнки әлеге хаталар тигезләү сыйфатына йогынты ясый.

Сканлаштырылган текстларны таныганда, рәсемнәр һәм рәсем асты язулары, таблицалар һәм таблица исемнәре, бит номерлары, төрле формулалар һ.б. алга таба кирәк булмаган мәгълүмат алып ташланырга тиеш. Моны гамәлгә ашыру өчен, документны текст форматында сакларга була, әмма бу очракта рәсем асты язуларын, бит номерларын алып ташлау катлауланачак, чөнки алар текстның бер өлешенә, ә таблицалар, үз функциональ мөмкинлекләрен югалтып, эзлекле рәвештә килүче абзацларга әйләнә. Шуңа күрә, алга таба кирәге булмаган мәгълүматны алып ташлау өчен, программа эшләргә карар кылынды, ул алынырга тиешле мәгълүматның түбәндәге үзенчәлекләренә таяна.

Әгәр дә бит номерлары өске колонтитулга кермәсә һәм бит астында килсә, сканлаштырылган текст танылганнан соң, алар аерым юлда килүче бер берәмлеккә үскән саннарны тәшкил итә һәм гади алгоритм ярдәмендә табыла. Әгәр дә бит номерлары өске колонтитулга керсә, алар колонтитуллар өчен булган алгоритмны кулланганнан соң юкка чыга.

Өске колонтитул танылганнан соң аерым юлга урнаша һәм төп тексттан аерылып торган (гадәттә, кечкенәрәк зурлыктагы) шрифтлы була. Җөп санлы бит колонтитуллары барысы бертөрле булып, бу шулай ук так санлы бит колонтитулларына да кагыла. Колонтитуллар бер-берсеннән аларга бит номерлары кергән очракта гына аерылалар. Шул ук вакытта ул аерма колонтитулның башында яки ахырында, бит номеры өчен җавап биргән санда гына булачак.

Рәсемнәр, гадәттә, төп текст белән рәсем арасында килгән рәсем асты язуы белән бергә бара. Рәсем асты язуының тагын бер үзенчәлеге – аның зурлыгы төп текстныкыннан аерылып тора һәм күпчелек очракта башка шрифттан була.

Таблицалар рәсемнәр кебек эшкәртелә, аермасы – таблицага аңлатма язуының таблицадан соң түгел, ә аңа кадәр килүендә генә.

Шулай итеп, алга таба кирәк булмаган мәгълүмат махсус язылган программа ярдәмендә тексттан алып ташлана, бу очракта дөрес нәтиҗә 90% тәшкил итә.

Сүзне юлдан юлга күчерү текстның тышкы күренешен яхшырта. Шуңа күрә ул китап басу эшендә киң кулланыла. Сканлаштырылган текст танылганнан соң, сүз, юлдан юлга күчерелгән очракта, сүз башына, сызыкка, юл ахыры билгесенә һәм сүзнең күчерелгән өлешенә әверелә. Бу очракта бүленгән сүзнең кушма сүз яки сызыкча аша языла торган сүз булу ихтималын исәпкә алырга кирәк. Өстәвенә,

сызыкча аша язылган сүзләр чагыштырмача сирәк очрый, алар юлдан юлга күчкән сүзләрнең уртача 2% ын тәшкил итә. Шуңа күрә юлдан юлга күчкән сүзләрнең барысын да кушылып языла торган сүзләр дип карарга мөмкин булыр иде. Әмма рус-татар параллель текстларының мәгълүмат базасы әлеге текстлар хисабына тулылана барганга күрә, андагы хаталы сүзләр саны да артачак. Димәк, юлдан юлга күчкән сүзләрне эшкәртергә кирәк һәм моның өчен татар теленең морфологик анализаторы [Gatiatullin, Ayupov, 2015, p. 120–126] һәм түбәндәге алгоритм кулланыла.

Беренче адымда андый сүз кушылып язылырга тиеш, дип фаразлана, шуңа күрә юлдан юлга күчкән сүздән сызык һәм юл ахыры билгесе алына; ул сүз морфологик анализаторга тапшырыла. Морфологик анализатор бу сүзне тамырга һәм морфемаларга таркатырга тырыша. Әгәр дә бу эш барып чыкса, сүз кушылып язылырга тиеш санала. Сүзне тамыр һәм аффикслар тезмәсе рәвешендә күрсәтеп булмаган очракта, морфологик анализаторга сүз сызыкча аша язылып бирелә. Бу юлы сүз дөрес дип табылса, әлеге сүз сызыкча аша языла дип исәпләнә.

Мисал өчен 1 нче рәсемдәге беренче юлны алыйк. Башта морфологик анализаторга кушылып язылган *хатынкыз* сүзен бирәбез, әлеге сүз морфологик анализатор базасында табылмады дигән җавап алачакбыз, димәк, сүз хаталы язылган. Икенче адымда сызыкча аша язылган *хатын-кыз* сүзен бирәбез. Морфологик анализатор бу сүзне тамыр сүз дип җавап кайтарачак, димәк әлеге сүз дөрес язылган. Шуңа күрә ул сызыкча аша язылырга тиеш, дигән фикергә киләбез.

> Зәмзәмия гаепне заманага да тага. Мөселман хатын-
> кызларына куелган таләпләр кысасында яшәсә, ул шундый
> көнгә калыр идемени? Гүзәл зат, бөек ана, ир-атлар белән
> хатын-кызларның хокуклары тигез, дип, күккә чөеп, хатын-
> кызны бозып бетерделәр. Бу мактауны күтәрә алмыйча,
> күпләр тайгак юлдан китеп барды. Зәмзәмия үзен әнә
> шундыйларның берсе итеп саный. Аның фикеренчә, аракы
> эчкән, тәмәке тарткан, ят җирләрен күрсәтергә атлыгып тор-
> ган, ирләр муенына асылынырга хирыс хатын-кызлар иң
> модалы затка әйләнделәр. Тыйнаклык, гүзәллек, сөйкемле-
> лек, хатын-кыз горурлыгы турында сүз катарга урын кал-
> мады...

1 нче рәсем. Сканлаштырылган текст үрнәге

1 нче рәсемдәге соңгы юлны карап үтик. Бу очракта беренче адымда морфологик анализаторга *калмады* сүзе бирелә. Җавап итеп, сүз *кал-* тамыры һәм *-ма* һәм *-ды* морфемаларына таркалып кайта, ягъни андый сүз бар һәм ул дөрес язылган. Димәк, әлеге сүз кушылып язылырга тиеш.

Юлдан юлга күчкән сүзнең башында яки ахырында сызыкча килгән очраклар да була. Аларда юлдан юлга күчерү өчен хезмәт иткән сызыкча һәм юл ахыры билгесе автомат рәвештә алып ташлана.

Бу алгоритмны куллану, дөрес танылмаган сүзләрдән кала, сүзне юлдан юлга күчерүнең барлык очракларын дөрес эшкәртергә мөмкинлек бирә.

Машина тәрҗемәчесен өйрәтү өчен сыйфатлы параллель текстлар кирәк, әмма әлеге таләп һәрвакытта да канәгатьләндерелми. Бигрәк тә бу Интернеттан алынган мәгълүматларга кагыла. Кайвакыт уртаклыклары аз яки бөтенләй булмаган җөмлә парлары очрый. Шуңа күрә, сыйфатлы машина тәрҗемәчесе булдыру өчен, рус-татар параллель текстларының мәгълүмат базасын мондый сыйфатсыз парлардан чистартырга туры килә.

**Йомгаклау.** Безнең тарафтан эшләнгән мәгълүмат җыю, эшкәртү һәм киңәйтү ысуллары рус-татар параллель текстларының зур күләмле һәм сыйфатлы базасын төзергә мөмкинлек бирде. Бу, үз чиратында, «Татсофт»ның бүгенге көндә, үз аналоглары (Google, Яндекс) белән чагыштырганда, рус һәм татар телләре арасында тәрҗемә итү сыйфаты буенча иң яхшы тәрҗемәче булуына сәбәп булды. Алга таба да рус-татар параллель текстларының мәгълүмат базасы күләмен арттыру буенча эш дәвам иттереләчәк. Димәк, русчадан татарчага татар машина тәрҗемәсе тагын да камилләшәчәк.

**Әдәбият**

*Khusainov A., Suleymanov D., Gilmullin R.* (2020) The Influence of Different Methods on the Quality of the Russian-Tatar Neural Machine Translation. In: Kuznetsov S.O., Panov A.I., Yakovlev K.S. (eds) Artificial Intelligence. RCAI 2020. Lecture Notes in Computer Science, vol 12412. Springer, Cham. P. 251–261. URL: https://doi.org/10.1007/978-3-030-59535-7_18.

*Хакимов Б.Э., Шаехов М.Р.* Проблема эквивалентности параллельных предложений в тестовом корпусе для русско-татарского машинного переводчика // Proceedings of the 9th International Conference on Turkic Languages Processing (TURKLANG-2021). (Tyva, September 21–23, 2021). Tyva, 2021.

*Gatiatullin A., Ayupov M.* Modifications of morphological analysis programs for the problems of multilingual search // Proceedings of the International Conference «Turkic Languages Processing» TurkLang-2015. Kazan, 2015. P. 120–126.

***Әюпов Мәдехур Мәсхүт улы,***
*ТР ФА Гамәли семиотика институты фәнни хезмәткәре,*
*Казан федераль университеты өлкән укытучысы*

***Сафина Рәзинә Рәфкать кызы,***
*ТР ФА Гамәли семиотика институты кече фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***А.С. Шәрипова***

# ХХ ГАСЫР АХЫРЫ – XXI ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ МИФОЛОГИЗМ ҺӘМ СИМВОЛИЗМ
## (М. Гыйләҗев иҗаты мисалында)

В статье исследуются художественные особенности использования мифологических и символических средств в татарской драматургии конца XX – начала XXI века. На примере анализа пьес ведущего татарского драматурга исследуемого периода Мансура Гилязова автор приходит к выводу, что применение мифопоэтических приёмов, сплетение реального и ирреального пластов изображения, создание условно-ассоциативных образов, стремление к философичности и притчевости приводит к расширению художественных границ и усилению интеллектуальной тенденции в сценической литературе рубежа веков. Полученные результаты свидетельствуют о том, что развитие модернистских и постмодернистских приёмов создает возможность для углублённого рассмотрения проблем о прошлом, настоящем и будущем татарского народа и страны в целом, а также продвижения идеи возврата к этническим корням и традиционным ценностям. Неотъемлемым элементом художественной структуры произведений становятся образы-символы, в том числе авторские, отражающие национальное своеобразие и специфику.

**Ключевые слова:** татарская драматургия, мифологизация, символизация, Мансур Гилязов, мотив, проблема, идея, конфликт.

The article examines the artistic features of the use of mythological and symbolic means in Tatar dramaturgy of the late 20th – early 21st centuries. Using the example of an analysis of the plays of the leading Tatar playwright of the period under study, Mansur Gilyazov, it is concluded that the use of mythopoetic techniques, the intertwining of real and surreal layers of image, the creation of conditionally associative images, the desire for philosophy and parables leads to the expansion of artistic boundaries and the strengthening of the intellectual tendency in stage literature of the turn of the century. The results obtained indicate that the development of modernist and postmodernist techniques creates an opportunity for an in-depth consideration of problems about the past, present and future of the Tatar people and the country as a whole, as well as promoting the idea of a return to ethnic roots and traditional values. An integral element of the artistic structure of works are images-symbols, including those of the author, reflecting national identity and specificity.

**Keywords:** Tatar drama, mythologization, symbolization, Mansur Gilyazov, motive, problem, idea, conflict.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар драматургиясенең төп үзенчәлекләреннән берсе булып, гомуми әдәби барышка хас булганча, «әхлакый кыйбланы үз традицияләрендә эзләү, фантастик чаралар куллану, төрле стиль һәм юнәлешләр синтезы, жанр чикләре югалу, мифопоэтик алымнарга мөрәҗәгать итү» [Давлетшина, 2022,

с. 2] тора. Пьесаларның сюжетын мифологик нигезгә кору, тарихи һәм мәдәни хәтердә сакланган символик һәм мифик образларны үзәккә кую, метафорик фикерләү алымнарын куллану халыкның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турындагы проблемаларны калку итеп күтәрергә, милли тамырларга кайту һәм традицион кыйммәтләрне торгызу идеясен алгы планга чыгарырга мөмкинлек бирә. Мондый әсәрләрдә, кагыйдә буларак, бер үзенчәлек күзәтелә: сурәтләнгән вакыйгалар вакыт ягыннан хәзергегә карый, ә мифологик образлар һәм мифопоэтик традицияләргә барып тоташкан мотивлар мифологик фантастика төсен ала [Ибрагимов, 2003, с. 47].

Һичшиксез, «милли язучыларының традицион реализм һәм романтизм кысаларыннан чыгуы, аларның яңа әдәби формаларга, метафораларга, архетипларга, прообразларга мөрәҗәгать итүе әдәби агымнарның һәм юнәлешләрнең яңаруын, иҗади аңның күпдәрәҗәле үзгәрешләр кичерүен, милли әдәбиятларның катлаулы үсеш юлын күрсәтә» (Арзамазов, 2016, 23), бу үзенчәлек татар драматургиясенә дә хас. Әдәбият белән мифологиянең тыгыз үрелеп китүе әлеге чорда сәхнә әдәбиятында да яңа бер юнәлеш барлыкка килүгә этәргеч була. З. Хәкимнең «Җен бутады» (1991), «Су төбендә сөйгәнем» (1991), «Кишер басуы» (1993), «Шайтан куентыгы» (1999), Ф. Бәйрәмованың «Аллалар ялгышы» (1998), Р. Зәйдулланың «Саташкан сандугач» (2001), «Ашина» (2003), «Казан ятиме» (2012), М. Гыйләҗевнең «Бичура» (1988–1989), «Микулай» (2019) пьесаларын бу юнәлештәге әсәрләрнең ачык мисаллары дип атарга мөмкин. Д. Салиховның «Алла каргаган йорт» (1990), З. Хәкимнең «Җүләрләр йорты» (1995), М. Гыйләҗевнең «Баскетболист» (2002), А. Хәлимнең «Кияү урлау» (2006) кебек уен, «абсурд театры» элементлары актив кулланылган әсәрләр иҗат ителә. М. Гыйләҗевнең «Бичура» (1988–1989), Т. Миңнуллинның «Саташу» (2001), «Дивана» (2006), Д. Салиховның «Баязит» (2010) һ.б. пьесаларда шәхеснең күңел халәтен, икеләнү-бәргәләнүләрен сурәтләү аша иҗтимагый-сәяси проблемалар үзәккә куела. Төп фикерне җиткерү өчен, шартлы-символик образлар, архетиплар, метафораларга мөрәҗәгать итү активлаша, Р. Хәмиднең «Актамырлар иле» (1989), Аманулланың «Җәйге кырау» (1992), Р. Сәгъдинең «Сынган беләзек» (1994), Р. Батулланың «Сират күпере» (1996), И. Зәйниевнең «Суган чәчәге» (2007), Т. Миңнуллинның «Төш» (2009) һ.б. пьесалар шундыйлардан.

Атап үтелгән үзенчәлекләр «татар драматургиясенә яңа юнәлешләр, заманча модерн-постмодерн алымнары алып кергән әдип буларак, күпчелек әсәрләре татар сәхнә әдәбиятында яңа сүз, әдәби-эстетик табыш кебек кабул ителгән» [Миңнуллина, 2021, б. 478] драматург Мансур Гыйләҗев (1961) иҗатында аеруча калку чагыла. Аның «Бичура» (1988–1989) пьесасы бу җәһәттән аерым игътибарга лаек. Д.Ф. Заһидуллина әлеге драманы, З. Хәкимнең «Гасыр моңы» һәм башка кайбер драмалар кебек, халык эпосы нигезенә корылган әсәр, ди. Һәм аны XX гасыр татарлары тарихы турында төп авторлык

мифын тудыру өчен кулланган беренче әсәрләр рәтенә кертеп карый (Загидуллина, 2016, с. 13]. Безнең карашыбызча, хәзерге заман театры һәм драматургиясенә хас булган «шартлы хәлләрне, хәтта тулы бер шартлы дөньяларны модельләштерү, әлеге акылсыз реаль дөньябызга туры килгән аерым бер «идеяләрне» җиткерү өчен махсус сәнгать чаралары булдыру» [Громова, 2013, с. 128] үзенчәлеге әлеге драмада тулы чагылыш таба.

Бушап калган авылда гомеренең соңгы көннәрен кичергән 70 яшьлек Аксак картның мифологик персонажлар – Кара җаннар (Шәүләләр) һәм Бичура белән очрашуын сурәтләү, чынбарлык белән реаль булмаган дөнья күренешләрен бергә үреп бару аша автор кеше күңелендәге каршылыклы уй-хисләрне күрсәтә, «яшәеш мәгънәсе» төшенчәсенә мөнәсәбәттә эчке конфликт тудыра.

Л.Х. Дәүләтшина билгеләп үткәнчә, халыкның мәдәни хәтерендә сакланган йорт хуҗалары образлары һәм аларга бәйле мифологик элементлар татар әдәбиятында – драматургиядә дә, шигърияттә дә, прозада да (Т. Миңнуллин, М. Гыйләҗев, Х. Әюпов, Р. Шәрипов, Г. Гыйльманов, Н. Гыйматдинова, Р. Мөхетдинова һ.б.) мөһим урынны билиләр һәм этник тарихны үткән һәм киләчәк белән үзара бәйләнештә яңадан карау шартларында милли тематиканың аерылгысыз өлешенә әйләнәләр [Давлетшина, 2022, с. 22–23]. М. Гыйләҗев пьесасында да Бичура – халыкчан, милли рух белән сугарылган, ул гаиләдәге иминлек, кешенең күңел чисталыгы, рухи тынычлык сагында торган образ (*Ул бит төзүче түгел, җан сакчысы гына, күңелләр кояшы!* [Гыйләҗев, 2002, б. 88]), ә Кара җаннар, киресенчә, таркатучы көчләр буларак тәкъдим ителә. Аксакның Кара җаннар белән шартлы-фантастик көрәше, Бичура белән эчкерсез әңгәмәләре аша автор халык язмышына, аның үткәне һәм киләчәгенә бәйле җитди иҗтимагый-сәяси мәсьәләләрне күтәрә, әсәрдә «реалистик һәм мифологик образлар үзара кушылып китү аша татар авылларының юкка чыгуы, милли традицияләрне оныту кебек проблемалар яктыртыла» [Ахмадуллин, 2012, с. 491]. Үзәк герой әсәрдә идеология басымы астында үз кыйбласын югалткан, гомере буе шәхси фикерен кычкырып әйтүдән куркып яшәгән тоталитар режим корбаннарының җыелма образы буларак тәкъдим ителә.

Әсәр тукымасына кертелгән Мосафир образы мифологиядә һәм гасырлар чиге татар прозасында шактый еш очраган Хозыр Ильяс образы белән аваздаш. Тормышының киеренке чорларында Аксакка ярдәм кулы сузган Мосафирның аның нәсел дәвамчылары янына килүе һәм яшь буын вәкилләренең картның үтенечен кире кагуы милли гореф-гадәтләрнең, дини ышануларның, әхлакый кыйммәтләрнең югалуын күрсәтә, һәм бу күренеш атеистик заман нәтиҗәсе буларак аңлашыла. Әлеге фикер автор тарафыннан җимерелгән койма символы аша ныгытыла, бу шартлы образны кулланып, драматург бәхетле тормыш кору турындагы совет чоры мифы җимерелүен күрсәтә: *Хәзер койма безгә нәмәстәгә? Аусын, җимерелсен – кирәге бетте.*

*<...> Кирәкләре дә шулкадәр генә иде! Җәбер-җәфалардан саклап, бәла-казалардан ышыклап тора алдымы коймаларың?!* [Гыйләҗев, 2002, б. 57].

Әсәрдә, тотрыклылык, киләчәккә өмет-ышаныч символлары буларак, нигез, ут шартлы образлары мөһим урын били, алар үзәк геройның нәселенә генә түгел, ә гомумән, татар халкы язмышына мөнәсәбәтле бирелә. Нигез татар халкының милли асылы символы булса, учак уты милли гореф-гадәтләр белән ассоциацияләнә, һәм әлеге символик образлар аша Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» (1965), Т. Миңнуллинның «Нигез ташлары» (1968) әсәрләре арасында интертекстуаль элемтә барлыкка килеп, этник тамырларга кайту, милли үзаңны торгызу аша гына халыкның киләчәге булачак, дигән фикер көчәйтелә.

«Тарихи риваятьләр, тотрыклы, архаик сыйфатларның үзгәрешсез сакланган мәгънәсен ачарга мөмкинлек биреп, хәзерге чорның көнүзәк мәсьәләләре, милли традициянең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәгенә нисбәтле язмышы турында уйлануларга этәргеч була» [Аминева, 2012, с. 13]. Әлеге үзенчәлек М. Гыйләҗев үзе жанрын «мелодрамадан фантасмагориягә» дип билгеләгән «Исәнмесез?!» (2019) пьесасын характерлый. Әсәрнең нигезенә Иван Грозный тарафыннан Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, урманнарда, сазлыкларда качып гомер иткән татар халкының бер-берсен сәламләү сүзенә бәйле риваять салынган. Автор укучыга, «исәнмесез?» риторик соравы белән мөрәҗәгать итеп, татар халкы язмышы, аның үткәне һәм киләчәге, бердәмлек мәсьәләләрен күтәрә, кешеләрне берберсенә карата битараф булмаска чакыра.

Пьесаның сюжеты милли бәйрәм – Сабантуй алдыннан Исламовлар гаиләсендә булган вакыйгаларны сурәтләүгә корылган. Алты бертуган арасындагы туганлык мөнәсәбәтләрен сайлау мотивын үзәккә куеп тасвирлау аша, драматург конфликтны гаделлек, мәрхәмәтлелек, кешелеклелек кебек күпгасырлык рухи кыйммәтләр һәм битарафлык хөкем сөргән бүгенге көн вазгыяте арасында кора. Әсәрнең беренче күренешеннән соңгысына кадәр үзәк урынны биләп торган Сабантуй баганасы (колга) образы татар халкының милли рухы, бердәмлеге символы буларак кабул ителә. Пьеса, фольклор әсәрләрен хәтерләтеп, яхшылыкның яманлыкны җиңүе белән тәмамлана: геройларның үзара туганлык мөнәсәбәтләре ныгыгач, Сабантуй баганасына менеп, бәхетле матур тормышка күчүе рухи асылларына кире кайту белән ассоциацияләнә. Әсәрнең төп идеясе татар халкын милләт буларак сакларга чакыруга корылган, ә аның алшарты – милли үзаңны үстерү, традицияләргә, әхлакый кыйммәтләргә тугрылык саклау, дигән фикер үткәрелә. Мифологик материалны нигез итү, рациональ һәм иррациональ башлангычлар кушылып китү, рухи кыйбланы, милли нигезне, бердәмлекне аңлаткан колга, печән кибәне, йорт символларын куллану төп идеяне көчәйтүгә хезмәт итә.

«Яшәеш кыйммәтләренең тамырдан үзгәрүе, моңа кадәр ышанган, хәтта табынган идеалларның юкка чыгуы драматургларны үткәннең гыйбрәтле сәхифәләрен, тормыш-чынбарлыкны, яңа тип геройларны, каршылыклы яшәешне чагылдыруның үзенчәлекле алым-чараларын эзләүгә этәрә» [Закирҗанов, 2019, б. 320]. «Бичура», «Исәнмесез?!» драмаларында күтәрелгән глобальләштерү шартларында милли үзтәңгәллекне, мәдәни һәм рухи кыйммәтләрне саклап калу зарурлыгы мәсьәләләре М. Гыйләҗевнең «Микулай» (2019) пьесасында да үзәккә куела. Автор бу әсәрендә җитди проблеманы чагылдыруның үзенчәлекле адымын сайлый: әсәрне мондодрама жанрында иҗат итү аша халык язмышы, аның киләчәге проблемасын аеруча кискен итеп кую мөмкинлеген таба.

Драматург Сарсазкүл дип аталган керәшен авылының бердәнбер кешесе Микулайның хатирәләре аша укучыга геройның тормыш юлын бәян итә. Пьесаның композицион төзелеше озак еллар ялгызлыкта гомер кичергән геройның үз-үзе һәм чарасызлыктан үз куллары белән ясаган курчаклар белән монологына корылган. Күренештән күренешкә Микулайның бүгенге тормышы, күңел халәте ачылу белән беррәттән, узган гомере дә күз алдына китереп бастырыла, һәм ул аерым бер кешенең язмышы гына түгел, ә татар халкының XX гасырдагы Рус-япон, Беренче бөтендөнья, Гражданнар, Икенче бөтендөнья, Әфган сугышлары, шәхес культы, атеизм белән бәйле фаҗигалы вакыйгаларга мөнәсәбәтле тарихи үткәне буларак кабул ителә. Автор, сюжетның нигезенә «кечкенә авыллар» язмышы проблемасын салып, кеше һәм хакимият, шәхес һәм җәмгыять кебек җитди иҗтимагый-сәяси мәсьәләләрне күтәрә.

И.Ю. Кириллова, чуваш драматургы М. Карягинаның «Куккуклă сехет» («Күкеле сәгать», 2016) драмасын М. Гыйләҗевнең «Микулай» драмасы белән чагыштырма планда өйрәнеп, пьесаларның үзәк геройлары – Беренче Геннадийның да, Микулайның да үз өсләренә авылны, аның белән бергә милли дөньяның бер өлешен дә саклау кебек үтәп булмаслык авыр йөк алган милли геройлар булуын ассызыклап әйтә [Кириллова, 2021, с. 51]. Бу җәһәттән алар Р. Хәмиднең «Олы юлның тузаны» монодрамасы герое Нәүхәбәр белән дә аваздаш. Әлеге персонажлар өчесе дә – халыкның буыннан буынга күчеп килгән күңел байлыгын үзләрендә кадерләп саклаучылар. Сюжетның үткәндәге һәм геройның бүгенге көн вакыйгалары бергә үрелеп баруга нигезләнүе, үзәккә ялгызлык мотивы куелу, тирән психологизм укучыны яшәү һәм үлем кебек мәңгелек фәлсәфи төшенчәләр турында уйланырга мәҗбүр итә. Төп фикерне тирәнәйтүдә символик образларның роле аеруча мөһим. Микулайның үзе ясаган курчаклар белән сөйләшүе, ягъни «курчак уены» Г. Исхакыйның «курчак туе» («Ике йөз елдан соң инкыйраз», 1902–1904) белән аваздашлыгы ягыннан халыкның милләт буларак бетү куркынычы турында кисәтә. Автор аның төп сәбәбен халыкның милли асылы, милли рухы, гореф-гадәтләре югалуга бәйләп карый. Күп еллар дәвамында караңгылык белән көрәшеп яшәгән

Микулай *(Бөтен тирә-юньдә дә ут әсәре юк... Менә шуңа күрә шәм кабызып куям да инде. Кешеләр күреп торсын: монда әле тормыш бетмәгән...* [Гыйләҗев, https:// rus4all.ru/tat/20201117/33843/Mikulay.html]) авылларның бетү сәбәбен утсызлыкта, сусызлыкта күрә *(Ут та, юл да юк авылда... Шуңа күрә беркемнең дә авылга кире кайтасы килмидер дип уйлыйм. Ни күле, ни юлы, ни уты юк!* [Гыйләҗев, https:// rus4all.ru/tat/20201117/33843/Mikulay.html]). Ул һәркөнне авылны яшәтү өмете белән электр лампочкаларын тикшерә, иске чиркәүдән алып кайтылган балавыздан шәм ясап кабыза. Өметсезлек символы буларак аңлашылган ташландык йорт образлары янәшәсендәге ут, шәм, су, юл символлары киләчәккә өмет мотивы буларак яңгыраш ала. Дин йортыннан алынган балавыз шәмнән төшкән яктылык кешенең рухи гармониясе, күңел тынычлыгының нигезе шулай ук диндә булуын искәртә. Әсәрдәге ассоциатив образлар, символлар ярдәмендә автор, караңгылык һәм яктылыкны капма-каршы куеп, кеше яшәешенең мәгънәсе нидә? дигән фәлсәфи сорауны күтәрә. Шул рәвешле, аерым авыл һәм аерым кеше язмышын сурәтләү аша гомуммилләт язмышы турында уйлануларга нигезләнгән, үзенчәлекле сюжетка корылган, шартлы алымнарга һәм символларга бай «Микулай» монодрамасы белән М. Гыйләҗев милли һәм рухи кыйммәтләрне торгызу һәм алга таба саклау зарурлыгы турында фикер үткәрә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар сәхнә әдәбиятында лаеклы урын тоткан М. Гыйләҗевнең аерым әсәрләрен анализлау күрсәткәнчә, әлеге чор татар драматургиясе «элек тыелган темаларга һәм мотивларга мөрәҗәгать итү, сюжет һәм композиция коруга һәм күптөрле характерлар тудыруга мөнәсәбәтле тәҗрибә ясау аша тематиканың баетылуы һәм проблематиканың киңәюе белән характерлана» [Шарипова, 2022, с. 128], аңа әдәби алымнар төрлелегенә омтылу хас. Мифопоэтик алымнар куллану, шартлы-ассоциатив образлар, символлар тудыру, сурәтнең реаль һәм ирреаль катламнары үрелмәсе сәхнә әдбиятында интеллектуаль тенденциянең көчәюенә китерә, татар халкының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәгенә бәйле мәсьәләләрне тирәнтен карау, шулай ук этник тамырларга кире кайту һәм рухи кыйммәтләрне торгызу идеясен үткәрү мөмкинлеге тудыра.

**Әдәбият**

*Аминева В.Р.* Национальные литературы республик Поволжья как «межлитературная общность» // Национальные литературы республик Поволжья (1980–2010 гг.): коллективная монография / науч. ред. В.Р. Аминева. Барнаул: ИГ «Си-пресс», 2012. С. 5–13.

*Арзамазов А.А.* «Миноритарные» литературы и перспективы компаративистики // Национальная литература республик Поволжья: проблемы межкультурной коммуникации: материалы Межрегиональной науч.-практ. конф. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2016. С. 21–23.

*Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: история и проблемы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 511 с.

*Громова М.И.* Русская современная драматургия [Электронный ресурс]: учеб. пособие для студентов-филологов, учащихся средних учебных заведений гуманитарного профиля. 4-е изд. М.: Флинта, 2013. 160 с.

*Гыйләҗев М.* Бичура // *Гыйләҗев М.* Бичура: Пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 53–93.

*Гыйләҗев М.* Микулай // Портал национальних литератур [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://rus4all.ru/tat/20201117/33843/Mikulay.html (дата обращения: 05.12.2023).

*Давлетшина Л.Х.* Татарская проза рубежа XX–XXI веков в контексте актуальной мифологической традиции: 10.01.02; 10.01.09. Казань, 2022. 48 с.

*Загидуллина Д.Ф.* Татарская литература и национальный театр: одна дорога на двоих // Театр XXI века и вызовы нового времени: материалы Междунар. науч.-практ. конф., посв. 110-летию татарского театра. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 4–13.

*Закирҗанов Ә.М.* Драматургия / Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / төз. Р.Ф. Рахмани. 7 т.: 1985–2000 еллар / фәнни мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов. Казан: Фолиант, 2019. Б. 320–346.

*Ибрагимов М.И.* Миф в татарской литературе XX века: проблемы поэтики. Казань: Гуманитария, 2003. 64 с.

*Кириллова И.Ю.* Национальная идентичность и особенности ее отражения в современной драматургии Поволжья // Вестник Чувашского государственного педагогического университета им. И.Я. Яковлева. 2021. № 3. С. 46–52.

*Миңнуллина Ф.Х.* Мансур Гыйләҗев / Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / төз. Р.Ф. Рахмани. 8 т.: 2001–2020 еллар / фәнни мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов. Казан: Фолиант, 2021. Б. 477–493.

*Шарипова А.С.* Художественное воплощение темы судьбы народа в пьесе «Бичура» («Домовой») Мансура Гилязова // Вестник Чувашского государственного педагогического университета им. И.Я. Яковлева. 2022. № 1 (114). С. 127–136.

*Мәкалә «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау»*
*Татарстан Республикасы дәүләт программасының 3.19 номерлы чарасын*
*тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Шәрипова Алсу Сәмигулла кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институты директорының*
*инновацион эшчәнлек һәм тышкы элемтәләр буенча урынбасары*

УДК 821.512.145

***Ф.И. Габидуллина***

# М. ФӘЙЗУЛЛИНАНЫҢ ФӘННИ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ МУСА ҖӘЛИЛ ИҖАТЫ

В статье представлена попытка осмысления личности и творчества поэта Мусы Джалиля в жизни и научной деятельности Магинур Файзуллиной (1901–1983). Автор представляет несколько точек соприкосновения этих личностей: посещение творческих и культурных мероприятий; помощь и поддержка в очень сложных жизненных ситуациях; высокая оценка и попытка объективного описания эволюции творчества поэта со стороны М.Файзуллиной и признание ее как истинного учёного и ценителя татарской поэзии со стороны М. Джалиля.

**Ключевые слова:** М. Файзуллина, М. Джалиль, татарская поэзия, поэма, критическая статья.

The article presents an attempt to comprehend the personality and creativity of the poet Musa Jalil in the life and scientific activity of Maginur Fayzullina. The author presents several points of contact between these personalities: visits to creative and cultural events; assistance and support in very difficult life situations; high appreciation and an attempt to objectively describe the evolution of the poet's work by M. Fayzullina and recognition of her as a true scientist and connoisseur of Tatar poetry by M. Jalil.

**Keywords:** M. Fayzullina, M. Jalil, poetry, poem «The Postman».

XX гасыр ахырында татар халкы тарихында җитди урын алып торып та, төрле сәбәпләр аркасында читкә кагылган яисә аз өйрәнелгән дәверләргә игътибар артып, яңа фәнни тикшеренүләр мәйданга килә. Шуңа нисбәтле татарның иҗтимагый-мәдәни тормышында тирән эз калдырган олы шәхесләрнең тормышы һәм иҗтимагый-мәдәни эшчәнлеге халыкка кире кайтарыла. Хәзер инде киң җәмәгатьчелеккә аз билгеле булып та, милли мәгариф һәм мәдәният үсешенә сизелерлек йогынты ясаган зыялыларыбызның тормышын һәм эшчәнлеген, иҗатын барлау, үз чоры һәм бүгенгебез өчен кыйммәтен билгеләү буенча зур эзләнү һәм тикшеренүләр бара. Әнә шундый үзенчәлекле шәхесләр арасында мөгаллимә, татар хатын-кызлары арасында беренче фәннәр кандидаты, аянычлы да, гыйбрәтле дә язмышлы Маһинур Гайнулла кызы Фәйзуллина да (1901–1983) бар.

М. Фәйзуллинага XX гасырның катлаулы һәм каршылыклы җил-давыллары уртасында калып, күптөрле тормыш сынаулары аша үтәргә туры килә. Ул 1901 елның 13 июнендә казакъ далаларында урнашкан Атбасар шәһәрендә туа. Булачак әдәбият галимәсе, педагог, мәгърифәтче Маһинур Гайнулла кызының үсүе, шәхес булып җитешүе шактый катлаулы шартларда бара. XX гасыр башында татар дөньясында башланып киткән Яңарыш хәрәкәте, укуга, белем алуга, башка халыклар казанышларын, шул исәптән яңа һөнәрләр



Ф.С. Фәйзуллина

үзләштерүгә омтылыш бу төбәккә дә килеп җитә. Тормыштагы үзгәрешләрне ачык тоемлаган әти-әнисе шактый үткен, кыю кызның теләкләренә каршы килми. Гомумән, белемгә омтылыш әнисе Гайниҗамалдан күчкән күркәм сыйфат булган, күрәсең. Бәхетенә, Маһинурның балачагы, җитлегүе хатын-кызларны да хөр, укымышлы итү тенденциясе таралыш алган елларга туры килә. Яңача укыту алымнарына нигезләнгән мәктәптә (анда дини һәм дөньяви фәннәр укытылган) белем алганнан соң, Маһинур Гайнулла кызы Троицк шәһәрендәге мөгаллимнәр хәзерләүче кызлар семинариясенә (дарелмөгаллимат) укырга керә. Монда ул бөтен тормышына йогынты ясаган кызыклы шәхесләр белән очраша. Мәсәлән, уку йорты җитәкчесе – Петербургта Бестужевлар курсын тәмамлаган Рокыя Юнысова – шундыйлардан. Әдәбиятны һәм тарихны Газиз Гобәйдуллин (соңыннан тарих буенча татарның беренче профессоры) укыта. Маһинур Гайнулла кызы семинарияне дәһшәтле 1919 елда «бик яхшы» билгеләренә тәмамлый.

Гаҗәеп чибәр, сәләтле, шул ук вакытта халыкка хезмәт итү дәрте белән янган М. Фәйзуллина үзенә тиң парын таба. Акыллы һәм тырыш кыз «Азат Себер» газетасы редакторы, актив җәмәгать эшлеклесе Хәбиб Вәлиевнең игътибарын җәлеп итә. 1922 елда яшь пар никахларын рәсмиләштерә.



# Свидетельство

Предъявительница сего Магинуръ Гайнуллина Файзуллина окончила курс учения в Троицкомъ Мусульманском 3-ти классном Женском Дарульмуаллимат (женская учительская семинарии) Г. Б. Яушевой, учрежденном на основании закона 1 Июля 1914 года, и при отличном поведении оказала следующие успехи:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1) | Вероучение | 5 | 12) | Физика и химия | 5. |
| 2) | Татарский язык | 5 | 13) | История: татарская, русская, всеобщая | 5. |
| 3) | Русский язык | 5 | 14) | Педагогика | 5. |
| 4) | Арабский язык | 5. | 15) | Рукоделие | 5. |
| 5) | Арифметика | 5 | 16) | Рисование | 5. |
| 6) | Алгебра | 5 | 17) | Чистописание | |
| 7) | Геометрия | | 18) | ~~Основы домашнего хозяйства~~ | |
| 8) | ~~География~~ | | 19) | Пение | |
| 9) | Природоведение | 5. | 20) | Музыка | |
| 10) | Анатомия | 5. | | | |
| 11) | Гигиена | 5. | | | |

а потому, постановлением педагогическаго совета Троицкаго Женскаго дарульмуаллимата от 15 ~~января~~ Августа 1919 года она Магинуръ Файзуллина удостоена звания учительницы мусульманских начальных школ, что и удостоверяется подписью и приложением печати.

~~Января~~ Августа 15 дня 1919 г. Троицк, Оренб. губ.

перевод с подлинным, за надлежащими подписями, верно:

Пр. Председатель П. С. Совета: [signature]

Маһинур Гайнулла кызы Фәйзуллинаның Троицк шәһәрендәге мөгаллимнәр хәзерләүче кызлар семинариясен (дарелмөгаллимат) тәмамлау турындагы таныклыгы

XX гасырның 20 нче елларында М. Фәйзуллина үз белемен күтәрү өстендә эшли башлый, гыйльми, педагогик һәм иҗтимагый эшчәнлеккә чума. Казанга килеп, төрле мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1925 елдан ул Мәскәүдә яши. Шушы елларда «ил башкаласындагы Нариманов исемендәге татар мәктәбендә укыта, аның укучылары арасында булачак күренекле татар язучысы Г. Әпсәләмов та була. Мәктәпкә якын гына урнашкан клубка йөреп, мәдәни чараларда башлап йөри. Шунда ул М. Җәлил белән очраша. 1926 елда Маһинур Фәйзуллинаны Мәскәү елгасы аръягының район Советына депутат итеп сайлыйлар. 1927 елда Мәскәүдә совет хатын-кызларының Бөтенсоюз киңәшмәсе уза, Маһинур Фәйзуллина анда килгән Көнчыгыш хатын-кызлары делегациясенең җитәкчесе була» [Укытучы һәм...]. Казан педагогия институтына укырга кереп, аны 1931 елда уңышлы тәмамлый. Аннары Г. Нигъмәти җитәкчелегендә аспирантура үтә. Әмма Сталин чоры репрессияләре бу гаиләгә дә канлы кулын суза. Татарстанның Җир эшләре буенча халык комиссариаты җитәкчесе урынбасары булып эшләгән ире Хәбиб Вәлиевне, нахак бәла тагып, атып үтерәләр, өч бала белән калган, «халык дошманы хатыны» исемен алган Маһинур Гайнулла кызы коточкыч матди кыенлыкта һәм бигрәк тә эчке рухи тетрәнү халәтендә кала. Казандагы фатирларын тартып алалар. Бу вакыйгаларга кадәр үк М. Фәйзуллинаны өметле галимә, асыл шәхес буларак танып калган кайбер могтәбәр затлар авыр хәлдә калган хатынга ярдәм кулы сузарга тырышалар. Шулар арасында, киләчәктә атаклы каһарман-шагыйрь буларак танылу алачак, ә ул вакытта әле яңа тормыш җырчысы М. Җәлил дә була. 1939 елда Казанга кайткан шагыйрь Маһинур Фәйзуллинаны ярдәменнән ташламый, эш белән дә булыша. Әнә шундый киң күңелле, мәрхәмәтле кешеләр ярдәме белән М. Фәйзуллина фәнни эшчәнлеген актив дәвам иттерә ала.

М. Фәйзуллина поэзия белән бик нык кызыксына башлый һәм катлаулы, каршылыклы тормыш һәм иҗат юлына ия Һ. Такташны өйрәнә башлый. Татар шигъриятен эзлекле үзләштерә барып, Г. Тукай, М. Җәлил шигырь-поэмаларын да тикшеренү объекты итеп ала. Халык шагыйре Г. Тукай белән кызыксынуы яшь галимәне диссертация язуга этәрә һәм 1943 елда М. Фәйзуллина «Буржуаз-демократик инкыйлаблар чорында халык шагыйре Г. Тукай иҗаты» темасына диссертациясен уңышлы яклап, татар хатын-кызлары арасында беренче филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була.

М. Фәйзуллина хезмәтләре арасында М. Җәлил иҗатына багышланган «Муса Җәлил иҗаты турында» һәм «Гражданнар сугышы героикасы» дигән мәкаләләре аерым игътибарга лаек. «Совет әдәбияты» (хәзер «Казан утлары») журналында беренче язма – 1940 елда, ә икенчесе 1948 елда басылып чыга. Әлеге хезмәтләр, бердән, М. Җәлил турындагы беренче монографик мәкаләләр булып торса, икенчедән, авторның фикер-карашлары, шагыйрь иҗатына бәяләмәсе

үзенең ачык-аңлаешлы булуы, эзлеклелеге һәм идея-эстетик фикерләренең бүген дә кыйммәтен югалтмавы белән мөһим.

М. Җәлил иҗаты бүгенге көндә шактый тәфсилле өйрәнелеп, галимнәр тарафыннан төрле аспектта тикшерелгән. М. Фәйзуллинаны бу яктан беренче эзтабар дип атарга була, аның «Муса Җәлил иҗаты турында» язмасы – шагыйрь исән вакытта дөнья күргән беренче монографик мәкалә. Ул шагыйрьнең мөһим бер чор иҗатына тирән бәя бирелү белән үзенчәлекле. Танылган галим һәм язучы Р. Мостафин М. Җәлилнең 25 елны үз эченә алган иҗатын түбәндәге чорларга бүлә: 1) матбугатта басыла башлау, тәҗрибә туплау еллары (1919–1924); 2) комсомол шагыйре булып танылып, журналистика эшчәнлеген киң җәелдергән еллары (1924–1932); 3) өлгергәнлек еллары (Ватан сугышы башланганчы) (1932–1941); 4) фронт лирикасы (1941–1942); 5) Моабит чоры (1942–1944) [Мустафин, б. 12].

М. Фәйзуллина мәкаләсендә, шагыйрьнең беренче тәҗрибә туплау елларыннан башлап, өлгергәнлек елларына кадәрге (1940 ел) иҗаты анализлана. Язмада матур әдәбиятны, тормышны чагылдыручы көзге булудан бигрәк, идеология коралы, укучыга тәэсир итүче көч итеп күрү һәм кабул итү чагылыш таба. Үз чорының җимеше буларак, әдәбият мәйданына яңа гына аяк баскан Җәлил дә әдәбиятны, шигъриятне шул рәвешле кабул итә. Бу хакта М. Фәйзуллина мәкаләсендәге түбәндәге юллар игътибарга лаек: «Бу елларда кылыч белән каләм икесе артык зур аерылмыйлар. Чөнки икесе дә конкрет дошманның йөрәгенә кадалырга билгеләнгәннәр иде. Бу елларда Муса Җәлил, актив комсомолец буларак, ак бандаларга каршы көрәшне оештыру юлында көннәр буенча чаба. Калган вакытта сары кәгазь кисәкләренә үзенең шул көннәрдә янган тойгыларын күчерә бара» [Фәйзуллина, 1940, б. 86]. Мәкалә авторы шагыйрьнең иҗат эволюциясен объектив тасвирлау омтылышы ясый: әдәбиятта беренче адымнарын ясаган яшь шагыйрь иҗатында дошманга каршы көрәшү мотивлары ачык яңгыраса да, алар әлегә сәнгатьчә камиллеккә дәгъва белдерә алмыйлар. Биредә сүз чама белән 1919 еллар хакында бара. Билгеле булганча, М. Җәлил исеме матбугатта тәүге мәртәбә 1919 елда күренә. «Бәхет», «Ил хакына», «Ирек бәйрәмендә», «Кызыл әләмгә» кебек шигырьләре басылу шатлыгы белән дәртләнгән яшүсмер яңадан-яңа шигъри әсәрләр иҗат итә башлый.

Зыялы һәм үзүсешкә әзер һәрбер шәхес үзенең һәм башкаларның эшчәнлегенә тәнкыйть күзлеге аша каравы, иҗатта сыгылмалы юлдан баруы белән аерылып тора. Без моны М. Җәлил иҗатында да ачык күрәбез. Шагыйрь инкыйлаби фикерләргә ритмик һәм рифмалы яңгыраш бирүнең чын шигърият була алмавын бик тиз аңлый, иҗат юнәлешен үзгәртеп, фикер тирәнлеге белән аерылып торган әсәрләр яза, Көнчыгыш классикасына таяна. Мондый үзгәрешләр 1921–1923 елларда күзәтелә. М. Фәйзуллина үзенең мәкаләсендә үзгәрешләрнең сәбәбе, аларга этәргеч бирү шарты буларак, шагыйрь биографиясенә дә мөрәҗәгать итә. Кечкенә генә деталь: ул М. Җәлилнең берничә ай

буена хастаханәдә авырып ятуын аерым игътибарга ала. Бер карaганда, бу – иҗади һәм фикри үсеш белән бәйләнеше булмаган факт кебек. Әмма бүгенге көндә психология фәне кеше тормышында бер генә очраклы вакыйга да булмавын ассызыклый. Айлар буе хастаханәдә яту Җәлилгә язмыш тарафыннан бирелгән сынау гына түгел, ә тормыш, иҗат турында җитди уйлану, сәнгати өлгерү өчен дә кирәк була. Бу елларда ул Хафиз, Сәгъди кебек Шәрык авторлары иҗатын, шул традицияләрне дәвам иттерүче татар шагыйре Дәрдмәнд әсәрләрен ныклап өйрәнә. М. Фәйзуллина Җәлилнең бу еллардагы иҗатын 1923 елда язылган «Әсирлектә» шигыре аша характерлап булуын әйтә. Мәкаләдә теркәлгән юлларга күз салыйк:

*Мәгез инде, тураклагыз тәнемне,*
*Җанымдагы хәрәкәтне ямарсыз.*

[Фәйзуллина, 1940, б. 87].

Шушы чор иҗатына караган «Үлем алдыннан» шигыреннән алынган өзеккә игътибар итик:

*Үләрмен... тик (үкенмим!)*
*бер теләк бар:*
*...Бу күлмәк каплаган изге йөрәк бар.*
*Аңардан акты күлмәккә бу каннар.*
*Алырсыз сез аны миннән мин үлгәч,*
*Эләрсез бер биек талга – күренсен...*

М. Җәлилнең «Үлем алдыннан» (1923), «Әсирлектә» (1923) кебек шигырьләрендә көрәшчегә каршы куелган дошман – илдәге социалистик үзгәрешләрне кабул итмәгән шәхес образы бар. Кайбер шигырьләрендәге ил өчен корбан булган шагыйрь образын ул әйтерсең үзенең киләчәктәге язмышын күреп тудырган. Бу шигырьләрдә М. Фәйзуллина көрәш романтикасы күрә, әмма көрәшнең асылы укучыга аңлашылып җитми. Лирик герой сагышка күмелгән, әмма сагышның да конкрет сәбәпләре аңлашылмый [Фәйзуллина, 1940, б. 86]. Шунысы игътибарга лаек: еллар узу белән Җәлилнең әлеге чор әсәрләрендә дә тирән мәгънә-символлар булуы ачыкланды. Әйтик, югарыда китерелгән өземтә Х. Туфанның «Күлмәгең талда» шигыренә эпиграф була.




М. Фәйзуллина мәкаләсендә «Хат ташучы» поэмасына аерым игътибар бирелә. Әсәр 1938 елда язылган, шагыйрь аны М. Фәйзуллинага да бүләк иткән. Әлеге автографлы нөсхәне галимә гомеренең соңгы көннәренә кадәр кадерләп саклаган. Монысы – М. Фәйзуллина биографиясеннән билгеле факт. Мәкалә авторы гадилекне поэманың

үзенчәлекле ягы буларак аерып чыгара, әмма биредә аны гадәтилек, түбәнлек дип аңларга ярамый. «Зур бер тирәнлеккә ия булган, әйтәсе килгән фикерләрнең эшләнеп конкретлаштырылуыннан, зур проблемаларны вак детальләрдә оста итеп бирә белүдән, гомумән, шагыйрьнең зур талант иясе булуыннан килеп чыккан гадилек» [Фәйзуллина, 1940, б. 92], – дип яза М. Фәйзуллина. Автор тагын бер кызыклы һәм әһәмиятле детальгә игътибар итә: поэманың халык җыры, халык моңы белән сугарылган булуын ассызыклый [Фәйзуллина, 1940, б. 96]. Әлбәттә, «Хат ташучы»дагы образларга, эпизодларны тәфсилләп анализлап, М. Фәйзуллина укучының игътибарын, кечкенә генә аңлашылмаучанлыкка нигезләнгән вазгыять ярдәмендә, әдипнең совет чоры яшьләрен, совет авылында гөрләгән тормышны сурәтләвенә юнәлтә. Һәм бу дөрес тә: поэмада, беркадәр юмор кушылып, совет авылының идиллик тормышы тасвирлана. Биредә хат ташучы хат таратып кына калмый, ул – эшен үз вакытында һәм сыйфатлы итеп башкаручы ударник та әле. Яшьләрнең һәммәсе хезмәтләренә күрә дан казана, авылда хөрлек, күңеллелек, дәрт кебек хис-халәт ташып тора. Болар – совет илен тасвирлауда шул чорда еш кулланыла торган күренешләр. Әмма татарның халыкчан моңын, фольклор белән бәйле җырларны урынлы кертеп җибәрү, гомумән, әсәрне татар җырына тартымлы итеп эшләү – М. Җәлилнең аерым казанышы ул. М. Фәйзуллина әдипнең фольклорга таянып язылган «Алтынчәч» либреттосына да югары бәя бирә.

М. Фәйзуллинаның М. Җәлил иҗаты белән ихлас кызыксынуы биографик фактлар белән дә бәйле. Алдарак, ире «халык дошманы» буларак атып үтерелгән, үзе дә эштән куылган М. Фәйзуллинага М. Җәлилнең булдыра алганча ярдәм итүе хакында әйтелгән иде. Әсирлеккә эләккән М. Җәлилгә ил күләмендә сатлыкҗан, хыянәтче исеме тагылганда, М. Фәйзуллина үз заманында батырлык гамәле кыла: шагыйрьнең хаин була алмавын дәлилләп, «Совет әдәбияты» журналында «Гражданнар сугышы героикасы» дигән мәкалә [Фәйзуллина, 1948] бастыруга ирешә. Галимә анда М. Җәлилне ватанпәрвәр зат буларак тасвирлый, иҗатына сокрлануын белдерә. Автор инкыйлаблардан соң башланып киткән Гражданнар сугышы елларында актив иҗатта булган Г. Камал, М. Гафури, М. Җәлил, М. Максуд, К. Нәҗми кебек әдипләргә тукталa. Һәрберсенең иҗатында көрәшкә әзерлек, яңа туган совет иле өчен фидакярләрчә хезмәт итү, аның идеологиясен җан-рух белән кабул итү мотивлары чагылышына аеруча игътибар бирелә. М. Җәлил иҗатын тикшергәндә, М. Фәйзуллина аның «Сәрби әби» шигыренә һәм «Авыру комсомолец» поэмасына югары бәя бирә. Билгеле, автор аларны үзе яшәгән чор күзлегеннән торып тикшерә, шул чор идеологиясеннән читкә тайпыла алмый. Халык арасында комсомолец-батырларны яратуны автор кечкенә деталь – әбиләрнең дә әлеге сугышчы-каһарманнарга җылы мич өстендә урын бирүе аша ассызыклауга ирешә. Поэмада башта патша төрмәләрендә утырган, аннан «Ленин речен тыңлау бәхетенә ирешкән» шәхесләрнең Гражданнар сугышында аяусыз көрәшче-ватанпәрвәр

зат булып җитешүе тасвирлана. Шул еллар идеологиясен халыкка җиткергән шигърияттә бу – типик образ. Бүгенге көндә Гражданнар сугышы чоры әдәбияты, шул чор вазгыяте, әлбәттә, тирәнрәк, совет идеологиясе кысаларыннан чыгып анализлана.

Билгеле булганча, 1947 елда М. Җәлил, концлагерьга эләгеп, фашистлар ягына чыккан аеруча куркыныч җинаятьче дип танылa. Бары 1952 елда гына татар шагыйренең әсирлеккә эләгүе һәм тоткынлыктагы тормышы буенча алып барылган эш туктатыла, исеме аклана. Әлбәттә, аның тугры исемен кайтаруга күп кешеләр, төрле факторлар йогынты ясый. «Моабит дәфтәрләре» кайту, рус әдибе К. Симоновның шагыйрь исемен агарту буенча эш-гамәле дә эзсез калмый. М. Фәйзуллина исә болай дип яза: «Фронт еллары темасы М. Җәлил иҗатында соңгы елларга кадәр күренекле урын алып торды. Патриот шагыйрь көрәш уты белән янды. Массаны да шул юлда тәрбия итәргә тырышты» [Фәйзуллина, 1948, б. 110]. Җинаятьче дип танылган шәхес иҗатына хакыйкый бәя биреп, аның чын патриот булуын ассызыклап, татарның әйдәп баручы журналында чыгыш ясавы М. Фәйзуллинаның галимә генә түгел, батыр рухлы зат булуын да ачык күрсәтә.

Шулай итеп, М. Фәйзуллина тормышын һәм эшчәнлеген киң җәмәгатьчелеккә җиткерү, хезмәтләренә бәя биреп, үз вакыты һәм бүгенгебез өчен кыйммәтен билгеләү сорала. М. Җәлил үзе исән вакытта дөнья күргән «Муса Җәлил иҗаты турында» монографик мәкаләсе шагыйрь иҗатын биографик методка нигезләнеп тикшерүнең уңышлы үрнәге булып тора. Ә инде 1948 елда басылган «Гражданнар сугышы героикасы» язмасы каршылыклы чорга нисбәтле рәвештә яшь шагыйрь иҗатындагы аерым үзенчәлекләрне аерып чыгаруы белән игътибарга лаек. М. Фәйзуллина, билгеле, заман вазгыяте йогынтысыннан азат була алмый, әмма беренче мәкалә – М. Җәлилнең сугышка кадәрге иҗатына комплекслы анализ ясау омтылышы, икенчесе шагыйрьнең үз чоры шигърияте үсешенә йогынтысын ачыклавы, объективлыгы белән бүген дә кыйммәтен югалтмый.

**Әдәбият**

*Мустафин Р.* Страницы героической жизни (Муса Джалиль) // Силуэты: литературные портреты писталей Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. С. 111–153.

Укытучы һәм остаз елына: Татарстанның беренче хатын-кыз филологы Маһинур Фәйзуллина // Алабуга нуры. URL: https://alabuganury.ru/news/maxsus-proekt/ukytucy-ham-ostaz-elyna-tatarstannyn-berence-xatyn-kyz-filology-mahinur-faizullina; мөрәҗәгать итү вакыты: 24.11.2023.

*Фәйзуллина М.* Муса Җәлил иҗады турында // Совет әдәбияты. 1940. № 3. Б. 85–95.

*Фәйзуллина М.* Гражданнар сугышы героикасы // Совет әдәбияты. 1948. № 2. Б. 105–117.

***Габидуллина Фәридә Имаметдин кызы***,
*филология фәннәре кандидаты, КФУның Алабуга институты доценты*

УДК 821.512.145

***Р.Ф. Бәдретдинов***

# ЯЗУЧЫ АФЗАЛ ТАҺИРОВНЫҢ ТОРМЫШ ҺӘМ ИҖАТ ЮЛЫНА КҮЗӘТҮ

В статье прослеживается жизненный и творческий путь татарского прозаика, общественного деятеля, драматурга Афзала Тагирова. Учитывая, что творческий путь писателя изучен не в полной мере, автором статьи проведена кропотливая работа по сбору новых сведений о его жизнедеятельности. Особенностью статьи является то, что образ А. Тагирова в ней рассматривается в тесной связи с историческими событиями, происходящими в то время в стране, где он жил и работал. Автор статьи даёт анализ каждому периоду его жизни и творчества, подчеркивает трагичность судьбы писателя, рассказывает о крепком духе, необыкновеннной преданности истории, литературному делу, искусству, анализирует литературные произведения, принадлежащие А. Тагирову.

**Ключевые слова:** Афзал Тагиров, жизнь, творческий путь, татарский народ, статья, автор, литература, прозаик, драматург, анализ, проблема, произведения.

The article traces the life and creative path of the Tatar prose writer, public figure and playwright Afzal Tagirov. Considering that the writer's creative path has not been fully studied, the author of the article has carried out painstaking work to collect new information about his life. The peculiarity of the article is that the image of A. Tagirov is considered in it in close connection with the historical events taking place at that time in the country where A. Tagirov lived and worked. The author of the article gives a deep analysis of each period of his life and work, emphasizes the tragedy of the writer's fate, talks about his strong spirit, extraordinary devotion to history, literature, art and analyzes literary works belonging to A. Tagirov.

**Keywords:** Afzal Tagirov, life, creative path, Tatar people, article, author, literature, prose writer, playwright, analysis, problem, works.

Татар әдәбиятының үткән юлы гомумкешелек идеяләре югарылыгында иҗат ителгән әсәрләргә бик тә бай: мотивлар төрле, иҗат принциплары үзгә. Әлеге байлыкның шактый өлеше һаман да киң җәмәгатьчелек өчен генә түгел, хәтта фәнни даирәгә дә аз билгеле. Үткәннәр караңгылыгында калган тарихи-әдәби мирасыбыз яңа заман әдәбият мәйданында үз урынын алырга бердәй лаек, бердәй хокуклы. Мәдәниятебез, әдәбиятыбыз, сәнгатебез идеология кытыршылыклары әйләндереп алган кыршаулардан азат булган үзгәртеп кору чорында – милләтне рухи кыйммәтләр белән баету өчен уңайлы җирлек туган бер чакта – татар җәмәгатьчелегенә, аның иҗтимагый фикер сөрешенә, меңьеллыклар белән исәпләнгән татар әдәбияты тарихына язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Афзал Мөхетдин улы Таһиров (1890–1937) исеме дә кире кайтты. 70 тән артык хикәя, повесть, пьеса, роман, дилогияләре белән кайчандыр әдәбият мәйданында исеме

шактый танылу алган Афзал Таһиров – сәяси-иҗтимагый сәбәпләр аркасында игътибардан читтә кала килгән иде.

А. Таһировның тормышы, иҗаты катлаулы һәм каршылыклы да. Ул 1890 елның 25 октябрендә Әлмәт районы Габдрахман авылында дөньяга килгән. Ике кыш туган авылында мәдрәсәдә белем алган. Әмма укуы өзелгән, яшьли ятим калып, тормыш авырлыкларын үз җилкәсендә татып үскән. 1903 елның җәендә абыйлары Закир, Баһман, Дәрҗеман, Каюм белән бергәләп, тамак ялына Врачевка боярына ашлык, сабан эшләренә барып ялланганнар. Әмма белемгә сусау үзенекен иткән. Афзал Әлмәткә барып, Һади Атласовның ысулы җәдит мәдрәсәсендә укый башлаган. Кичләрен Ш. Әхмәровтан география, тарих фәннәреннән дәресләр алуы беленеп, мәдрәсәдән куылган, Казанга киткән. «Мөхәммәдия» ишеген шакыган егетне кочак җәеп каршы алмыйлар, ул «Мәрҗания»гә самавырчы, аш пешерүче, йомышчы малай булып эшкә урнаша. Пороховойдагы укытучы авылдашы Вәли Мөэминов һәм шунда ук рус теле укыткан Г. Коләхмәтов белән аралаша, акрынлап иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Унбиш яшеннән Казан, Оренбург шәһәрләрендәге мәдрәсәләрдә белем ала. Ләкин революцион характердагы листовкалар таратуда гаепләнеп, бу мәдрәсәләрдән дә куыла, кире авылга кайтып, крестьян чуалышларында катнаша. 1907 елда Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенең әзерлек курсына укырга керә, яшерен әдәбият түгәрәге оештыра, үзенең шигырь һәм хикәяләрен шунда укый. 1907 елны беренче әсәре «Бичура»ны яза.

«...А. Таһиров “Хөсәения” дә укыганда укучылар арасында, әдип булудан бигрәк, шагыйрь булып танылды. Аның гарәпчәдән, урысчадан тәрҗемә ителгән һәм үзе тарафыннан оригиналдан төзелгән шигырьләре байтак бар иде. Алар 1911 елда бер мәҗмуга хәленә кителгән иде»,– дип яза үз истәлекләрендә бергә укыган дусты Гариф Китабов [Китабов, б. 17–20]. «Шура» журналында аның шигырьләре дә чыга [Таһиров, б. 16]. Бу вакытта ул Мөхетдинов, Афзалетдинов, Әфзалетдин, Ә. Мөхетдин, А. Та, Әбү Таһир тәхәллүсләре белән басыла.

А. Таһиров язган шигырьләр тупланмасының язмышы Фатих Сөләйманов дигән кешегә барып тоташа. Г. Китабов язганча: «Таһиров солдатка киткәндә (1911 елда) үзенең кульязма “Шигырьләр мәҗмугасы”н һәм тагы хикәяләрдән торган берничә җыентыгын миңа биреп калдырган иде, Оренбург жандарм идарәсе 1915 елның апрель аенда мине кулга алды. Бөтен язу, Таһировның кульязмалары, хатлары шул чакта конфисковать ителде һәм кабат кайтарылмады, шунда югалды», – ди [Китабов, б. 17–20]. Афзал Таһировның солдат хезмәтендә дә күп кенә шигырьләр язуы мәгълүм һәм ул аларны, хат аша, дусты Г. Китабовка җибәреп барган. А. Таһиров соравы буенча, Г. Китабов аның хатларын саклаган, ә шигырьләрен аерым җыентыкка теркәгән.

«Таһировның кулъязма хикәяләре, халык әдәбиятының тупланган хәзинәсе: җырлар, бәетләр, такмаклар, такмазалар җыентыгы аның якын иптәшләреннән булган Фатих Сөләймановта да бар иде», – дип яза Г. Китабов [Китабов, б. 17–20]. Димәк, А. Таһиров фольклор үрнәкләрен туплау белән дә шөгыльләнгән. Бу турыда Хәсән Гали дә: «А. Таһиров үз иҗаты өстендә эшләү белән бергә халык иҗаты булган авыл әдәбияты өстендә дә күп кенә эшләгән: мәкальләр, табышмаклар, әкиятләр, бәетләр җыйган. Аның тарафыннан төзелгән “Уеннар”-да халык иҗатының күп кенә үрнәкләре бар», – дигән фикерләрен җиткерә [Гали, 1932].

А. Таһиров 1911 елда, яше җитеп, патша армиясенә алына. Ул анда 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр хезмәт итә. 1913 елда яшерен рәвештә РСДРП сафларына керә. Гражданнар сугышы башлану белән илне сакларга чакырыла. Совет власте урнаштыру өчен Урта Азиягә җибәрелә, Үзбәкстанда полк командиры була.

Илдә беркадәр тынычлык урнашкач, Оренбургта «Пролетариат сүзе» газетасын чыгара башлый. А. Таһировның укытучы булып эшләве дә мәгълүм. Аның шулай ук, авылдан авылга йөреп, халык авыз иҗатын җыюы, фольклорчы Фазыл Туйкә белән берлектә «Тирмән» исемле кулъязма сатирик журнал бастыруы, Оренбургта «Юксыллар сүзе» газетасы мөхәррире булуы да билгеле. 1922–1925 елларда А. Таһиров Үзбәкстанда төрле җитәкче урыннарда эшли. Хезмәт ордены белән бүләкләнә. Хива өлкә комитетының агитпроп мөдире, «Инкыйлаб кояшы» газетасы мөхәррире вазифаларын да башкара.

1925–1927 елларда әдип Мәскәүдә Комакадемиядә укый. Аны тәмамлагач, А. Таһиров Башкортстанга җибәрелә. 1931 елда ул Башкортстан Үзәк Башкарма комитеты Рәисе итеп билгеләнә һәм репрессияләнгәнче (1937 елга кадәр) шунда яши һәм эшли. Бер үк вакытта Башкортстан Язучылар берлеген оештыра һәм аның җитәкчесе дә була.

А. Таһиров 1932–1935 елларда СССР Үзәк Башкарма комитеты Президиумы әгъзасы итеп сайлана. 1935–1936 елларда мәдәни бәйләнешләр буенча совет делегациясе составында Истанбул, Әнкара, Париж, Версаль һәм башка шәһәрләрдә була.

Гаҗәеп киң эрудицияле, белемле һәм үткен карашлы А. Таһировның, Мәскәүгә барып, Бөтенсоюз Язучылар съездында чыгыш ясавы, Максим Горький белән очрашуы да билгеле. Бу турыда ул: «Алексей Максимовичны читтән күргәнем булса да, үзе белән танышлыгым юк иде әле. 1932 елның 29 июнендә аның белән күрешеп сөйләштем... Үзе килеп күреште һәм бүлмәсенә кадәр кулны ычкындырмады», – дип искә ала.

XX гасыр башы татар дөньясының эчке хасиятен милли чынбарлыктан аерылмыйча тәфсилле итеп чагылдыру осталыгына ия булган А. Таһировны 1937 елның 16 августында, «халык дошманы» дип, нахакка гаепләп кулга алалар һәм атарга хөкем итәләр. Хөкем карары 27 августта Мәскәүдә җиренә җиткерелә.

Татар әдәбиятында иҗат кредосының үзенчәлекле булуы ягыннан һәм үзе яшәгән дәвернең иҗтимагый-сәяси йөзен ачып бирүдәге объективлыгы, совет чынбарлыгын яктыртуда, аның эстетик-идеологик эволюциясенең төп тенденцияләрен, юнәлешләрен чагылдыруда А. Таһиров исеме, аның милли тарих сәхифәләрендә тирән эз калдырган иҗади мирасы аерым урын алып тора. Классик образлар иҗат итеп, әсәрләренең мәгънәви төсмере, фәлсәфи карашлары, лирик-психологик хасияте калку чагылыш тапкан булу аның XX гасыр башында ук танылуына сәбәп була.

Тоталитар системаны сискәндергән әсәрләрендәге милли мотив, тарихыбызны яңача бәяләү, халкыбызның дине, гореф-гадәтләре, яшәеш-көнкүреш мәсьәләләрен хакыйкый җирлектә ачу күренешләре, кешелеклелек идеяләре югарылыгында сурәтләнгән образлары шул чор совет хакимиятенең каршылыгына очрый һәм А. Таһировның язмышы да күпләгән татар зыялыларыныкы кебек фаҗигалы тәмамлана. Иҗат эшчәнлеген большевиклар заманында бөек идеаллар белән рухланып башлаган А. Таһиров, үзе үк нигез ташларын салышкан тоталитар системаның корбанына әйләнә, халык хәтереннән сызып ташлана, «онытылуга» дучар ителә. Башка бик күп татар әдипләренеке кебек үк, аның да иҗади мирасы юкка чыгарыла.

Ниһаять, «җепшеклек чорында», төгәлрәге, 1960 елларда, нахакка рәнҗетелгән әдипләребезнең иҗатын яңадан халыкка кайтару башлана. Татарстан китап нәшриятында А. Таһировның да өч томлык әсәрләр җыелмасын чыгару планлаштырыла, ләкин эш тоткарлана. Бары яңа гасыр башында гына (2008 елда) әдипнең «Сайланма әсәрләре» [Таһиров, 2008, 472 б.] дөнья күрә.

Аның «Ил өреккәндә» (1912), «Әтрәгәләмнәр» (1916), «Шайтан» (1917), «Ач-ялангачлар» (1918) әсәрләрендә татар халкының азатлык өчен көрәш мәйданында тоткан кыйбласы, әлеге чорда күләгәдә калган ак таплар бөтен тулылыгы белән ачыла. Авыл хуҗалыгы, җитештерү, сәнәгать темасы киң урын алган «Иген фабрикасы» (1930), «Штурвалчы» (1931), «Машиналар каны» (1932) әсәрләрендә киң һәм әтрафлы яктыртылган образлар авыл халкының, гади эшче көчләрнең эчке һәм тышкы хасиятен калку яктырта, чын асылын ачып бирә, тарихи җирлек яссылыгында бәян ителә.

«Солдатлар» романы – ил-дәүләтнең тотрыксызлыгы, армия һәм андагы гаделсезлекләр, җитәкчелекнең дөрес карарлар кабул итмәве аркасында килеп туган башбаштаклыклар турында. Кеше һәм җәмгыять язмышы проблемасын, килеп туган вазгыятьнең гаеплеләрен ачуга корылган тарихи фон, тынычлыкның кадере, аны туздыручыларга карата тирән нәфрәт, төгәл сюжет сызыгы, уңай яки кире герой дип тамга салмыйча, бердәй таләпләр үрнәгендә бирелгән образлар бөтенлеге – әдипнең табышы, татар әдәбиятына алып кергән яңалыгы.

Хаксызга рәнҗетелгән каһарманның җуелмас мирасы бүгенге көндә, акрынлап барлана, өйрәнелә. А. Таһиров һәрвакыт милләт мәнфәгате белән яшәгән. Ул еш кына тарихка мөрәҗәгать итеп, милли

асылыбызны эзли. Тарихи чынбарлык аша әдипнең «Янгура», «Күчү чорында», «Ямәлкә тавы» (Пугачёвтан калган архив материаллары буенча) әсәрләре языла. Аларда Татарстан, татар авыллары, географик атамалар, татар халкының мәкаль-әйтемнәре, җырлары шактый чагылыш тапкан.

Аның «Сатылган кызлар» (1908), «Мәзлумәләр» (1909), «Ил өреккәндә» (1912), «Әтрәгәләмнәр» (1916), «Шайтан» (1917), «Ямәлкә тавы» (1929), «Штурвалчы» (1932), «Солдатлар» (1933), «Кызылгвардиячеләр», «Кызылармиячеләр» (1936) һ.б. бик күп әсәрләрендә яшәеш, ил-көн язмышы, гади халыкның коточкыч авыр хәле, аянычлы язмышы, татар тарихы, хәрбиләрнең хәле бәян ителә.

А. Таһировның «Ямәлкә тавы» (1927) исемле тарихи хикәясендә урын алган әшәкелек, җәберләү күренешләре укучыда патша иярченнәренә карата нәфрәт уята. Әлеге мәхшәрне кичергән герой халык азатлыгы хакына җәзалана, ахыр чиктә, рәнҗүле карашын калдырып, бакый дөньяга күчә. Әсәрдән күренгәнчә, авторның милләтпәрвәрлек, милләт кайгысы белән яшәү, киләчәк хакында уйлану кебек сыйфатлары беренче планга чыга. Миллилек тойгыларын гәүдәләндергән, шуның асыл сыйфатларын чагылдырган, гаҗәеп моңлы аккордларга күмелгән мизгелләр бирәүне дә битараф калдырмый. Миллилек әсәрнең төп сюжет сызыгында ук күренә. Татар егете Габдрахманның фаҗигасы – татар халкы фаҗигасы ул.

Әсәрнең актуальлеге – халык язмышын чагылдыруда, милли тойгыларга ихтирамның кимүен ассызыклауда. Анда күтәрелгән проблемалар бүген дә актуаль. Хикәядә кешенең шәхес буларак уянуы, замана хәлләре белән актив кызыксынуы, иске тәртипләрне тәнкыйть итүе, тигезлек идеяләрен алга сөрүе ачык сизелә. Шәхес дөньяви уй-хисләр белән янып яши. Әсәрдә автор хатын-кыз язмышы мәсьәләсен дә күтәрә. Чит-ятлар тарафыннан кыерсытылган Зөләйха образы нәкъ шул турыда сөйли.

Әсәр ахырында яшел бәбкә үләненә күмелгән биек тау уй-хыялларның, рухи кыйммәтләрнең, чиста, пакь булуын гәүдәләндерә. Кеше никадәр авырлык, михнәт күрмәсен, рухы пакь булса, беркайчан түбән тәгәрәми, ә биек таулар булып күккә аша. Символлар белән тәгаенләнгән сюжет сызыгы – авторның моңарчы очрамаган үзгә табышы.

А. Таһиров гасырлар алышынган чорда татар әдәбиятының иҗат мөмкинлекләрен арттырып, чикләрен киңәйтеп, үзгә бер формада иҗат итә. Башка берәүне дә кабатламыйча, үз фикерен саллы образ-сурәтләр аша укучыга җиткерү осталыгы күрсәтә. Чыннан да, аның әсәрләре кичерешләргә бик бай, хисләр агышы, мәгънә тирәнлеген тәэмин иткән символлар көчле. Якты киләчәккә өмет белән караган Габдрахман, изге юлда шәһит китеп булса да, намусына хыянәт итми. Күрәсең, рухи якның бөтенлегенә хилафлык китерергә теләми автор, геройларын үлемсез итеп сурәтли.

А. Таһировның «Янгура» (1913) дип исемләнеп, тарихи фаҗига дип аталган әсәрендә дә сюжет сызыгы милли каршылыкка корылган. Анда әсәр героеның милли чынбарлыкны аерып тергезү юлындагы милли фәлсәфәсе тәкъдим ителә. Халык каһарманы Янгура турындагы фикерләре әсәрнең идея-эстетик сурәтен ачарга ярдәм итә: «Менә халык батыры, аны никадәр җәзалыйлар, ул һаман үз сүзеннән кайтмый, үз чынлыгын ташламый. Кичә мескенне исеннән яздырганчы кыйнап чыгып киттеләр. Ул үзенең дошман кулында тоткын икәнен белсә дә, халык каһарманы икәнлеген онытмый, әйтәсе сүзен әйтә, дошманнарыннан курыкмый. Әйе, ул әйтергә тиеш.., без... без халык ирекчеләренең калдыклары, без иксез-чиксез диңгездә йөзә торган ирек көймәләренең йомычкалары, көймәне йөртүчеләрнең иреклеге аркасында юлсыз урынга кереп, ташка бәрелеп ватылган көймәнең калдык такталарын язгы, каты куркынычлы диңгез дулкыннары бәрәләр, бер урыннан икенче урынга ыргыталар, ләкин ул дулкыннар безне никадәр ыргытсалар да, үзләре кеби рәхимсез йөзне, куркыныч диңгез суына әверелдерә алмаслар, без һаман шул ирекле көймәнең кисәкләре булып калачакбыз, шул дулкыннар бервакытны безне яр читенә чыгарырлар да, утынга аптырап йөрүче берәр фәкыйрь безне кызганып алып киптерер, ул кеше безнең ирекле көймә такталары икәнлегебезне белер, аның күз алдында көймәдә һәлак булган ирек сөюче кызганыч халык гәүдәләре басарлар, шулвакыт ул кеше аларны кызганыр, көймә йөртә белмәүчеләргә ләгънәт укыр» [Таһиров, 1927, б. 40].

Әлеге юллардан күренгәнчә, автор игътибарын 1552 елгы Казанны басып алу күренешләренә юнәлтә, дәүләтчелегебезне югалтуга ишарә ясый. Автор, татар язучысы буларак, халык хәтере турында уйлана һәм борчылып ачыргаланып яза. Әлеге әсәрне без милли-фәлсәфи әсәр дип атар идек. Чөнки ул кеше, яшәеш, үткән һәм бүгенге хакында фикер йөртеп, чагыштырулар ясап язылган. Ул кайбер яклары белән Америка язучысы Эрнест Хемингуэйның «Карт һәм диңгез» («Старик и море») әсәре белән аваздаш. Анда да Куба халкының тормыш-көнкүреше, уй-ниятләре, ирекkә омтылуы тасвирланган күренешләр берәүне дә битараф калдырмый. Ике әсәрдәге милли мотивлар да үзара охшаш.

А. Таһировның «Янгура» драмасында яңгыраган тагын бер көчле фикер бар: «Дулкыннар безне никадәр ыргытсалар да, үзләре кебек рәхимсез диңгез суына әверелдерә алмаслар», – дигән юллар Дәрдмәнднең (1859–1921) «Кораб» шигырендәгегә аваздаш.

Күргәнебезчә, Дәрдмәнд тә, Э. Хемингуэй да, А. Таһиров та милли-символик яңгырашка ия булган детальләр белән эш итәләр. Аларның әсәрләрендә бәйсезлек төшенчәсенең никадәр кадерле булуы күрсәтелә. Ирекле кешедә генә була торган якты омтылышлар, олы максатлар тәгаенләнә. Ә инде колларның өметләре, хыял-максатлары канатсыз. Язучы бу әсәрендә кеше, буыннар һәм милләт фаҗигасын ул яшәгән тирәлек, идарә итүче система һәм коллык

психологиясе белән дә аңлата. «Мин ачык беләм, халык кулыннан ирек алынды, бүгенгә кадәр иркен яшәп килгән татар, нугай балалары башкалар кулында кол булып калдылар... алар бүтәннәр тырнагында изелсәләр дә, шул мөкатдәс иреккә чыгарга тырышалар, шул юлда үзләрен корбан кыйлучылар да булыр, аларның араларында халык ирке өчен тартышучыларның берсе асылса, изелсә, киселсә, аның урынына йөзләп икенчеләре җитешер! Шушы үзем ышанган динемдә татар баласы булып үлүемнән разый», – ди Яңгура каһарман, татар булуы белән горурланып.

Оренбургта яшәгәндә Афзал Таһиров 1921–1922 елларда Идел-Урал буйларындагы ачлыкны күреп, аның төп сәбәпләрен әдәби әсәрендә чагылдырырга тели. Әмма моны турыдан-туры язып чыкмый. Язучы аны тарихи җирлеккә юнәлдереп, тарихи шәхесләр йогынтысы белән аңлата. «Янгура» драмасы исә әнә шундый киң колачлы әсәрләрнең берсе буларак танылу ала. Драма Г. Ибраһимов, Г. Толымбай, Г. Сәгъдинең көчле тәнкыйтенә дучар була. 1923 елда язылган «Күчү чорында» исемле әсәре дә алдагысына аваздаш. «Янгура»га ябырылган тәнкыйтьнең төбендә ни ятканын яхшы аңлап, А. Таһиров 1921 елгы ачлык темасына икенче яктан якын килә. Хәзер инде ачлыкны тудыручылар итеп кулаклар, спекулянтлар, руханилар күрсәтелә. Г. Сәгъди бу пьесага уңай бәя бирә. Татарстан Халык мәгариф комиссариаты каршындагы Гыйльми Үзәк тарафыннан уздырылган сәхнә әсәрләре бәйгесендә әлеге пьеса аерым бүләккә лаек дип табыла.

Патша гаскәрендәге гади солдатның авыр, аянычлы хәрби хезмәтен күрсәтү белән башланып киткән «Солдатлар» романының 1931, 1933 елларда басылып чыгуы А. Таһировның зур күләмле тарихи темаларга керә алырлык үтемле сүз һәм каләм остасы булуын күрсәтә.

Драматургия өлкәсендә дә А. Таһировның укып гыйбрәт алырлык әсәрләре бар. «Ач-ялангачлар», «Уеннан уймак», «Кияү белән кәләш», «Алатау» пьесалары – әнә шундыйлардан.

70 тән артык хикәя, повесть, роман, пьесалар язган әдипнең әсәрләренә, беренчеләрдән булып, галим М. Әхмәтҗанов мөрәҗәгать итте. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә А. Таһиров фонды булдырылды. Эзләнүләр әле дә дәвам итә, аерым фактлар ачыклана. Мәсәлән, Казан хореография училищесы укытучысы, танылган балет остасы, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Нинель Юлтыева (язучы Давыт Юлтыйның кызы) белән Афзал Таһировның кызы – Башкортстан опера һәм балет театрында биегән, Россиянең атказанган артисты Майя Таһирова хореография училищесында бергә укыганнар. Алар икесе дә бүген безнең арада юк инде. А. Таһиров кызының язмышы да аянычлы төгәлләнгән. 1937 елда «шпионлыкта» гаепләнеп, атарга хөкем ителгән, шунлыктан барлык китаплары яндырылган А. Таһировның нәсел шәҗәрәсе шуның белән өзелгән.

Шулай итеп, Афзал Таһировның милли яссылыктагы фикер үсеше гаҗәеп үзенчәлекле, башка берәүне дә кабатламый торган тәэсирле әсәрләре татар тарихында тирән эз калдырган. Хикәяләрендәге чор тудырган каршылык аша хәрәкәт итән фәлсәфи җирлек бүген дә актуаль. Әлеге мирасның кадере торган саен ачыла бара, аның бай һәм матур әдәби иҗатына яңадан-яңа штрихлар өстәлә. Киләчәктә әдипнең исеме киң катлау укучыларга барып ирешер һәм әсәрләре милли сәнгатебез тарихын баетыр.

**Әдәбият**

*Әфзалетдин.* Булмаса // Шура. 1911. № 16. Б. 16–50.

*Әхмәтҗанов М.* Әдип һәм драматург // Мирас. 2001. № 8. Б. 115–117.

*Бәдретдинов Р.Ф.* Каһәрле еллар корбаны. Казан: Ихлас, 2010. 175 б.

*Баһманов С.* Хаксыз онытылган талант // Мәйдан. 2007. № 12. Б. 56–57.

*Заһидуллина Д.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр: Монография. Казан. Мәгариф, 2006.

*Ибраһимов Г.* «Янгура» уйналуы мөнәсәбәте белән // Татарстан хәбәрләре. 1922. 31 гыйнвар.

*Китабов Г.* Афзал Таһиров Оренбургта // Октябрь. 1934. № 5–6. Б. 17–20.

Книга Памяти жертв политических репрессий. Т. 14. Казан. Книга Памяти. 2005.

*Нуруллин И.* XX йөз башы татар әдәбияты. Казан ун-ты нәшр., 1966. 305 б.

*Поварисов С.* Афзал Таһиров // Мәдәни җомга. 2001. 25 октябрь.

*Сәгъди Г.* Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты // Мирас. 2007. № 8. Б. 40.

*Таһиров А.* Шагыйрь турында истәлек // Яңалиф. 1936. № 4. Б. 23–27.

*Таһиров А.* Солдатлар. Казан: Татиздат, 1933. 286 б.

*Таһиров А*. Хикәяләр. Казан: Татиздат, 1935. 268 б.

*Таһиров А*. Сайланма әсәрләр. Рухият, 2008. 471 б.

*Таһиров А*. Мин ничек үстем // Октябрь. 1934. № 5. Б. 2–5.

*Таһиров А*. Язучылык турында // Октябрь. 1934. № 5–6. Б. 5–6.

***Бәдретдинов Рәҗәп Фәтхетдин улы,***
*филология фәннәре кандидаты*

УДК 82-131

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# ТАТАР ЭПОС-ДАСТАНЫ: ТӨП ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ, БҮГЕНГЕ ТОРЫШЫ

Статья посвящена исследованию особенностей эпического наследия татар. Автор обращается к проблемам генезиса национального эпоса, выявляет общее между различными преемственно переходящими через века татарскими вариантами дастанов на известные сюжеты, характеризует дастаны как источники в воссоздании истории народа. Интерпретируя и исследуя национальное эпическое наследие, автор выявляет, что дастаны татар – удивительный локальный пласт, хронологически восходящий к глубоким корням, географически охватывающий неиссякаемое эпическое наследие многих народов; акцентирует внимание на роли письменной культуры в развитии национального эпоса; уделяет внимание на собирание и изучение дастанов на современном этапе; отмечает актуальность и важность татарских дастанов и дастанных традиций не только для филологической или исторической науки, но и для современной литературы, искусства, образования и в целом общественной жизни.

**Ключевые слова:** татарское эпическое наследие, дастаны, предпосылки формирования жанра, письменная культура татар, фольклорные традиции.

The article is devoted to the study of the features of the epic heritage of the Tatars. The author addresses the problems of the genesis of the national epic, identifies the commonality between various Tatar versions of dastans on well-known subjects that have been passed on through the centuries, and characterizes dastans as sources in reconstructing the history of the people. Interpreting and exploring the national epic heritage, the author reveals that the epic dastans of the Tatars are an amazing local layer, chronologically going back to deep roots, geographically covering the inexhaustible epic heritage of many peoples associated with the Tatars; focuses on the role of written culture in the development of the national epic; pays attention to the collection and study of dastans at the present stage; notes the relevance and importance of Tatar dastans and dastan traditions not only for philological or historical science but also for modern literature, art, education and social life in general.

**Keywords:** Tatar epic heritage, dastans, prerequisites for the formation of the genre, written culture of the Tatars, folklore traditions.

Татар халкында дастан барлыкка килү тенденциясе һәм эпик иҗатка омтылышның тамырлары тирәндә. Тарихта халык күңелен тетрәндерерлек вакыйгалар булган икән, алар һәрвакыт зур иҗат булып бәреп чykканнар һәм күләмле җитди әсәр буларак танылганнар. Дәүләт тоткан халыкның озын-озак тарихы андый вакыйгаларга бай. Татарларның эпос-дастанлы халык булуы әнә шул тарихка барып тоташа.

Татар дастаны «эпос» дигән төшенчәне дә, «хикәяләп бирү», «тарих сөйләү» дигәнне дә, «поэма» дигән мәгънәне дә үз эченә ала.

Дастанда һәрвакыт каһарман була. Халык телендә аларны «батыр» дип атау бар. Зур батырлар зур вакыйгалар барышында туа. Батыр ул – халык өчен әһәмияте биниһая вакыйгаларда кыю катнашучы көрәшче, гадәттән тыш батырлыклар кылучы ир-егет. Мондый батырлар ил азатлыгы, халык бәхете өчен югары идеяләрне тормышка ашырам дип көрәшеп яшиләр, көрәш юлында я стихияле табигать көчләре, я идарәче түрәләр, я аерым бер кеше, я язмыш белән каршылыкка кереп, гадәттә һәлакәткә дучар булалар. Менә шундый гадәттән тыш көчле рухлы батырларның тууы, үсүе, көченең ташып торып, куәтен илен-халкын, сөйгәнен яклау-саклау максатында кулланыуы, тарихи җирлеккә ия зур вакыйгалар эчендә акылы-куәте белән массадан аерылып торуы, зур эшләр башкаруы хакында нейтраль формада сөйләп-хикәяләүне җырлар, сарын, тулгаулар, елау-сыктау, назымнар кебек тезмә юллар белән аралаштыру яисә тоташ шигъри тезмәдә бирү дастан дип атала. Дастанда алга хис-кичерешләр түгел, ә халык тормышының эпик картинасы чыгарыла, сурәт һәр детальдә сәнгати югарылыкны саклап, сабыр гына, хәтта фаҗигаи күренешләргә дә мөнәсәбәтне ачыктан-ачык белдерми генә тудырыла. Шушыларның барысын да исәпкә алып, фольклор кануннарын тиешле дәрәҗәдә үтәп оешкан катлаулы бер әсәрне эпос-дастан дибез. Татар дастаны батырлык темасы белән бергә ике гашыйкның мәхәббәт тарихын да бәян итә, төзелеше белән тоташ шигъри, чәчмә яисә катнаш характерда була.

Вакыйгаларны бәян итү ысулына, поэтик үзенчәлекләренә, эчтәлегенә һәм күбрәк кайсы темага багышланган булуына мөнәсәбәттә татар дастаннарын ике зур төркемдә карарга мөмкин: героик дастаннар («Түләк», «Идегәй», «Гыйсә улы Амәт», «Чыңгыз хан», «Аксак Тимер», «Кыйссаи Сәкам», «Каһарман Катил», «Җик мәргән», «Нарык һәм Чураның хикәяте», «Күр углы Солтан» һ.б.) һәм романик дастаннар («Таһир белән Зөһрә», «Бүз егет», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Йосыф китабы», «Шаһсәнәм һәм Гариб», «Хурлуга белән Һәмра», «Сәйфелмөлек», «Мактым-сылу» һ.б.). Романик дастаннарны, нәкъ менә темасыннан-эчтәлегеннән чыгып, мәхәббәт дастаннары дип атау да бар.

Эпосны халыкка җиткерүче кешеләрне төрле халык төрле исем белән атап йөрткән. Борынгы греклар аларны аэдлар дип атаган, борынгы һинд эпосын әйтүчеләрне сут яки кушелавлар дип йөрткәннәр, Көнбатыш Африкада бу төр шөгыль ияләре гриотлар, Көнбатыш Европада шпильманнар дип аталган, славяннарның сказительләре, кобзарьлары булган. Монгол телле бурятларда мондый осталарны улигершин яисә гесершин, калмыкларда җангарчы, алтайдагы төрки булмаган кайбер халыкларда хайджи дип атау кабул ителгән. Халыкка эпос-дастан җиткерүчеләрнең төрки халыкларда да исемнәре төрле: олонхосут, шагыйрь, җомакчы, ашуг, бахшы, сәсән яки кобайырчы, акын, манасчы, кыйссахан, кайчы һ.б. [Мөхәммәтҗанова, с. 44].

Эпосны телдән әйтү күчмә тормыш шартларында озаграк яшәгән, мөселман культурасын соңрак үзләштергән яисә ислам тәэсирен

бөтенләй кичермәгән халыкларда стабиль саклаңган. Халык шигыренә нигезләп, зур-зур вакыйгалар турында тоташтан сөйләп бирү фольклорда дастан (эпос) жанры булып ныгыган. Тугандаш төрки һәм төрки булмаган халыкларга хас җыраулык-чичәнлек татарларның халык иҗатында борынгыдан бик киң таралган.

Татар чичәне туй-мәҗлесләрдә көтелгән кунак булган, төрле вазгыятьтә оста сөйләве белән игътибарны җәлеп иткән. Кагыйдә буларак, ул – үзе яшәгән төбәкнең оста телле, мәгълүм мөхтәрәм кешесе, фольклор музыка коралларында да уйный белгән. «Чичән» сүзе халыкта сүз остасы мәгънәсендә йөргән, «чәчән» дип тоткарсыз рәвештә җыр чыгарып әйтә алучыларны атаганнар [Татар халык мәкальләре, 1959, б. 67, 70], кайбер халыкларда хәтта соңгы чорларда да әле шагыйрьләргә «чичән (сәсән)» исеме бирелә торган булган. Бу очракта «чичән» сүзе «матур сөйли белүче генә түгел, илһами рәвештә, кәгазьгә язмастан, тоткарлыксыз шигырь әйтүче-импровизатор» мәгънәсен дә үз эченә ала.

Татарларның иң оештыручы үзәге саналган Идел һәм Урал буенда эпосның думбра чиртеп әйтелә торган сөйләмә формасына караганда язма-китаби төренә өстенлек бирелсә дә, халыкка җыраучичәнлек традицияләре ят түгел. Кайбер дастаннарыбызның шигъри өлешләрен дутар, думбра, саз белән көйләп әйтү традициясе әле дә исән булу яисә эпос-дастаннарга якын торган кайбер сөйләмә әсәрләрнең бүгенге көннәрдә дә халыкта актив жанрлар рәтендә йөрүе үк – шуңа дәлил. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан 2000 еллар азагыннан интенсив төстә уздырыла килә торган, Институт эшчәнлегенең зур бер юнәлешен тәшкил иткән комплекслы фәнни экспедицияләрдә галимнәр татар дастаны эзләренә әле дә тап була торалар. Әле бүгенге көндә дә татарлар яши торган төбәкләрдә дастанны фабула характерында, я булмаса әсәрдән эпик җырны көйләп-сөйләп бирүчеләрне чичәнлек традициясе кыйпылчыкларын бүгенге көнгә китереп җиткерүчеләр дип санарга мөмкин. Мисал өчен, 2023 елның сентябрь аенда Татарстанның Ютазы районында узган фәнни экспедициядә Дим Тамак авылыннан 1949 елгы информант Гәрәева Сәгъдүнә Миннешәех кызы «Таһир-Зөһрә җыры» дип аталган дастан җырын әйтеп күрсәтте. Информант үзе үк дастан җырына аңлатма да бирә:

*«Таһир-Зөһрәне ишеткән бар. Көчле мәхәббәт турында. Таһир белән Зөһрәнең мәхәббәте. Сандыкка салып суга агызылар Таһирны. Таһир пәри кызлары янына барып чыга. Анда бик чибәр пәри кызы аны үзенә өйләндерергә тели, үзенең буе белән кызыктыра. Таһир Зөһрәгә биргән вәгъдәм бар ди. Җыры шуннан.*

*– Таһир, затың пәриме?*
*Фирештәме, хуримы?*
*Бу яралган җис(е)мегез*
*Яшел гәвәр нуримы?*

*– Мин Зөһрәнең ярымын,*
*Бер күрүгә заримын,*
*Синең гүзәл хөснеңә*
*Хәйран булып карыймын.*

*– Саф мәхәббәт бар икән,*
*Сине сөяр яр икән,*
*Бер хуб-мазар кыйлсана,*
*Зөһрәң миндәй бар микән?*

*– Пәри назым минем юк,*
*Хөсне дәхи сүзем юк,*
*Акылым Зөһрә алгандыр,*
*Сине күрер күзем юк.*

*– Мәгъсүманә һәр җирем,*
*Нәзек-зифа бу билем,*
*Иренем шифа хасаңа,*
*Дәрткә дәрман һәр җирем.*

*– Матур булсаң, мең хозур,*
*Борыл, кыйлмам ихтыяр,*
*Зөһрәм белән вәгъдәм бар,*
*Һич сөймәмен бүтән яр».*

[Таһир җыры (дастан җыры)]

Татар халкының тарихи хәтерендә чичән образлары бар: Җирән чичән, Сыпра (Субра) җырау, Җамукай чичән яисә Идел-Урал төбәге шагыйрь-импровизаторлары саналган Әсән Кайгы (XV гасыр), Казтуган җырау (XV гасыр), Дусмәмбәт җырау (XV гасыр ахыры – XVI гасыр башы), Чалгиз (Шалкиз) җырау (XV гасыр ахыры – 1560 еллар) һ.б. Соңгы чорда Урта Идел татарларының талантлы чичәннәреннән Сабирҗан акын (Әтнә районы Мәңгәр авылыннан), Байчыгави (Лаеш ягыннан), Кәшшәфетдин Шаһимәрдән Минзәләви (Минзәлә өязе Сөлек авылыннан), Хөсәен Нугай һ.б. – чичәнлекләре белән шулай ук билгеле шәхесләр.

Алай да татарларда һәм бигрәк тә Идел буе татарларында дастаннар һәм дастани традицияләр исән булса да, эпос-дастанны фольклор музыка коралында уйнап, тоташтан телдән әйтеп утыру гадәте күптән сүрелгән. Аның каравы, татар эпос-дастаны бүтән юнәлештә үсеш алган. Татар дастаннарының төп үзенчәлеге шунда: алар китап культурасын үстерүгә зур йогынты ясаганнар, язма әдәби-мәдәни процессны югары баскычка күтәрүдә әһәмиятле функция үтәгәннәр. Хикмәт шунда: халкыбыз күләмле дастаннарны берничә гасыр элек кәгазьгә төшергән, ягъни мәгълүм дастани сюжетлы иң камил, иң төзек вариантлар язмага теркәлеп, кульъязма нөсхәгә яисә китапка әверелеп таралган. Язулы һәм дәүләтле халыклар эпосының язмышы-

на карата Х.К. Короглы түбәндәгечә яза: «Язулы борынгы халыкларның (фарсы, һинд һ.б.) күбесендә эпос, язуга күчерелү белән үк, сөйләмә формада яшәүдән туктаган, чөнки дастан әйтүчене (сказитель) кыйссахан (чтец) алыштырган һәм ул авыл һәм шәһәрнең озын кичләрендә шул ук эпосны үзе «канунлаштырган» формада халыкка укып бирә торган булган. Шәһәр һәм авыл культурасы югары утрак тормышлы иранлылар, һинд, греклар, тарихи үсешләренең билгеле бер чорында, телдән башкарыла торган эпоска караганда язма эпосны кулайрак күреп, тулысынча язма эпоска күчкәннәр» [Короглы, 1976, с. 114].

Күп гасырлык язма мираска ия татарларда да эпик иҗатның язмышы әлеге закончалыкка тәңгәл: иртә язмачылык, утрак тормыш, шәһәрләшү, укымышлылыкның югары дәрәҗәдә булуы, грамоталылыкны һәм белемне пропагандалый торган ислам тәэсире татар дастанының язма-китаби юнәлештә үсүенә йогынты ясаган. Халыкның уку-язу белән турыдан-туры шөгыльләнүче катламы даирәсендә туган күләмле эпик иҗат язуга теркәлгән. Татар халкы үзенең яшәү-тереклек итүе дәверендә эпос-дастаннарны бик күп иҗат иткән. Мондый ядкярләр, кулдан язып күчерелеп һәм таратылып, тарихи үсешнең татарлар өчен үзенчәлекле чорларында халыкка милли үзаңны, милли үзбилгеләнүне саклап калу чарасы булып та хезмәт иткән.

Сөйләмә эпос-дастаннарга алмашка килгән язма-китаби дастаннарыбыз гарәп язулы кульязмалар булып, китап басу чорында исә басма китапларга әверелеп, хәзерге көннәргә килеп җиткәннәр. Алмашка килгән дисәк тә, сөйләмә дастаннар стилендәге традицияләр китаби дастаннарда да эзсез юкка чыкмаган. Татарларда озак еллар буена бер үк дастанның сөйләмә төре дә, китаби төре дә параллель яшәгән булуга да мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Ләкин шунысы да бар: бер үк сюжетка иң камил дастанны сайлый башласак, нәкъ менә китаби вариантның югары эпик кануннарны да саклаган, шул ук вакытта әдәби камиллеккә җиткән иң тулы әсәр булуын таныйбыз.

Авторлы әдәби дастаннардан һәм импровизатор иҗаты булган традицион сөйләмә дастаннардан аермалы буларак, китаби төрдәге эпоска карата фәндә «китаби дастан» төшенчәсе кулланыла. Китаби дастан дип карасак та, дастан гына дисәк тә, асылда аларның барысында да халыкның тарихы белән бергә гасырлар дәвамында тупланган акылы, тормыш тәҗрибәсе, тел байлыгы, сүз сәнгатенең кабатланмас бизәкләре урын алган. Халкыбыз хәзинәсе, башка халык авыз иҗаты үрнәкләре белән беррәттән, эпос-дастаннар – яшь буынга милли рухыбызны тапшыруның кыйммәтле чыганагы да. Әлеге бәһаләп бетергесез зур мирас бүгенге көндә дә иҗтимагый тормышыбызда билгеле бер роль башкара килә. Дастаннарның һәм дастаннардан килә торган традицияләрнең онытылмавы шул хакта сөйли. Дастан батырларының исемнәре, дастан вакыйгалары опера-балет, театр сәхнәләрендә, әдәбият мәйданында, милли мәгариф өлкәсендә (әйтик, мәктәп дәреслекләрендә) яшәвен дәвам итә.

Татарларга мәгълүм эпик сюжетларның, билгеле дастаннан эпик җырларның безнең көннәрдә дә актив яши торганнары юк түгел. Алдарак китерелгән һәм башка мисаллардан күренгәнчә, алар татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә әле дә язып алыналар. Бу күренешне дә хаклы рәвештә эпос-дастаннарыбыз дәвамы, татар җәмәгатьчелегендә жанрга карата булган ихтыяҗның чагылышы дип бәялибез. Дастаннар һәм дастан традицияләре – буыннан буынга тапшырылып килә торган олы мирас, әлеге байлыкны файдалану, дастаннар сюжетында, стилендә, башкарылу үзенчәлекләрендәге нечкәлекләрне килер буыннарга җиткерү үзаңны үстерә, милли асылыбызны саклауны нәтиҗәлерәк итә.

Россия халыклары арасында татарларның иң дисперс халык булуы да дастаннар үсешенә үзенең уңай йогынтысын ясаган. Сибелеп урнашкан татар халкының Себер этник төркемендә яисә Әстерхан татарларында сөйләмә характердагы дастаннар күбрәк сакланып калып, Идел буендагы татарларда исә язма-китаби эпос-дастаннар тотрыклы үсеш алган булу шуны раслый. Оештыручы сәяси үзәктән ераклык, шулай ук территория киңлеге һ. б. факторлар Себердә, Әстерхан өлкәсендә яшәүче татарларда сөйләмә эпос-дастаннарның яшәве өчен уңайлырак шартлар барлыкка китергән. Себердә әле XX гасыр урталарынача күләмле эпосны телдән әйтүче татарлар булган. «Мешәк алып», «Йәстәй Мөңке», «Кадыш мәргән», «Кара Күкел», «Йиртөшлек», «Ак Күбәк», «Кузы Көрпәч белән Баянсылу» һәм «Идегәй»нең берничә дистә варианты – чагыштырмача тыныч төбәккә сыенып, себер татарлары иҗатында исән калган традицион сөйләмә дастаннарыбыз.

Академик фәннең фольклористика тармагында дастаннар – татар халык иҗатының һәм әдәбиятының төп фундаменты. XX гасырның 20 нче елларыннан татар халык иҗаты үрнәкләрен интенсив җыю-туплау, героик җырлар, әкиятләр белән беррәттән дастани эпос тарихын да өйрәнү, халыкта киң таралган дастани сюжетларга яңа әсәрләр иҗат итү, мәгълүм дастаннарның җыйнама вариантларын төзү бурычы куела. Әмма татар дастаннарына, ягъни милли эпоска карата хөкүмәт тарафыннан күрсәтелгән җылы караш чорның иҗтимагый-сәяси шартларына бәйле тукталып кала. ВКП(б) Үзәк Комитетының татар галимнәрен милләтчелектә, Алтын Урда чорын идеаллаштыруда, «ханнар-феодаллар эпосы» «Идегәй»не популярлаштыруда һәм артык бизәп күрсәтүдә гаепләгән «О состоянии и мерах улучшения массово-политической и идеологической работы Татарской партийной организации» дигән 1944 ел 9 август карары озак елларга милли эпосны өйрәнелүдән мәхрүм итә. Шушы вакыйгадан соң татар эпосын, аның тарихи-эволюцион үсешен, яшәү формаларын өйрәнү, башка халыклар фольклоры белән чагыштыру берничә дистә елга артка чигерелә.

Проблемага кабат әйләнеп кайту, дастаннар хакында янә сүз кузгату фәкать XX гасырның икенче яртысыннан соң гына мөмкин бул-

ды. Ф. Урманчеев (1984, 1997, 1999, 2015), И. Надиров (1988), М. Госманов (1990), Ф. Әхмәтова-Урманче (1984, 2000), Ф. Яхин (2000), В. Хәйруллина (1998), М. Әхмәтҗанов (2000), Л. Ибраһимова (2002), И.Г. Закирова (2003) һ.б.ның дастаннарны төрле аспектларда тикшергән монографик хезмәтләре дөнья күрде. XXI гасырның 10 нчы елларыннан алып Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре М. Гайнетдин (2001), Ф. Вәлиуллина (2007), А. Фәхретдинова (2008), И. Закирова (2011), Л. Мөхәммәтҗанова (2015), Г. Хөсәенова (2022) тарафыннан эпос жанрына багышланган докторлык, кандидатлык диссертацияләре яклнды, дастаннарыбыз хакында киң колачлы монографияләр, фәнни һәм популяр матбугатта саллы мәкаләләр дөнья күрде, дастаннар хакында радио-телевидениедә чыгышлар да активлашты.

Моннан тыш, мәгълүм булганча, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан «Татар халык иҗаты»-ның татар телендә 25 томлыгы, рус телендә 15 томлыгы әзерләнеп килә, берничә том, шул исәптән рус телендә «Дастаны» китабы [Татарское народное творчество. Т.8: Дастаны, 2019] инде дөнья күрергә дә өлгерде. Сүз уңаеннан, татар дастаннарының академик җыентык буларак рус теленә тәрҗемәдә әле моңа кадәр нәшер ителгәне юк иде. Татар телендә чыга торган күптомлыкның «Дастаннар» һәм «Китаби дастаннар» дип аталган ике томы шулай ук әзер, «Дастаннар» томы [Татар халык иҗаты. Т.9: Дастаннар, 2023] шушы араларда басылып та чыкты. Томнар татар дастннарының иң камил үрнәкләрен үз эченә ала, дастаннарның халыкта билгеле вариантлары хакында тулы фәнни мәгълүмат бирелә. Шулай ук Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан ел саен уздырыла торган «Татар гыйлеме» халыкара яшьләр фәнни мәктәбенең 2023 елгысы төрки халыклар эпик мирасына багышланды. Әлеге мәктәпнең быелгы ачылышына Ф. Урманчеевның «Героический эпос татарского народа» (Казань, 1984) һәм «Народный эпос «Идегей» (Казань, 1999) дип аталган ике китабын берләштергән «Татарский народный эпос» монографиясе дөнья күрде [Урманчеев, 2023]. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында «Обычаи и традиции татарского народа» сериясендә чыгып килә торган фәнни-популяр басмаларның да нәкъ менә татар эпик традицияләренә багышлап әзерләнгән булуы игътибарга лаек [Мөхәммәтҗанова, 2023].

Идел-Урал буе татарларында эпос-дастанның язма әдәбиятка гына түгел, гомумән язмачылыкка, язма культурага бәйлелеге, хәтта буйсынган булуы төрле факторлар аркасында гаять киң җәелеп, тора-бара халык дастаннары таралыш-яшәешендә масса характерын алган булуны ассызыкламый булмый. Чыннан да, Казан татарлары дастани мирасының иң зур күпчелеген китаби дастаннар тәшкил итә. Эпосның башка төрки халыкларда авыз-тел иҗаты буларак таралган версияләре дә үз җирлегебездә китаби булып формалашканнар. Мәсәлән, атаклы «Идегәй»нең фәндә мәгълүм татар вариантлары –

Н. Исәнбәт варианты, Н. Хәким варианты, В. Радлов, А. Ходьзко, С. Чыгатай вариантлары һ.б. мәгълүм, шулардан Н. Исәнбәт тарафыннан шигъри камиллеккә җиткерелгән һәм Н. Хәким себер татарыннан язып алып кайткан дастан турында да шуны әйтергә мөмкин. Ходьзко вариантында да [Мөхәммәтҗанова Л.Х. Янә дә «Идегәй» хакында, б. 166–172] автор кулы аша үткәнлек сизелми калмаган. Яисә «Чура батыр», «Түләк китабы», «Бүз егет» һ.б. – барысы да татар рухи тормышына иң беренче чиратта җыручы-чичән башкаруында түгел, ә язма-китаби эпос булып кереп ныгыганнар. Ә «Кыйссаи Сәкам», «Каһарман Катил», «Гыйсә улы Амәт», «Чыңгыз хан нәселе турындагы дастан» һ.б. – болар, гомумән, башлангычы белән үк язмада таралыш алган дастаннар.

Эпосны халыкка җиткерүче башкаручы-импровизатор иҗаты – язмага кадәрге культураның бер чагылышы, дастанның бу төре тексттан гына гыйбарәт түгел, әйткәнемчә, ул чичән тарафыннан башкарыла, тыңлаучы аудитория тарафыннан ишетеп кабул ителә. Күләмле сөйләмә эпоска караганда китабилыкка, язма иҗат белән шөгыльләнүгә омтылган Идел буе татарларының рухи тормышында китаби дастаннар гаҗәеп популяр булган. Моны күчереп таратылган кулъязмаларның күплеге дә, басма китап чорына кергәннең соңында бик зур тиражлар белән басылып чыккан булуы да раслый. Мисал өчен, татарларда «Каһарман Катил» дастанына карата шул мәгълүм: күчерелүе XVIII гасырга караган кулъязмаларыннан башлап, бу әсәр XX гасырның 20 нче елларына кадәр гарәп язулы китаплар булып шактый зур тираж белән басыла килгән. 1912 елда «Кәримия» нәшриятында китапның 6000 гә якын, ә 1913 елда «Ш. Хөсәеновлар нәшере»ндә төгәл 6000 данә белән басылуы мәгълүм [Гилазев, 2005, с. 148, 149], димәк, дастанга халыкта, шиксез, ихтыяҗ булган, әсәр кабул ителгән, яратып укылган, таралган һәм – иң әһәмиятлесе – XX гасыр башында да әле «Саф татар телендә, һәркемгә аңлап укырга бик кызыклы» [Кыйссаи пәһлеван Каһарман Катил] дигән тәкъдимнәр белән өндәп, рекламалау рәвешендә халыкка аңлы һәм максатчан рәвештә таратылган. «Сәйфелмөлек», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Йосыф китабы» һ.б. сюжетка корылган дастаннар турында да шундый ук фактларны китерергә мөмкин булыр иде. «Идегәй», «Чура батыр», «Гыйсә улы Амәт», «Дастане Чыңгызнамә», «Алпамша», «Җик мәргән», «Таһир белән Зөһрә», «Бүз егет», «Түләк китабы», «Сары Салтык», «Хурлуга белән Хәмра» «Мактым-сылу», «Кыйссаи Зәркум», «Хикәят Былбылнамә», «Хикәя Маһфируз вә солтан илә Разанхан», «Каһарман Катил» «Кыйссаи Сәкам», «Кыйссаи Сәед Баттал», «Хикәяте Күр углы солтан» кебек дастаннарыбызның да халыкта күпләгән вариантларда кулъязмалар һәм басма китапларда таралганлыгы билгеле.

Татарның бик борынгыдан килә торган кулъязма китабының да, XIX гасырның башыннан дөнья күрә башлаган тулы канлы милли басма китабының да мәдәниятебез һәм әдәбиятыбыз тарихын өй-

рәнүдә кыйммәте бик зур. Татарларның кульязма һәм басма китабы аеруча бай һәм зур тарихка ия. Китап тарихын, бигрәк тә меңәрләгән кульязма китапларны, шулар арасында дистәләгән исемдәге, йөзәрләгән варианттагы дастаннарны өйрәнү иң элек кульязма материалны туплаудан башлана. Казанда Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында, аннан тыш Милли китапханә һ.б. фәнни үзәкләрдә татар дастаннарын җыютуплау һәм сакланышын тәэмин итү юнәлешендә хаклы рәвештә максатчан эш алып барыла килә. Институтның Язма мирас үзәгендә генә дә әллә никадәр кульязма дастан барлыгы мәгълүм һәм аларның саны фәнни экспедицияләрдә табылган яңа вариантлары исәбенә ел саен арта тора.

Дастаннарда халыкның тарихы, гасырлар дәвамында тупланган акылы, тормыш тәҗрибәсе, тел байлыгы, сүз сәнгатенең кабатланмас бизәкләре урын алган. Аларда борынгы һәм бик борынгы мифология эзләрен, ислам идеологиясенең тирән йогынтысын, сүзне хикмәт белән әйтү, элек-электән фольклорга хас традицион образлар, эпик сюжет һәм мотивларны табарга мөмкин. Халкыбыз хәзинәсе, башка халык авыз иҗаты үрнәкләре белән беррәттән, эпос-дастаннар – яшь буынга милли рухыбызны тапшыруның кыйммәтле чыганагы да. Әлеге бәһаләп бетергесез зур мирасның мәктәптә әдәбият укыту программаларында тиешле урын алуы да шуның белән аңлатыла. Кулланылышта булган мәктәп программасы һәм дәреслекләр нигезендә укучылар дастан жанрының тарихы, төрләре белән танышалар. Алыплар турындагы архаик, романик характердагы мәхәббәт дастаннары яисә стадиаль яктан төрле чорларны иңли торган тарихи дастаннар турында сөйләшү халкыбызның күңел байлыгын, әхлакый идеалларын, матурлыкка омтылышын күзалларга ярдәм итә.

Татар дастаннары үткән юл бик озын һәм катлаулы. Гомумән, эпос-дастаннарыбыз – милләтнең үзе кебек үк, гаять яшәүчән жанр. Нинди генә шартларга юлыкканда да татар эпосының исән калуы, яңадан-яңа отышлы формаларга трансформацияләнеп, камилләшә баруы шул хакта сөйли. Мең елдан артык язма тарихка ия халык булуыбыз татар дастанының элитар жанр булып формалашып җитүенә йогынты ясаган. Дастаннар – буыннан буынга тапшырылып килә торган олы мирас, бу байлыкны файдалану һәм килер буыннарга җиткерү милли үзаңны үстерүне, асылыбызны саклауны нәтиҗәлерәк итә. Дөньяда эпос-дастаны булмаган бик күп халыклар барлыгын да исәпкә алсак, дастаннарыбызның аеруча зур хәзинә, халкыбызның исә нык тамырлы бөек халык булуына тагын да ныграк инанырга мөмкин. Идел һәм Урал буйларында гына түгел, гомумән Евразия далаларында таралып яшәүче татарларда киң таралып, татар дастаны гасырлар буена халык тормышында эмоциональ-экспрессив дәрәҗәдәге рухи азык, тәэсирле язма, укып, күңел юату чарасы гына булмыйча, тарихның халык өчен хәлиткеч әһәмияткә ия этапларында үзенә күрә бертөрле идеологик функция дә үтәп килгән.

Чабып барган ат тоягы тавышын, кошның очып һавага күтәрелүен, исеп үткән дала җилен, ат пошкыруын, кылыч чыңын сөйләме аша тыңлаучыга җиткерергә сәләтле башкаручы тасвирындагы сөйләмә дастаннарыбызга да, шушыларга өстәп, язма мәдәният традицияләрен дә үзләштергән китаби дастаннарыбызга да халык эпик иҗаты кагыйдәләре барлык тулылыгы белән диярлек сыешкан, аларда эпик һәм индивидуаль иҗат башлангычлары бер-берсе белән гармониядә. Татар – дастанлы халык, ә инде аның китаби дастаннары дәрәҗәсенә җиткерелгән версия-вариантлары башка бер генә төрки халыкта да юк. Татар дастанының китаби камиллеккә ирешкән булуы – милләтнең аңы, укымышлылыгы, алдынгылыгы белән бәйле сыйфат. Бу төр иҗатны халкыбызның асыл кыйммәтләреннән берсе дип саныйбыз. Бүгенге көндә эпос-дастаннарыбызга карата игътибарның зурлыгы татар дастани традицияләренең дәвамчанлыгын күрсәтә, эпос-дастан стиленең, образ-каһарманнар рухының исәнлеген дәлилли.

**Әдәбият**

*Короглы Х.Г.* Огузский героический эпос. М.: Наука, 1976. 239 с.

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос: книжные дастаны. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2014. 380 с.

*Мухаметзянова Л.Х.* Эпическая культура татар: дастаны. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2023. 120 с.: ил. (Серия «Обычаи и традиции татарского народа»).

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Янә дә «Идегәй» хакында: «Идегәй» дастанының Александр Ходьзко тарафыннан язып алынган варианты // Казан утлары. 2023. № 9 (1211). Б. 166 – 172.

Татар халык мәкальләре: 3 томда / җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. Казан: Татар кит. нәшр., 1959. Т. 1. 915 б.

Татарское народное творчество: в 15 т. Казань: Татар. кн. изд- во, 2019. Т. 8: Дастаны. 471 с.

Татар халык иҗаты: 25 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2023. Т. 9: Дастаннар. 483 б.

Таһир җыры (дастан җыры)] / Татарстанның Ютазы районы Дим Тамак авылында Гәрәева Сәгъдүнә Миннешәех кызыннан (1949 елгы) Лилия Мөхәммәтҗанова тарафыннан язып алынган // Л.Х. Мөхәммәтҗанованың шәхси архивы.

*Урманчеев Ф.И.* Татарский народный эпос. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2023. 384 б.

*Гилазев З.З.* Татарская литература начала XX века в книжных изданиях. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2005. 160 с.

Кыйссаи пәһлеван Каһарман Катил. Саф татар телендә, һәркемгә аңлап укырга бик кызыклы. Казан: Матбагаи «Кәримия», 1914. 116 б.

*Мәкалә «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасының 3.19 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 393(=512.145)

***Ф.Х. Җәүһәрова***

## ТАТАР ХАЛЫК ЙОЛА ИҖАТЫНДА ЯШӘҮ ҺӘМ ҮЛЕМ БЕРЛЕГЕ

В статье на основе фольклорных образцов, ритуальных практик похоронно-поминальной обрядности татар рассматриваются отношение народа к таким понятиям, как смерть и жизнь. На основе приведённых примеров и описания этапов совершения обряда доказывается их единство, то есть осмысление смерти в народной традиции как продолжения самой жизни.

**Ключевые слова:** обряд, ритуал, мунаджаты, поверья, смерть, загробная жизнь, вечная жизнь, благопожелания, фольклорные практики.

The article, based on folklore samples and ritual practices of funeral and memorial rites of the Tatars, examines the attitude of the people to such concepts as death and life. Based on the examples given and descriptions of the stages of the ritual, their unity is proven, that is, the understanding of death as a continuation of life itself.

**Keywords:** rite, ritual, munajats, beliefs, death, afterlife, eternal life, good wishes, folklore practices.

Яшәү һәм үлем – татар кешесе акылында бер-берсеннән аерылгысыз төшенчәләр. Үлем – кеше тормышының кайгы-хәсрәтле халәте. Шулай булса да аңа хөрмәтле караш татар акылында бала вакыттан ук әрвах төшенчәсе аркылы тәрбияләнә башлый. Алдагы буыннарга – әрвахларга таяну һәм ата-баба рухының нәсел-нәсепне ярдәмсез, теръксез калдырмауларына инану – бик борынгыдан, төрки-татар заманнарыннан ук килүче бик үзенчәлекле мәдәни күренешләрнең берсе [Урманчеев, 2008, б. 190]. Татар гаиләсе нинди генә зур эшкә тотынмасын – гаилә дәвамчысы улы/оныгы туамы, кызын кияүгә бирәме, улын өйләндерәме, олы, җаваплы сәфәргә җыенамы, солдатка алынамы, һәрвакыт ярдәмен, киңәшен, фатихасын алырга өметләнеп, нәсел-нәсәп әрвахларына мөрәҗәгать итә [Баязитова, 2018, б. 479–494]. Әрвахларны ризалату өчен нәселгә килешә торган гамәлләр кылырга тырыша, ул гына да түгел, нәсел аклыгын, намусын саклау йөзеннән, гомерен, язылмаган булса да, нәсел кануннарына туры китереп үтәргә омтыла. Татар кешесенең үлемгә мөнәсәбәте нәкъ менә шушы күзаллаулар нәтиҗәсендә формалашкан. Аның өчен яшисен яшәп, эчәсен эчеп, фанидан бакыйга күчү – гайре табигый бер күренеш. Гомерен олы, озын юл ярып, нәсел бизәүче буларак үткәргән һәркем җанының бакыйлыкта әрвах затына әверелүе турындагы күзаллаулар үлемне билгеле бер югарылыкка, дәрәҗәгә күтәрә. Ә инде вакыт җитми, яшәп бетерми үлемгә дучар булганнарның бакыйлыкка күчүе татар акылында фаҗига буларак кабул ителә. Андыйларга карата халык «җыяр ризыклары беткәндер инде, гомере

шулай кыска язылган булгандыр инде» кебек юану сүзләре куллана [Галиуллин, 2019, б. 113]. Ә бакыйлыкка үзе тәрбияләгән балалары кулыннан, оныкларын сөеп, аларның матур итеп үскәннәрен күреп күчүчеләр турында «бәхетле гомер кичерде, бар бурычларын үтәп бетерде, тыныч үлемнәр насыйп булды» кебек соклану хисләре җиткерелә [Галиуллин, 2019, б. 144].

Татар кешесе өчен оныкларны күрү, аларны итәк тутырып сөю – гомернең заяга үтмәвен дәлилләүче иң төп күрсәткечләрнең берсе. Шуңа күрә дә татар хатыннары беренче оныклары дөньяга килүгә үлемтек әзерләүгә керешә. Алар өчен бу эш кызы тууга бирнә әзерли башлаган кебек үк бик җаваплы гамәллардән исәпләнә. Биредә үлемтек хәстәрли башлау гомернең өченче туена, соңгысына әзерләнү буларак та аңлана. Хатын үлемтекне үзенә дә, иренә дә бертигез итеп әзерли. Үлемтек әйберләре, гадәттә, гомер дәвамында шактый бушап калган бирнә сандыгына тутырыла. Анда салынырга тиешле һәр кирәк-ярак авылның, этник төркемнең электән килгән тәртибенә туры китерелеп әзерләнә. Үлемтеккә дип, гадәттә, мәетне юуу өчен су китерүчеләргә, кәфен кисүчеләргә, тегүчеләргә, мәет юучыларга, гүргә иңдерүчеләргә, төн саклауда катнашучыларга, кабер казучыларга һәм башкаларга өләшенергә тиешле кирәк-яраклар һәм исле сабыннар, ислемайлар да салына, кәфенлек өчен тиешле күләмдә ак бәз тукыма, энә-җепләр дә әзерләнә. Үлемтек әйберләре бик якыннарга гына күрсәтелә, андагы тәртипне төп йорт килене, яисә олы кыз гына белә. Гомерләрен ахирәтләр буларак көткән хатыннар өчен үлемтек әйберләрен бер-берләренә күрсәтеп киңәшләшү шулай гадәти гамәл буларак кабул ителә. Татар кешесе мондый хәстәрне «үлемтек әйберләрен никадәр алдан хәстәрләсәң, алар сиңа шулкадәр гомер теләп торырлар» дигән ышануга да таянып күрә. Ничек кенә булмасын, бу мәгънәле гамәлнең асылында үлемне зурлап көтеп алу ята. Халык телендә җанлы кулланышта йөргән бихисап мәкаль-әйтемнәр дә кеше гомере барышында үлемнең табигый халәт булуын иплән кенә аңлата, төшендерә, беркадәр үлемгә әзерләнүдә ярдәм итә [Брусько, 2013, с. 111–129]. Мәсәлән,

Атам – Мәккә, анам – Мәккә,
Туылганмын мин үлмәккә,
Аталардан мирас калган
Кара җиргә күмелмәккә.

[Брусько, 2013, с. 118]

Кичерәсе гомерләрен кичереп, үлем түшәгендә яткан кеше яисә каты авыруга бәйле үлемнең һичшиксез килүенә инанган чагыштырмача яшь татар кешесе күзе ачык, акылы бар вакытта якыннарына җан биргәндә кемнәрне үзе янында күрергә, җаны чыгар алдыннан кемнән ясин укытырга теләвен дә ирештерә. Якыннары исә үлем түшәгендә ятучының бөтен гозерен булдыра алган кадәр тизрәк үтәргә тырышалар. Алар өчен бусы да бик мөһим, чөнки адәм баласының

җаны бакыйлыкка тынычланып, хәер-фатихалар калдырып күчәргә тиеш. Үлем белән яшәү арасы бер бөртек чәч калынлыгы белән исәпләнгән мизгелләрдә, үлем түшәгендә ятучы якыннарын бәхилләргә тырыша. Бәхиллек алып калу – исәннәр өчен бик зур савап, ә инде үләсе кешенең бәхилләшә алуы аның җанына / рухына җиңеллек бирә дип аңлана. Әгәр бакыйлыкка күчүче ясин укучының кем булырга тиешлеген алдан тәгаенләмәгән булса, бу очракта үлем түшәгендәге кеше янына (авылның) мулласы чакырыла, мулла килә алмаса, укый белүче ягъни дини китапларны укый алучы, догалар белүчене дәшәләр. Мулла (яисә укый белүче) үлем түшәгендә ятучы янына килгәч, кычкырып ясин укырга тотына, бу гамәл, бер яктан, үлем газабын җиңеләйтү буларак аңланса, икенче яктан, ислам дине вәкиленең кабер газапларын җиңел үтүен тәэмин итү өчен дип тә башкарыла. Бу вакытта үлем түшәгендә ятучы үз хәленнән килгәнчә якыннары белән «Лә иләһә илләллаһ» дип әйтеп торырга тырыша. Бу – теге дөньяда мәетнең җаны оҗмахка керсен, анда үз урынын тизрәк тапсын дип эшләнелә. Татар акылы өчен тәннән җанның аерылуы мизгелләре адәм баласы кичерергә тиешле иң газаплы мизгелләрнең берсе буларак кабул ителә. Аны тиккә генә халкыбыз үлем / әҗәл ачысы димәгән һәм әлеге мизгелләрне кечү халәтен аңлату максатыннан мөнәҗәтләр иҗат итмәгән [Брусько, 2013, с. 117]. Мәсәлән:

Күкрәгем кыса, тыннарым бетә,
Ясин укырга вакытлар җитә.
Җаным чыкканда янда булыгыз,
Шаһәдәт берлән күч, дип торыгыз!

[Мөнәҗәтләр һәм бәетләр, 2001, б. 502]

кебек юлларда әлеге мизгелләр үлем түшәгендәге кешенең якыннарына гозере буларак ирештерелгән. Үлем газаплары үлем түшәгендә ятучыга да, аның якыннары өчен дә бик авыр.

Татар халкы күзаллауларында үлем бервакытта да кинәт, кисәтүсез килми. Ничек кенә булмасын, үлем хәбәре булачак мәетнең якыннарына мөмкин кадәр алдан ирештерелә. Ирештерү юллары төрле. Иң актив кулланылган хәбәрләрнең берсе – төштә кара яисә күк ат күрү. Татарларның мифологик күзаллауларында бу образлар Газраил образы белән тәңгәлләштерелә. Моннан тыш төштә теге яисә бу йорт каршында бура күтәрү дә үлем хәбәре буларак кабул ителә. Биредә бураның үлем хәбәрчесе булуын борынгы төрки-татарларның мәет күмү йолаларында кабер өстенә бура күтәреп кую гадәте белән бәйле аңлатырга мөмкин. Төштә йортның матчасы, яисә миче җимерелгәнне күрсәләр, татарлар йортның хуҗасы, токасы үлеменә ишарә дип аңлыйлар. Алар өчен бу – ата-ананың үлеменә ишарә. Татарлар йорт өстеннән козгын, кара карга кычкырып үтүен, ишегалдындагы этнең туктаусыз улавын да шулай ук мәет хәбәре дип кабул итәләр [Урманчеев, 2009, б. 151]. Хәбәрне ничек кенә булса да уңайга бору максатыннан, «Үз башыңа кычкырсаң иде, үз башыңа уласаң иде», дип

тәкрарларга тырышалар. Татарларның үлемгә бәйле күзәтүләрендә мәет буласы кешенең үлеменә 40 көн кала аның күзләреннән нур кача, рухы сүлпәнләнә, җилкәләре иңә дигәннәре дә бар. Болар барысы да үлемнең беркемне дә аямый торган табигый күренеш икәнлеген аңларга җирлек бирә. Татар халык иҗатында яшәп килгән күпсанлы мөнәҗәтләр дә шул турыда сөйли. Мәсәлән:

Үлем дигән ачы агу,
Берәү дә татымый калмас;
Үлем угы атар туры,
Берәү дә котыла алмас.
Берәүгә дә киңәш кылмас,
Бу карт, бу яшь диеп тормас,
Көтеп тормас чакырганны,
Алып китәр үлем хәле.
[Мөнәҗәтләр һәм бәетләр, 2001, б. 511]

Татар телендә кешенең үлү мизгеленә бәйле «өзелде», «сүнде», «китеп барды», «теге дөньягә күчте» кебек гыйбарәләр кулланыла. Кешенең үләләр дөньясына күчү сәгатьләре исәннәр дөньясын ике өлешкә бүлә. Берсе терепәр дөньясы булса, икенчесе үлем, шайтан, кайгы, җан, фәрештәләр кебек мифологик затлар белән тулы дөнья [Баязитова, 2008, 33–38]. Мәет булган йортта, аны җир куенына тапшырганчы, әлеге ике дөнья үзара бер яссылыкта кисешергә мәҗбүр. Әлеге кисешүләрне исәннәргә зарарсыз итеп оештыру максатыннан, үлгән кешенең якыннары ата-бабаларыбыз заманнарыннан ук килеп, ислам мәдәнияте кысаларында канунлашкан йолакагыйдәләрне мөмкин кадәр җиренә җиткереп башкарырга тырышалар. Күрәсең шуңадыр да бер генә татар гаиләсе дә мәетне *кумдек* дими, ә *зурлап озаттык* дигән гыйбарәне кулланырга тырыша. Үлем түшәгендә яткан кеше өзелгәннән соң, аны терепәрдән үзгә кыяфәткә кертү хасиятен күрәләр. Өстендәге киемнәрен башы аркылы түгел, ә ертып кына салдырып алалар.

Иң элек мәетне, башын кыйблага (көньяк-көнбатышка) каратып, астына кулдан тукылган гади тукыма гына җәеп, каты ятакка салалар. Ике кулын да гәүдәсе буйлап сузалар, аякларын бергә куеп бәйлиләр, бакыр акча белән күзләрен йомдыралар, берәр яулык ярдәмендә ияген баш очы белән тоташтырып бәйләп куялар, корсак өстенә тимердән эшләнгән пычак яисә кайчы куеп, ак тукыма белән каплыйлар, йөзенә дә ак яулык ябалар. Хатын-кыз затыннан булган мәетнең чәчләрен, сүтеп, күкрәгенә куялар, бар бизәнү әйберләрен (йөзек, алка, муенса, балдаклары) салдыралар. Бу гамәлләр мәетнең терепәр дөньясы вәкиле буларак яшәү дәвере бетеп, аның икенче дөнья затына әверелүен, күчешен тәэмин итү чарасы буларак башкарыла. Мәет яткан бүлмәне дә йола тәртибенчә хәстәрлиләр: көзгеләрне, фотосурәтләрне, телевизорны мөмкин булса алып, яисә каплап куялар. Нигездә, сурәтне чагылдыра торган әйберләр каплана. Татар кешесенең акылында

сурәт чагылдыра ала торган предметларда мәетнең җаны/рухы калып, аннан ул урын тапмый аптырап йөрергә, исәннәрне бимазаларга, ә кайбер очракларда үзе артыннан икенче мәетне дә тартып, икеләтә үлемгә китерергә мөмкин дип уйлыйлар. Мәетне урнаштырып, ул яткан урынны әзерләп бетергәннән соң, мәет янына аның туганнары, күрше-күлән килә башлый. Аларның килүе мәетне зурлау, якыннарының хәлен белү, хәсрәтләрен уртаклашу буларак кабул ителә.

Мәетне якыннары бер генә мизгелгә дә ялгыз калдырмыйлар, көн төнгә таба авыша башлагач, мәет саклаучылар, дөресрәге «төн саклаучылар» килә башлый. Төн саклаучылар ролендә, гадәттә, мәетнең якыннары арасындагы урта яшьтәге хатыннар белән ислам догаларын белгән өлкән яшьтәге хатын-кызлар – карчыклар чыгыш ясый. Төн саклаучыларның төп вазифасы – бер яктан, мәетне шайтаннан, явыз көчләрдән аралау булса, икенче яктан, йортның бәрәкәтен саклау. Төн саклаучылар алып килгән тәсбихләрен тартып, тәһлил әйтеп, гомерне заяга уздырмыйча, иман белән үткәрү кирәклеге турында, мәет булган адәмнең яхшылыкларын искә төшерү, кылган гамәлләре буенча урыны оҗмахта булырына өмет баглау турында сөйләшәләр [Брусько, 2013, с. 129–136]. Әлеге сөйләшү барышында теге һәм бу дөнья арасының күз белән каш арасы кебек якынлыгы, теге дөньяның бакыйлыгы, ә монысының фанилыгы турында да сүз бара, шуңа кагылышлы мөнәҗәтләр әйтелә. Мәсәлән:

Гомерем үтте, яшәп туймадым,
Үтеп киткәнен һичбер тоймадым.
Фани дөньядан бер көн күчәрмен,
Әҗәл ширбәтен тиздән эчәрмен.

[Мөнәҗәтләр һәм бәетләр, 2001, б. 486]

Татар халкы йола-гадәтләре буенча, мәетне ничек мөмкин шулай тизрәк гүр иясе итү мәслихәт. Әмма мәетне гүргә кертү бары тик кояш баеганчы гына башкарыла ала. Шунлыктан мәетнең бар якыннары бер- берләренә булдыра алган кадәр ярдәм итеп, аны вакытында гүр иясе итү хәстәрен күрергә тырышалар. Тиккә генә халкыбыз телендә «бүген үлдең – бүген күмәләр» дигән әйтем яшәп килмидер.

Таң беленер беленмәстән, кояш күтәрелгәнче, мәетне юууга кагылышлы мәшәкатьләр башлана. Мөселман дине кагыйдәләрен, догаларны белгән олы яшьтәге ике хатын-кыз чиләк-көянтә белән чишмәгә (коега) суга китәләр. Татарларның үлем-күмү йолалары тәртибенә бәйле алар беркем белән дә, шул исәптән үзара да сөйләшмичә, суны кояш чыкканчы ук алып кайтарып җиткерергә тиешләр. Мәет юуу өчен суның чишмәдән таң алдыннан алынуы татарларның таң суының аеруча көче, сихәте барлыгына ышануы белән аңлатыла. Бу, үз чиратында, мәетне теге дөньяга тиешле дәрәҗәдә пакьләндереп озату теләге турында да сөйли. Су алып кайтучылар юл буе үзлекләреннән Аллаһы Тәгаләгә юнәлтелгән түбәндәге гыйбарәне кабатлап баралар:

Аллаһыма гаффәкә!
Раббыма гаффәкә!
Аллаһыма гаффәкә!
Раббыма гаффәкә!
(Аллаһым үзе ярлыкасын! Раббым үзе ярлыкасын!)
[Брусько, 2013, с. 121]

Алар су алганда да, суны иңнәренә салганда да шушы сүзләрне бертуктаусыз әйтергә тиешләр. Кайту юлы никадәр авыр булмасын, аларның сулы чиләкләрне җиргә куярга хаклары юк, бу исә суның сафлыгын киметми алып кайтып җиткерү өчен башкарыла. Шушы ук максат белән өйдә сулы чиләкләрне зур тастымал яисә сөлге белән яхшылап каплыйлар. Болар барысы да мәетнең рухын саклау, аның гүр газапларын җиңеләйтү, аңа тиешле хөрмәт күрсәтү буларак бер дә авырсынмыйча башкарыла. Алып кайтылган суларны тән җылысына җиткереп җылыталар һәм мәетне юу эшенә керешәләр. Мәет юучы рolendә авылның ислам дине кагыйдәләре белән яшәүче, намаздагы кешеләре чыгыш ясый. Ир-ат җенесеннән булган мәетне – ир-ат, хатын-кызны хатын-кыз юарга тиеш. Мәет юу эшендә барлыгы 5 кеше катнаша, анда һәр кешенең дә вазифалары төгәл бүленгән: төп мәет юучылар икәү: берсе мәет юучы, икенчесе сөяк әйләндерүче, өченчесе комганнан су коючы, дүртенче һәм бишенче кешеләр юуу эшендә катнашмыйча, бары тик суны тиешлечә көйләп, комганга салып, мәет юучыларга ташып торучылар. Мәет юуу өчен суның да күләме бик төгәл исәпләнгән, барлыгы җиде комган су гына тотылырга тиеш. Биредә дә җиде санының магик эчтәлеге, пакьләндерү көченә ия булуы аңлашыла. Мәет юу урынын читләр күзеннән ныклап каплыйлар. Булдыра алганча тәрәзәләрне дә каплап, мәет юу урынын чаршау белән аерып алалар. Болай каплауның эчтәлегендә ике мәгънә ята: 1) мәетнең шәрә тәнен, шул исәптән гаурәтләрен башкаларга күрсәтмәү; 2) исәннәрне үлем зәхмәтеннән саклау. Мәет юуда катнашучылар махсус киемнәр (гадәттә, халатлар), ә юуучылар кулларына резин бармакчалар да кияләр. Мәетне юа башлаганчы ук төп юучы мәетнең икенче яңа дөнья юлына кузгалуына ишарә итеп: «Бисмилләһир рахмәниир рәхиим! Ошбу бәндәне (исеме) ахирәт сәфәренә юарга керештек. И, Раббым, үзең саклап, пакьләргә насыйп ит», – ди [Брусько, 2013, с. 123].

Мәетне юганнан соң, аны, мөселман дине кануннарына туры китереп, кәфенләү башлана. Кәфен тегүчеләр, мәетне юганчы ук, кәфенне кисеп, әзерләп куялар. Кәфен теккәндә бөтен гамәлләр исәннәргә кием тегү тәртибенең нәкъ киресенчә эшләнә. Энә бер кат җеп белән генә саплана һәм бер генә җирдә дә төен ясалырга тиеш түгел, энәне йөртү хәрәкәте дә тегүчедән мәеткә таба «кирегә» йөртелә, энәне берьюлы берничә тапкыр атлатырга да ярамый, һәр энә адымы саен «Лә иләһә илләллаһ, Лә иләһә илләллаһ» дигән сүзләрне кабатлау мәҗбүри. Бу сүзләр теге дөньяда мәет рухының оҗмахка ирешүен

җиңеләйтү өчен эшләнә. Кәфен әзерләүдә кайчыдан файдалану тыела, кирәк вакытта тукыма ертыла гына. Кәфенләү өчен ахирәт күлмәге, мәет ир-ат булган очракта – чалма, хатын-кыз булса, баш яулыгы әзерләнә [Баязитова, 2015, б. 103–108]. Юылган мәетнең тәненә ислемайлар сөрткәннән соң, юуучылар аны кәфенлиләр, аннан махсус алдан әзерләнгән юрганга төрәләр һәм урындыкларга куелган такта өстенә куялар. Мәет күмгәндә файдаланыла торган махсус кабыкны (носилканы), алдан әзерләп, ишегалдына куялар. Мәет чыгасы йортның олы капкасы иртәдән үк ачып куелган була, мәетне соңгы кат күреп калырга теләге булганнар аны юганчы ук күреп өлгерергә тиешләр. Гадәттә, юылган мәетнең пакьлеген саклау өчен аны кешеләргә башка күрсәтмәскә тырышалар. Мәетне өйдән алып чыгып киткәнче, ким дигәндә җиде ир-ат катнашында, мулла Коръән укый, аннан мәетне алып чыга башлыйлар. Мәетне, тереләрдән аермалы буларак, аякларын алга таба каратып алып чыгалар. Бу – мәет теге дөньяга үз аяклары белән берүзе генә барып керсен, башкаларны ияртмәсен, дип эшләнелә.

Мәетне ишектән алып чыгып киткәндә, якыннары телендә «Хәер догаларыңны калдырып кит! Рәнҗеп китмә! Ризыкларыңны калдырып кит! Бәхетләребезне алып китмә» дигән теләк кенә әйләнә. Мәетне ишегалдына алып чыкканнан соң, урындыкларга куелган кабыкка салалар, мәет ир-ат җенесеннән булса, аны матур бизәкле япма яисә келәм белән каплыйлар, ә хатын-кыз җенесеннән булганда, кабык өстенә чыбылдык коралар. Бу мәетне алып барганда аның тәненең сыгылмалары күренмәсен өчен эшләнә. Мәет салынган кабыкны ир-атлар баш очына күтәреп, Аллаһны зурлау догасы – тәкъбир әйтәләр:

Аллаһу әкбәр!
Аллаһу әкбәр!
Лә иләһә илләллаһ!
Аллаһу әкбәр!
Аллаһу әкбәр!
Вә лә иләһә һәмдә!
[Брусько, 2013, с. 125]

Бу – мөселманнарның иң зур бәйрәмнәреннән исәпләнгән Корбан гаетендә әйтелә торган тәкъбир-доганың мәет күмү йоласында да кулланылуын казан татарлары түбәндәгечә аңлаталар: «Аллаһы Тәгаләнең өч бәйрәм көне бар – кешенең туган көне, никахлашкан көне, үлгән көне. Мәетне күмүдә әйтелә торган бу дога Аллаһның кодрәте белән булдырылган адәмнең Аның янына ирешүеннән хәбәр буларак кулланыла». Мәетне капкадан алып чыгып китәр алдыннан, мулла, җеназа догасын укып, озатырга килгән бар кешедән мәетнең әҗәтләре калу-калмавын, ул рәнҗеткән кешеләрнең, фани дөньяда кылган гамәлләренең тиешле булу-булмавын сорый. Бу очракта җәмәгатьчелек дөресен әйтергә тиеш дип исәплиләр. Соңгы вакытларда җеназаны мәчет янында үткәрү гадәте өстенлек итә башлады, анда да әлеге

тәртип саклана. Әгәр дә мәет булган кешенең кемгә дә булса әҗәтләре калган булса, аның әҗәтен мулла туганнарына каплап бетерергә куша, чөнки теге дөньяда аның түләнмәгән бурычлары муенын авыр таш булып тартып торыр, дип аңлана. Ә тормышы барышында Аллаһы алдында кылган гөнаһларын мулла: «Раббым, бу кешенең бәндәчелек белән ялгышып кылган гөнаһларын ярлыкап, соңгы урынын вәгъдә иткән җәннәтләрдән әйләсәң иде», – сүзләре белән кичерелүен сорый.

Җеназадан соң мәетне башын алга каратып алып китәләр. Татарларда мәетне зиратка кадәр күтәреп озата бару бик саваплы гамәлләрдән исәпләнә. Шуңа күрә, мәет озатуда авылдагы ир-атларның барысы да диярлек катнаша. Кабык күтәреп баручылар, капкадан юлга чыгып, кырык адым киткәнче, үзлекләреннән «Аятел-Көрси»-не укып барырга һәм, бер-берләренең урыннарын алыштырып, «юл бутарга» тиешләр. «Юл бутау»ның төгәл үтәлергә тиешле үз тәртибе бар. Кабыкны алдан күтәреп баручыларны, һәр ун адым атлаган саен, алар артындагылар кабык астыннан диагональ буенча хәрәкәт итеп алыштырырга тиешләр. Бу үлемне бутап, аны авылга тиз генә китермәс өчен, һәм мәет күтәреп барганда адым саннарын арттырып, күбрәк савап алып, кылган гөнаһларның санын киметү теләге белән эшләнә. Мәет озатканда хатын-кызлар мөмкин кадәр еламаска, күз яшьләре күрсәтмәскә тиешләр, моның мәгънәсен татарлар «никадәр күп еласаң, мәет гүрдә шулкадәр су эчендә ятар», дигән ышану белән аңлаталар. Мәетне алып китүчеләр беренче борылышка җитүгә, олы капкалар ябыла, бар хатын-кыз өйгә керә һәм абыстай алар алдында Коръән укый, мәет гүргә кергәнче, мәетнең якыннары килгән бөтен хатын-кызга сәдака өләшә.

Әлеге гамәл башкарылуга, мәетнең үлгәндә өстендә булган киемнәре, юуу өчен тотылган чүпрәкләре мәет гүргә иңдерелгәнче, чайкалып эленергә тиешләр, моны мунчада мәеткә иң якын хатын-кызларның берсе, гадәттә кызы, апасы яисә сеңлесе башкара. Шул арада өйдә калганнар мичкә ягып, яисә чыра яндырып, төтен исе чыгарып ала, калганнар өй юу эшенә керешәләр. Мәет чыккан йортны юу кире тәртиптә башкарыла, ягъни тупсадан түргә таба юыла: түшәмнәр дә, өй стеналары да, идәннәр дә. Мәет яткан җирдәге челтәр-пәрдәләр дә, төрле япмалар да, урын җирләр дә юылырга тиеш. Мәет керләрен чишмә буена төшеп чайкыйлар. Мәет керен чайкаган вакыттан, гадәттә, бар авыл халкы хәбәрдәр була: малларны да эчерү өчен инеш буена китермиләр, түбән очтагылар кер чайкарга да төшми торалар. Бу гамәлләр мәет суына бәйле ышануларга бәйләп башкарыла. Мәет керен, тереләр кереннән аермалы буларак, уңын сулга әйләндерми генә эләләр. Бу да – мәетнең тереләр дөньясыннан башкага күчүен белдерүче фактларның берсе [Брусько, 2013, с. 139].

Мәет чыккан йортта өч көн ашарга ярамый дип исәпләнә, шуңа күрә мәетне озатырга кайткан туганнарны да, йорт хуҗаларын да күрше-күлән яисә авылда яшәүче башка туган-тумача ашата, эчертә. Бу

да зур саваплы эш дип кабул ителә, шуңа күрә ашарга алучылар саны берничә булып, бер генә гаилә җилкәсенә калмый.

Кабыкка салынган мәетне зиратта алдан тиешенчә казып куелган кабер урынына алып киләләр. Татарларда әле һаман да кабер казу зур савапка ия гамәлләрдән санала, шуңа күрә кабер казу өчен кешеләрне чакырып йөрмиләр, мәет барлыгын һәм бүген күмеләчәген белүгә авылның ир-атлары, егетләре зиратка кабер казырга җыела, каберне мулла күрсәткән яисә мәет үзе яки аның якыннары алдан ук тәгаенләп куйган урында казыйлар. Кабер казу тәртипләре мөселман дине кануннарына туры китерелеп башкарыла, мәетнең буе кадәрле җир кызыл балчыкка кадәр казыла һәм мәетне урнаштыру өчен кыйблага табалап ләхет алына. Бу очракта кызыл балчык беркадәр мифологик эчтәлеккә ия, чөнки татарларның мифологик күзаллауларында кеше кызыл балчыктан яратылган дип исәпләнә, тиккә генә бүген дә татар телендә «кызыл балчыктан яратылганбыз, шушы балчыкка кайтабыз, шушы балчыктан кубарылачакбыз», дигән гыйбәрә яшәми [Брусько, 2013, с. 182].

Ләхетне теләсә кемнән алдыртмыйлар, аны бу эшнең рәтен белгән кешеләр генә ала. Ләхет буе белән мәет сыярлык булып, ишелмәслек итеп алынырга тиеш. Ләхетне каплар өчен башлыча имәннән ясалган махсус нык такталар алына. Кабер казучылар алдан ук барысының да хәстәрен күреп, баш казыкны да әзерләп китәләр. Мәетне күмүчеләр кабыкны җиргә куялар һәм кабергә, мәетне кабул итү өчен, аның иң якыннарыннан өч кеше төшә, аларга мәетне махсус тастымаллар белән тотып, өстән өч кеше бирә. Мәетнең иң соңгы юлы – ләхеткә урнашуы иң якын кешеләре ярдәмендә башкарыла. Бу очракта гаилә ныклыгы, нәсел әрвахлары белән бәйләнгәнлек, аларның ярдәмен тоеп, алга таба яшәү тәртибен саклауны күрергә, татар этикетын, тәрбиясен аңларга мөмкин. Мәетне кабул итеп алган иң якын кешеләре аны ипләп кенә ләхеткә куялар һәм кәфенлеген бәйләп торган тасмаларны чишәләр. Моны мәетнең аннан сорау алырга дип килгән фәрештәләр Мөнкир белән Нәнкир каршына утырып, аларның сорауларына җавап тоту тиешлеген күз алдында тотып эшлиләр. Мөселман динендәге татарлар күзаллавынча, мәетне җирләүчеләр 40 адым атлап китүгә аның каршына әлеге ике фәрештә килеп сораулар бирә башлыйлар. Әгәр дә сорауларына дөрес җавап бирсә, кабердән бер тавыш та килми, ә инде дөрес булмаса, мәетне бик интектерәләр, таяклар белән сугалар, кыйныйлар, аларның суккан тавышларын, мәетнең газаплы авазларын кабер өстендә утырып тын калган мулла да ишетә имеш. Мәетне ләхеткә уранаштырып бетергәч, ләхет такталары белән каплыйлар, каберне балчык белән күмәләр, мәетнең башы куелган якка баш казык урнаштыралар. Мәет гүргә иңдерелгәч, кабернең дүрт чатына мәетнең дүрт якын кешесе утыра, калганнар кабер тирәли баса һәм мулла дога укый. Дога тәмамлангач, бар килгәннәргә мәетнең якыннары сәдакалар өләшә, сәдакаларның күләме, тәртибе һәр авылның үз кагыйдәләренә карата

билгеләнә. Сәдәкаларны, башлап, мәетнең якыннары, аннан теләге булганнар өләшә. Мәетне күмүгә бәйле мәшәкатьләр бетүгә, мулла кабер өстендә тын тыңларга кала. Тын тыңлар өчен, баш казыкка табарак үзенең таягын кадый, һәм күмүчеләр 40 адым үткәч, кабердән килгән авазларны тыңлый башлый. Бу гамәл әгәр дә мәет Мөнкир белән Нәнкирнең теге яисә бу соравына җавап бирә алмый торса, мулла булышыр, дигән өмет белән башкарыла [Брусько, 2013, с. 188]. Шуңа күрә дә мөгаен халык телендә әлегә кадәр:

Атнакич үлсә идем,  
Җомга көн җомгага хәтле  
Гүремә керсә идем,  
Сөалемне белсә идем!  
[Галиуллин, 2019, б. 207]

кебек мөнәҗәт текстлары яшәп килә. Мәетне күмү йоласында катнашканнар һәрберсе үз өйләренә кайта, өйләренә кергәнче, гадәттә, үлем аларга ияреп кермәсен дигән ышану нигезендә, мал абзарына кереп чыгалар. Имеш, үлем ияреп кайткан булса, ике аяклыга түгел, дүрт аяклыга ияреп кайткан булса, ике аяклыга түгел, дүрт аяклыга иярсен. Кабер өстендә тынга калган мулла мәет чыккан йортка кайтып, тагын бер кат дога укый, мәетнең якыннары аңа аталган бер савыт онны һәм авылда кабул ителгән күләмдә акчалата сәдака бирәләр. Аның белән бергә мәетне искә алу көннәрен, сәгатьләрен билгелиләр, мәетнең рухына Коръән чыгу, кырык ясин уку кебек саваплы, шул ук вакытта бик җаваплы башкарылырга тиешле гамәлләр турында да сөйләшәләр. Авыр югалту кичергән гаилә акрынлап мәетне искә алу кичәләрен үткәрү мәшәкатьләренә керешә. Моның өчен өй юганда урыннарыннан кузгатылган әйберләрне кире урнаштыру, челтәр пәрдәләрне киптереп кире элү, мәетнең өчесен үткәрү ашы өчен мал сую, кирәк-ярак, азык-төлек алу кебек гамәлләр башкарыла. Ул арада мәетнең кайбер киемнәрен, аның төсе итеп, бик якыннарына тарату эшләре дә оештырыла, мәетнең кулы, тәне тигән нинди генә кием булмасын барысы да беркат сулана, болар, тиешенчә эшләмәсәң, мәетнең рухы тынычсыз була дип башкарыла. Ул арада өчесе көне килеп җитә. Өчесен мәет күмгәннән соң өч тапкыр чыккан кояш белән саныйлар. Өченче тапкыр чыккан кояш көнне мулла билгеләгән вакытка аш әзерләнә, әлеге ашка башлап ир-атларны дәшәләр. Ир-атлар арасына якын туганнардан тыш күрше-күләннәрне дә, кабер казырга килгәннәрне дә атап чакыралар.

Әгәр дә искә алынучы мәет ир затыннан булса, мәет юуда катнашканнарның барысын да дәшү мәслихәт. Табынга утыруга мулла ясин сурәсен укый, беркадәр ислам дине кануннарына таянуның савабы, үлгәннәрнең рухы дога белән шатлануы турында вәгазьләр әйтә, догалар кыла. Догаларны, башлап, Аллаһы Тәгаләгә, пәйгамбәребез Мөхәммәдкә әле генә гүр иясе булган мәетнең рухына, әлеге гаиләдән дога көтеп ятучы бар әрвахлар рухына багышлый, багышлаганнан соң, табында утырган бөтен кешегә мәетнең якыннары авылда

билгеләнгән күләмдә сәдака өләшә. Сәдакаларны мулла кабат багышлый, шуннан соң гына табынга йола гадәте буенча әзерләнгән ашлар чыгарыла. Башлап мәетне искә алу табыны өчен атап суелган сарык итеннән пешерелгән токмачлы аш, аш артыннан җимешле дөге бәлеше бирелә. Бәлеш янына бер касә эретелгән атланмай куела, бәлешне, гадәттә, табынчы вазифасын үтәүче – бәлеш өләшүче кисә. Ул бәлешнең капкачын табында утыручыларга тигез итеп кисеп, өләшеп чыга, аннан бәлешкә әзерләнгән бер касә майны бәлеш эченә салып болгата, аннан соң гына һәр кешегә тигез итеп бәлешнең эчен салып чыга. Бәлештән соң табынга эре кисәкләп пешерелгән бәрәңге өстенә куелган калҗа чыгарыла. Калҗага мул итеп майда кыздыралган суган белән кишер сибелә. Калҗаны да табынчы һәркемгә тигезләп өләшеп чыга. Калҗадан соң, табынга акрынлап эчлеге берсеннән-берсе татлырак итеп ясалган бәлешләр, паштетлар чыгарыла, алар янына кеше саен сөтле чәй, башка төрле татлы камыр ризыклары чыгарыла, алар янына кеше саен җимешләр, лимон салынган яки сөтле чәй, башка тәгамнар куела. Чәй эчү тәмамланганнан соң, мулла табын әзерләүчеләргә, мәетнең рухын шатландырып догалар укыта алуларына рәхмәтләрен әйтә, кабат дога укып, табынны тәмамлый. Күп кенә татар авылларында Өчесенә дә ирләрдән соң хатын-кызларны чакыру гадәте кереп бара. Бирегә күрше-күлән, туганнардан исәпләнгән хатын-кызлар белән бергә төн саклаучылар, кәфен кисүчеләр, су алып кайтучылар, җыеп әйткәндә, мәетне озату гамәлләрендә катнашучыларны чакыралар. Бу юлы искә алу табыны түренә абыстайны утырталар, ул тиешле догаларны укып, шулай ук багышлый, сәдакалар өләшенә, табынга алдагы тәртиптә ризыклар чыгарыла. Искә алу мәҗлесләреннән Өчесен уздыргач, гаилә мәетнең Җидесенә әзерләнә башлый. Җидесе исәбе дә мәет гүр иясе булганнан соң чыккан җиденче кояш белән алып барыла. Бу мәҗлескә хатын-кызлар дәшелә. Гадәттә, кеше саны тагы да күбрәк була. Бирегә дә туганнар, күрше-күлән белән беррәттән мәет озатуга катнашы булган һәркем чакырыла. Чакырылган кунаклар үзләре белән табынга куярлык, тотарлык берәр төрле ризык китерәләр, хуҗалар аларны онытмыйча табынга чыгарырга һәм алып килгән кучтәнәчләрдән дә авыз итәргә тәкъдим итәргә тиеш.

Җидесе мәҗлесе тәртибе дә нәкъ шулай ук: табын түренә абыстай утыртыла, ул тиешле догаларны укып багышлый, сәдакалар өләшенә, аннан табынга ризыклар чыгарыла. Ризыклардан авыз иткән арада гаилә кичергән хәсрәткә бәйле чыгарылган бәет булса, ул укыла, аны күз яшьләрен әллә ни күрсәтмәскә тырышып, мәетнең туганнары, якыннары, күршеләре тыңлый. Бәет чыгаруны махсус бәет чыгаручыга кушарга мөмкиннәр, күп очракларда бәетне гаилә әгъзаларының берсе чыгарырга мөмкин. Бәет эчтәлегендә мәетнең беркадәр тормыш юлына кагылышлы биографик белешмәләр бирелә, аннан соң үлемнең беркемне дә аямый алып китүен, гомерләрнең санаулы булуын, барысының да Аллаһы кодрәтеннән генә торуын,

мәетнең моннан соңгы шатлыгы, ризыгы якыннары аның өчен атап кылган догалар булуы турында сөйләнә. Мәсәлән:

Үлем үкенечсез булмый,
Бик тә, бик тә үкенәм.
Кара кайгыларга салдым
Барчагызны, мин беләм.
Өсләремә япты кинәт
Ходай кара юрганын.
Күз алдымнан үттегез
Сез, әти-әни, газизем!
Сеңелем Чулпан, кече энем,
Бердәнберем Алиям!

[Галиуллин, 2019, б. 207]

Җидесеннән соң мәетнең Кырыгын уздыралар, бу табынга чакырылучылар мәетнең җенесенә бәйле була. Ир-ат мәеткә – ирләр, хатын-кызга хатын-кызларны дәшәләр. Чакырылучылар янына, атап, кырык ясин һәм Коръән чыгучылар да дәшелә. Искә алу мәҗлесе алдагылары тәртибендә башкарыла. Кырыгы чакырылган кешеләрнең саны шактый күп булу, мәетне зурлап, ерак туганнарның да кайтуы белән аерылып тора. Алдагы искә алу көне – Илле бере. Бу көнне әллә ни зурлап үткәрмәсәләр дә, мәетнең якын туганнары үзара җыелышып, дога кылдыралар. Бу көн татарлар күзаллавында мәет өчен аеруча авыр көннәрдән исәпләнә, чөнки нәкъ менә шушы көнне мәетнең тәненнән сөякләре аерылыр, ди. Илле бере көнне, мәеткә җиңеллек килсен өчен, кошларны ашату гадәте дә бар. Кышын җимлекләр ясап, анда төрле орлыклар, ипи валчыклары салалар, ә инде җәен булса, күгәрченнәргә җим сибәләр [Брусько, 2013, с. 166]. Ничек кенә булмасын, мәетнең якыннары алга таба да аны догалар белән искә алалар, алар уенча, ул да әрвахларның берсенә әверелеп, кайвакыт яннарына күбәләк булып кайтып, аларның тормышларыннан беркадәр хәбәрдәр булуына ышаналар [Баязитова, 2015, б. 212]. Ышаналар гына түгел, шулай булуына өмет тә итәләр. Алга таба мәетнең якыннары каберне рәтлиләр, яз җитүгә агач утырталар, чардуган коралар, гөлләр утыртып, беркадәр бизиләр.

Алга таба үткәреләсе искә алу мәҗлесе – мәетнең Елы. Аңа бик зурлап әзерләнәләр, зиратка барып, каберне рәтлиләр, куелмаган булса – чардуган, баш казык урынына мәетнең исеме, туган һәм үлгән еллары, догалардан өзекләр язылган таш куялар. Мәетнең елына туганнарның барчасы диярлек җыела, аларга өстәп, нәсел-ыру вәкилләре дә чакырыла, күрше-күлән дә ел мәҗлесенә чакырылмый калмый. Гадәттә, мәетнең елын башта ир-атларны чакырып, аннан хатын-кызларга дәшеп, ике тапкыр табын корып үткәрәләр. Еллык ашны үткәрү тәртибе алдагыларыныкы кебек. Биредә төп игътибар мәетнең нәсел-ыруының җыелуына бирелә. Бу исә, үз чиратында, мәетнең башка әрвахлар рәтендә кабул ителә башлавын тану, исән-

нәргә аның алдында да йөз аклыгын саклау бурычы куелуын төшендерүне тәэмин итә.

Татар халкы гореф-гадәтләрендә үлем-күмүгә бәйле йолалар әле дә төгәл кагыйдәләргә утыртылган эзлекле башкарылучы күренешләрдән торалар. Аларда төп игътибар үлемнең үзенә түгел, ә мәңгелек йортка күчкән әрвахның фани дөньяда калган нәсел вәкилләре белән элемтәләрен саклап, алар күңелендә яшәүне тәэмин итүгә юнәлтелгән бар гамәлләрне тиешенчә башкаруга бирелә. Ә ул гамәлләр борынгы заманнардан бирле татар кешесе акылында формалашкан ышануларга нигезләнгәннәр һәм шулар бәрабәренә буыннар алмашынуда кешелек кыйммәтләре саклануны тәэмин итүче бөек көчләрнең берсе буларак аңланалар. Нәтиҗәдә, үлем белән яшәү төшенчәләренең бер-берсеннән аерылгысыз бербөтен булуларын тәэмин итәләр.

**Әдәбият**

*Урманчеев Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. 1 т. Казан: Мәгариф, 2008. 303 б.

*Баязитова Ф.С.* Халык традицияләре лексикасы. Мифологик персонажлар, ышанулар (җирле сөйләшләр һәм фольклор текстлары яссылыгында). Казан, 2018. 823 б.

*Галиуллин Т.Н.* Бәетләрдә халык хәтере. Казан, 2019. 312 б.

*Брусько З.М.* В круге жизни. Казань: Ихлас, 2013. 223 с.

*Баязитова Ф.С.* Халык традицияләре лексикасы: Соңгы туй. (Дини фольклор һәм җирле сөйләшләр яссылыгында). Казан, 2015. 711 б.

Мөнәҗәтләр һәм бәетләр / төз. К.М. Хөснуллин, фәнни ред.: М.Х. Бакиров, С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Раннур, 2001. 724 б.

***Җәүһәрова Фәнзилә Хәким кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының*
*Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендәге стратегик тикшеренүләр*
*фәнни белем бирү үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 94(47)

*М.Р. Гайнанова*

# САДРИ МАКСУДИ
# ҺӘМ I ТӨРЕК ТАРИХ КОНГРЕССЫ

В статье освещается научная деятельность татарского интеллектуала Садри Максуди (1878–1957) в Турецкой Республике. Рассматривается его вклад в изучение истории тюркских государств в 1930-е гг. Основное внимание уделяется анализу доклада «Исторические факторы», где С. Максуди рассматривает все причины и факторы, влиявшие на историю развития человеческих цивилизаций. Исследовав данный вопрос, он определяет девять основных факторов оказавших влияние на поворотные исторические моменты и общественно-социальные преобразования. В работе также предпринята попытка анализа взаимодействия лидеров российского мусульманского общественного движения С. Максуди и З. Валиди по историческим вопросам в Турции и проанализирована работа З. Валиди «Семнадцать занесённых песком городов и Садри Максуди бей».

**Ключевые слова:** Садри Максуди, история тюркских народов, Турция, I Турецкий исторический конгресс, З. Валиди.

The article highlights the scientific activities of the Tatar intellectual Sadri Maksudi (1878–1957) in the Republic of Turkey. His contribution to the study of the history of Turkic states in the 1930s is considered. The main attention is paid to the analysis of the report «Historical Factors» where S. Maksudi examined all the causes and factors that influenced the history of the development of human civilizations. Having examined this issue he identified nine main factors that influenced turning points in history and social transformations. The work also attempts to analyze the interaction between the leaders of the Russian Muslim social movement S. Maksudi and Z. Velidi on historical issues in Turkey and analyzes the work of Z. Velidi «Seventeen Sand-Buried Cities and Sadri Maksudi Bey».

**Keywords:** Sadri Maksudi, history of the Turkic peoples, Turkey, I Turkish Historical Congress, Z. Velidi.

XX гасырның беренче яртысында Төркия яңарыш чорын кичерә. Ататөрек вазгыяте җәмгыятьне үзгәртә: яшь республика оешканнан соң ук социаль, сәяси, икътисади, хокукый һәм мәдәни реформалар үткәрелә, шул исәптән, мәгариф өлкәсендә дә зур үзгәрешләр була. Дәүләт идеологиясе үзгәрә, ягъни «госманчылык» урынына «төркичелек» кабул ителә. Ататөрекнең төп максаты – дәүләтне сәяси нигездә берләштерү һәм төрекләрнең милли үзаңын үстерү. Шуңа бәйле рәвештә, төрки халыклар тарихын өйрәнүгә багышланган тарихи тикшеренүләр үткәрелә. Бу мәсьәләләр белән махсус оештырылган галимнәр төркеме шөгыльләнә, ә татар эмигранты С. Максуди аның бер әгъзасы була.

1932 елда төрек милләте өчен мөһим вакыйга була: Төркия Җөмһүрияте президенты Ататөрек инициативасы белән 2–11 июль-

дә I Төрек тарих конгрессы үткәрелә. Чараның ачылыш тантанасын Ататөрек үзе башлый һәм барлык җыелышларда тыңлаучы буларак катнаша. Конгрессның максаты – тарихи тезислар белән рәсми таныштыру һәм тарих дәреслекләре эшләү программасын кабул итүдән гыйбарәт була.

«Төрек тарихын өйрәнү җәмгыяте» (Türk Tarihi Tektik Cemiyeti) рәисе Йосыф Акчура[1] конгрессның әзерлек этабында, аны үткәрүдә зур көч куя һәм күпчелек утырышларны үзе алып бара.

Конгресста төрки халыкларның тарихы буенча төп фәнни темалар формалаша:

1. Борынгы тарих һәм тарихи чорларга кагылышлы чыганакларны өйрәнү, куллану. Бу темага Афәт Инан[2], Фуат Көпрүлү[3], Хәсән Җәмил[4] чыгыш ясыйлар.

2. Төрки телләр, аларның чыганаклары һәм башка чит телләргә йогынтысы. Самих Рыфат[5] һәм Әхмәт Җафәроглу[6] арасында бәхәс туа.

3. Географик һәм табигый үзгәрешләр сәбәбе белән Үзәк Азиядән Халыкларның бөек күченеше процесслары. Тарихчылар Көнбатышка миграциянең төп сәбәбе Үзәк Азиядә барлыкка килгән корылык белән бәйле булуын ачыклыйлар. Дискуссиядә чыгыш ясаучылар төркиләрнең Үзәк Азиядән Көнбатышка, Көнчыгыш Европага күченүе бу төбәкләрнең мәдәнияте һәм иҗтимагый формацияләре үзгәрүгә китергәнен исбатлыйлар. Бәхәсләрдә Садри Максуди, Зәки Вәлиди[7] һәм Рәшит Галип[8] катнаша.

4. Тарих китаплары һәм дәреслекләр әзерләү һәм бастырып чыгару. Конгрессның бу өлешендә Аврам Галанти[9], Йосыф Акчура һәм Фазыл Нәзми[10] чыгыш ясый [Koçak, s. 22–23].

Әлеге чара тарих укытучылары өчен үткәрелсә дә, катнашучылар һәм тыңлаучылар арасында Төркия Җөмһүриятенең киң фәнни җәмәгатьчелеге, тарих белән кызыксынучылар күп була. Татар хал-

[1] Йосыф Акчура (1876–1935) – сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, журналист, Төрек тарих җәмгыятенең җитәкчесе (1932–1935).

[2] Афәт Инан (1908–1985) – төрек тарихчысы, социолог, Ататөрекнең тәрбиягә алган кызларының берсе.

[3] Фуат Көпрүлү (1890–1966) – төрек язучысы, тарихчы, тюрколог, сәясәтче, Төркиянең тышкы эшләр министры (1950–1955, 1955–1956).

[4] Хәсән Җәмил (1879–1967) – тарихчы, сәясәтче, Төрек тарих җәмгыятенең җитәкчесе (1935–1941).

[5] Самих Рыфат (1875–1932) – шагыйрь, филолог, сәясәтче, Төрек теле җәмгыятен оештыручыларның берсе.

[6] Әхмәт Җафәроглу (1899–1975) – азәрбайҗан чыгышлы галим, тюрколог, Истанбул университеты профессоры.

[7] Зәки Вәлиди (Әхмәтзәки Вәлиди Тоган, 1890–1970) – галим, тарихчы, тюрколог, сәясәтче.

[8] Рәшит Галип (1893–1934) – сәясәтче, тарихчы, Төркиянең милли мәгариф министры (1932–1933).

[9] Аврам Галанти (1873–1961) – сәясәтче, мөгаллим.

[10] Фазыл Нәзми (1875–1949) – сәясәтче, Истанбул университеты профессоры.

кының мәшһүр зыялылары да килә. Мәсәлән, Муса Бигиев конгресс утырышларында яңгыраган гыйльми чыгышларны тыңлый, алардан соң үткәрелгән фикер алышуларда катнаша [Муса Җаруллах Бигиев, б. 304–308].

Төркиянең Бөек Милләт Мәҗлесе вәкиле, Әнкара юридик факультеты профессоры С. Максуди 7 июльдә «Тарихи факторлар» (Tarihin Amilleri) темасына чыгыш ясый. Докладында ул мөһим сорауларга җавап эзли, тарихка тәэсир иткән сәбәпләрне, зур вакыйгаларга һәм иҗтимагый-социаль үзгәрешләргә китергән факторларны барлый һәм фикерен мисаллар белән ныгыта.

Садри Максуди XIX гасыр ахырын һәм XX гасырны тарихны өйрәнү дәвере дип атый. Бу чорда галимнәр тарихи тикшеренүләргә зур әһәмият биреп, мөһим ачышлар ясау һәм саллы тикшеренүләр үткәрү белән халыкка хезмәт итәләр, ди [Maksudi, s. 341]. Ул һәр тарихи чорның ике төп проблемасын аерып чыгара: 1) кешелек үсешенә йогынты ясаган факторлар һәм сәбәпләр; 2) кешелекнең тарихи үсеш максаты. Бу классификация буенча, тарихның һәр чорында тарихчылар ике нәрсәгә игътибар итәләр. Бер яктан, алар вакыйгаларны һәм күренешләрне билгеләргә тырышалар, икенче яктан, бу вакыйгаларга тәэсир иткән факторларны бәялиләр.

С. Максуди кешелек цивилизациясе үсешенә, тарихына йогынты ясаган тугыз сәбәпне билгели [Maksudi, s. 343]:

1. Физик һәм географик сәбәпләр. Максуди сүзен төрле галимнәрнең идеяләренә мөрәҗәгать итүдән башлый. Мәсәлән, Монтескьёның физик һәм географик шартлар белән халыкның тормышы арасындагы тыгыз бәйләнешне беренче күрсәткән галим булуын ассызыклый. Бу сәбәпләрне кешелек тарихына тәэсир иткән беренчел фактор дип раслый. Британия галиме Бокль географик сәбәпләрне кешелекнең социаль үсешендә бердәнбер фактор дип санамый. Цивилизация үскәндә рухи сәбәпләрнең иҗтимагый тормышка йогынтысы артуын, ә физик сәбәпләрнең роле икенче урында калуын билгели. Марксистлар исә физик һәм географик сәбәпләрне инкяр итмиләр, алар икътисади сәбәпләргә зур әһәмият бирәләр, дип аңлатып үтә [Maksudi, s. 343–344]. С. Максуди бер милләтнең, физик һәм географик сәбәпләрдән тыш, яшәгән җирләреннән климат шартлары аркасында китәргә мәҗбүр булуына һәм, нәтиҗәдә, миграция, яулап алу күренешләре барлыкка килүгә игътибар итә [Maksudi, s. 344].

2. Рухи (психологик) факторлар. С. Максуди рухи факторларны теоретик нигезләгән Габриель Тард карашлары аша аңлата, чөнки, Хәлил Иналҗык билгеләп үткәнчә, *«Максудига хезмәтләре һәм фикерләре белән нык тәэсир иткән шәхес – Тардтыр»* [İnalcık, s. 51]. Француз социологы фикеренчә, цивилизация үсешендә иң мөһиме – рухи факторлар. Болар – ачышлар һәм алдынгы технологияләрне охшатып кабатлаулар [Тард, с. 89]. Максуди да бу фикер белән килешә: *«Социаль тормышта һәм цивилизация тарихында ачышлар һәм*

*аларны тарату зур роль уйный. Габриель Тард боларны фәнни яктан исбатлап, зур хакыйкатьне күрсәтте»* [Maksudi, s. 347].

3. Бөек идеяләр. Идеалистик фикер ияләре әйтүенчә, максатлар – кешелекне үсешкә этәрүче төп фактор. Кеше бу җиһанда – хайван түгел, ә бөек җан иясе, рухлары югары фикерләр белән сугарылган зат. Гаделлек, бәхет, азатлык, тигезлек, дәүләт һәм хөррият – кеше җанына салынган иң югары идеаллар. *«Безнең заманыбызда барлыкка килгән бөек идеалларның берсе – милләт идеясе ул»,* дигән Максуди, дәвам итеп, кешелек үсеше белән бергә югары идеалларның да артуын билгели, шул ук вакытта максатны тормышка ашыруга бернинди көч тә комачаулый алмый, дигән фикер уздыра [Maksudi, s. 347–348]. С. Максуди Кант белән Гегель фикерләренә мөрәҗәгать итә. Кант сүзләренә караганда, кеше тормышында иң зур фактор – вөҗданга нигезләнгән югары әхлак тәртибе. Гегель буенча, дөнья белән идарә итә торган фактор – рух, дөнья рухы ул [Maksudi, s. 347].

4. Раса (ырк) факторы. С. Максуди раса проблемасын иң бәхәсле һәм чишелмәгән темалардан саный. Ул тарих һәм социология галимнәрен кызыксындыра, әмма *«төркиләргә бу мәсьәлә күптән билгеле. Тарих китабында үзебезнең аерым урынны алып торабыз»* [Maksudi, s. 348–350].

5. Сугыш, яулап алулар һәм миграция. Максуди фикеренчә, бу күренешләр һәрвакыт булган һәм тарих – моңа үзе дәлил. Мисалга галим борынгы чорга мөрәҗәгать итә һәм яулап алуларның ике сәбәбен күрсәтә: *«иске мәдәниятне җимерү һәм яңасын булдыру»*. Ул тарихта барлыкка килгән миграцияләр сәбәпләренең шәхесләр, икътисади һәм физик факторлар белән бәйле булуын ачыклый [Maksudi, s. 350–351].

6. Эволюция. Кешелек тарихында алгарыш (прогресс) фикере борынгы заманнардан башлана. Бу күренеш Лаплас, Ламарк, Дарвин һәм Спенсер тикшеренүләре ярдәмендә «эволюция законы» дип аталган фәнни төшенчә булып формалаша. С. Максуди әлеге фикер ияләренең карашларын аңлатып уза һәм мәсьәләнең фәнни яктан тулысынча чишелмәгәнлеген күрсәтә. Аныңча, кешелекнең иҗтимагый-тарихи үсеш процессында эволюция кичерүе бәхәссез хакыйкать булып тора. Максуди эволюциянең төрле факторларга бәйле бару ихтималына фәнни табышмак дип карый һәм сорауны ачык калдыра [Maksudi, s. 351–352].

7. Икътисади сәбәпләр. С. Максуди бу бүлектә Карл Маркс һәм аның тарихи материализм карашларына мөрәҗәгать итә. Ул икътисади факторларның тарихка ясаган көчле йогынтысы Аристотельнең «Дәүләт» әсәрендә үк каралуын искәртә. Ул XIX гасыр ахырыннан индустриаль үсеш, завод-фабрикаларның саны арту һәм шуңа бәйле рәвештә эшчеләр сыйныфы барлыкка килү; капиталистларның эшчеләр хокукларын кайгыртмавы, хәтта аларның иң гадел таләпләрен дә канәгатьләндермәве аркасында эшчеләр сыйныфында ризасызлык һәм тәртипсезлек башлану – К. Маркс тәгълиматы туының җирлеге,

ди [Maksudi, s. 357]. К. Маркс капитал системасын җимереп, эшчеләр сыйныфын азат итү хакында программасын халыкка җиткерә. Бу яңа карашлар зур социаль вакыйгаларга этәрә һәм революция китереп чыгара [Maksudi, s. 357]. Шулай итеп, К. Маркснең карашлары кешеләрнең игътибарын җәлеп итә, яңа идеяләре аларда теләктәшлек таба.

С. Максуди бу теманы объектив анализларга тырыша һәм фәннилеккә нигезләнә. К. Маркс карашларының фәнни кыйммәте юк дисә дә, аның йогынтысын һәм нәтиҗәләрен ассызыклаудан курыкмый, үзен исә, тирән фикер иясе һәм яхшы социолог дип атый. С. Максуди икътисади факторларның социаль реформаларга тәэсир итүен мөһим дип саный [Maksudi, s. 352–358].

8. Тарихта халыкның роле. С. Максуди халыкның тарихта нинди роль уйнавы турында фикер йөртә. Аның күзлегеннән, җәмгыять ихтыяҗларына бөтенләй игътибар ителмәгән тираник дәүләтләрдә дә халык иҗтимагый һәм тарихи тормышта мөһим фактор булып кала [Maksudi, s. 360].

9. Бөек шәхесләр. Бөек шәхес – кешелек тормышында мөһим тарихи, иҗтимагый һәм гражданлык үзгәрешләре китереп чыгарган, яңа агымнар тудырган кеше. Милләте алгарышында тирән эз калдырган бөек шәхесләр дип С. Максуди Конфуцийны (б.э.к. 551 – б.э.к. 479), Галилео Галилейны (1564–1642), Н. Коперникны (1473–1543), Р. Декартны (1596–1650), Наполеон Бонапартны (1769–1821) һ.б. күрсәтә. Төрки халыклардагы Тогрул бәк (якынча 990–1063), Мәлик шаһ (1055–1092) исемнәрен атагач, С. Максуди залда утырган Гази Мостафа Кәмалны (1881–1938) бөек шәхесләр исемлегенә кертә һәм аның бу сүзләрен залда утырган катнашучылар алкышлар белән каршы ала. С. Максуди мондый шәхесләрне милләт үзе барлыкка китерә һәм алар, тарихны үзгәртеп, зур эшләр башкаралар дип белдерә [Maksudi, s. 360–364].

С. Максудиның конгресста ясаган докладына төрек галимнәре уңай бәя бирә. Мәсәлән, Б. Эрсанлы тарих фәненең этапларын тәртипкә салып аңлатуына игътибар бирә. Көнбатыш фикер тарихын һәм андагы идеяләрне яхшы белгән С. Максуди турыдан-туры тарих фәне турында сөйләгән бердәнбер кеше булды, дип күрсәтә [Ersanlı, s. 145].

Конгресс барышында З. Вәлиди белән Р. Галип һәм С. Максуди арасында бәхәс кузгала. Соңыннан сүзгә Шәмсетдин Гүналтай[1] да кушыла. Бәхәс Урта Азиядә ком астында калган унҗиде шәһәр мәсьәләсенә кагыла.

Конгресста Р. Галип «Төрек ыркы һәм мәдәният тарихына гомуми караш» дип исемләнгән доклад ясый [Galip, s. 99–161] һәм түбәндәге фикерләрне ассызыклап чыга:

1. Ырклар (расалар) кешелекнең зур гаиләләрен тәшкил итә. Шуңа күрә милли тарихны тикшергәндә, ыркны өйрәнүдән башларга тиеш.

[1] Шәмсетдин Гүналтай (1883–1961) – тарихчы, дәүләт эшлеклесе, Төркия Җөмһүрияте Премьер-министры (1949–1950).

2. Климат үзгәреше цивилизацияләр үсешенә турыдан-туры йогынты ясый [Ersanlı, s. 146].

Әлеге фикерләргә С. Максуди да кушыла.

Рәшит Галипнең чыгышыннан соң, 3 июль көнне З. Вәлидигә «Урта Азиядә ком астында калган / калмаган шәһәрләр» турында сөйләү өчен сүз бирәләр. Утырышны алып баручы Р. Галип чыгыш барышында вакыт турында кисәтеп караса да, З. Вәлиди нотыгы сузыла. Ул борынгы чорда корылыкның еш булмавын чыганаклар ярдәмендә дәлилли, сүз кагылган шәһәрләр (Алмалык, Атбаш, Баласагун, Барсхан, Илебалык, Суяб һ.б.) урнашкан урыннарны билгели һәм аларның ком астында калмавын исбатларга тырыша. 7 июльдә З. Вәлиди белән конгресста катнашучылар арасындагы бәхәсләр кискен төс ала [Velidi, 2010, s. 167–176, 369–376].

З. Вәлиди үзенең нотыгында әл-Бируниның кайсы кавем вәкиле булганлыгы мәсьәләсен күтәрә. Бурса шәһәрендә табылган язудан әл-Бируни цитатасына нигезләнеп, аның төрки чыгышлы булуы турында фикер әйтә: *«Әл-Бируни китабының һәр урынында төркиләргә бик күп әһәмият бирә. Ул шәһәрләрне, тауларны, ташларны аңлата. Төркиләрнең гореф-гадәтләре, ризыклары, гомумән, һәр нәрсәләре турында яза. Соңыннан төрки табибларыннан күргән игелекләр хакында да сөйли. Ул табибларның тәһарәт алуларын, үләннәр җыеп нәрсәдер әзерләгәннәрен күрә. Ягъни, әл-Бируниның төрки булуында һичбер шөбһәм юктыр»* [Velidi, İkinci oturuş, s. 376].

Бу фикер тискәре кабул ителә [Birinci Türk tarih kongresi, s. 377]. Рәшит Галип болай ди: *«Зәки Вәлиди бәй аңлаткан Әбү Рәйхан әл-Бируниның төрки булуы мәсьәләсе – безнең мәмләкәтебездә борынгы заманнардан мәгълүм булган бер факттыр. (...) Әбү Рәйхан әл-Бируниның тормышы һәм төркилеге турында әсәр бар. Җәмгыятебезнең матди хәле аркасында ул әлегә басылып чыкмады. Хезмәт Закир Кадыйри бәй тарафыннан язылды. Безнең җәмгыятьнең финанс мөмкинлекләре булуга ук, китап дөнья күрәчәк»* [Galip, s. 377]. Шулай итеп, З. Вәлидинең әлеге теманы яңа ачылган хакыйкать итеп күрсәтүе тәнкыйтькә дучар була.

Тәнәфестән соң сүзне С. Максуди ала. Ул З. Вәлиди чыгышындагы ике мәсьәләне аерып чыгара: 1) Корылык; 2) Борынгы төрки шәһәрләр. Корылык проблемасы Р. Галип тарафыннан ачыкланганнан соң, С. Максуди бу темага кабат әйләнеп кайтырга кирәк дип санамавын искәртә һәм игътибарын борынгы төрки шәһәрләргә юнәлтә [Üçüncü oturuş, s. 389].

С. Максуди тәнкыйте З. Вәлидинең Тарих җәмгыятенә җибәргән мәкаләсендә һәм трибунадан сөйләгән нотыгында мисал итеп ялгыш чыганаклар китерүенә һәм аларның битләрен күрсәтмәвенә кагыла. *«Әфәнделәр, теге яки бу мәсьәләнең дәлилләре теге яки бу әсәр битендә булса, чыганакларны һәм битләрне күрсәтү тәнкыйтьче өчен берни түгел. Ләкин ул аларны күрсәтми икән, бу аның ваемсызлыгын һәм ялкаулыгын күрсәтә. Мондый гамәл дүрт-биш битле мәкаләдә*

*бернічә тапкыр кабатланса, тәнкыйтьне укыган кеше тәнкыйтьченең сүзләренә шикләнеп карарга тиеш була»* [Üçüncü oturuş, s. 389].

С. Максуди, чыганаклардан мисаллар китереп, аларның З. Вәлиди дәлилләре белән туры килмәвен ассызыклый, чыгышын кискен сүзләр белән тәмамлый: *«Зәки Вәлиди бәй билгеле дип игълан иткән шәһәрләрнең берсе дә ачыкланмады. Аның бу мәсьәләдә бөтен гаепләүләре нигезсездер. Тәнкыйтьләре ялгыш чыганакларга, дәлилсез мисалларга корыла. Билгеле ки, эш – барлык бу тәнкыйтьләрнең фәнни мәсьәләне чишү өчен түгел, бөтенләй башка максат белән әйтелгән булуында.*

*Әфәнделәр, югары уку йортында укыткан укытучының Мәгариф министрлыгына һәм фәнни оешмага, Тарих җәмгыятенә җибәргән мәкаләсендә андый системалы хаталар ясарга хакы бармы, конгресс әгъзалары үзе хәл итсен»* [Üçüncü oturuş, s. 397].

С. Максудиның конгресстагы әлеге чыгышы «Hakimiyet Milliye» газетасында аерым биттә басылып чыга [Sadri Maksudi Bey Zeki Velidi Beyin esassız fikirlerine cevap veriyor, s. 2].

Шәмсетдин бәйнең бәхәскә кушылуы аны тагын да кискенләштерә: *«Биредә Зәки Вәлиди бәй белән Садри Максуди бәйнең бәхәсләрен тыңлаган вакытта, Зәки Вәлиди бәй коточкыч роль уйнаган башка бер конгресс хәтеремә килде.*

*Ул конгресста да Зәки Вәлиди бәй белән Садри Максуди бәй шулай ук төркиләр мәсьәләсе аркасында каты бәрелештеләр: патшалык җимерелгәннән соң, Русиядәге халыклар үзләренең милли өлешен саклап калырга тырышканда, төркиләр башта Мәскәүдә, аннары Уфада килешү төзеделәр һәм төркиләр исеме белән берләшергә, союз булдырырга тырыштылар. Ләкин Зәки Вәлиди бәй Уфа конгрессында «төрки» исеме астында төркиләрнең берләшүенә каршы чыгучы булды һәм башкортларны төркиләр җәмгыятеннән аерды (залдан «оят» дигән сүзләр яңгырый). Зәки Вәлиди бәй каршылык күрсәтә һәм милли бердәмлек хисенә, төрки телгә нигезләнеп бердәмлек төзергә ризалашмый. Русия төркиләренең аерым диалектлары, аерым культуралары, шәхесләре, татарлар, башкортлар, үзбәкләр, азәрбайҗаннар аерылалар, ди… Бу аларның таркалуына китерә.*

*Зәки Вәлиди бәйнең бу конгресста да шул ук рольне башкарасы киләме? Ләкин шуны белсеннәр: бу конгресс тирәсендә тупланган кешеләрнең зиһене милләт уты белән яна. Бу ут каршында теләсә нинди каршылык, омтылыш эреп бетәчәк (залда көчле алкышлар)»* [İkinci oturuş, s. 400].

Шәмсетдин Гүналтайның сүзләрен конгресска җыелганнар алкышлап хуплый. Утырышның рәисе, корылык мәсьәләсе, ниһаять, хәл ителде дип, бу утырышны тәмамлый [İkinci oturuş, s. 400].

Конгресстагы хәлләр турында С. Максуди дусты Г. Исхакыйга яза. Г. Исхакый исә Варшавадан җавап хатында З. Вәлидинең Венадагы эшчәнлеге турында сөйли һәм конгресс белән бәйле фикерләрен шулай җиткерә: *«Уфада улдыгым вакыт күрдегем тюркологларның*

*һәпсе Зәки Вәлиди әфәндедән бәхәс итде. Зәки Вәлиди Будапештайа киләрәк төрек тарихы корылтае хакында конферанс вирмеш. [...] Кәндесене икенче Галилей кеби гөстәрмәк өчен бөек гайрәт сарыф итмешдер» (Мин Уфада чакта күрешкән тюркологларның барысы да Зәки Вәлиди әфәнде турында сөйләде. Зәки Вәлиди Будапештка килеп, төрек тарихы корылтае хакында лекция укыган. [...] Үзен икенче Галилей итеп күрсәтү өчен күп көч түккән* (09.01.1933)) [Исхакый, б. 58–60].

Н. Өзбәк фикеренчә, I Төрек тарих конгрессында З. Вәлидигә каршы юнәлтелгән тәнкыйтьнең сәбәпләреннән берсе – С. Максуди белән З. Вәлиди арасында электән дошманлык булу [Özbek, s. 22].

Араларында үпкә, тәнкыйть булуга карамастан, З. Вәлидинең галим һәм танылган тарихчы булуын С. Максуди таный һәм бу фикереннән кире кайтмый. С. Максудиның «Төрек теле өчен» (Türk Dili İçin) [Maksudi, 1930, s. 233–234] китабында китерелгән мисаллар да моны дәлилли.

Конгресстагы чыгышларда яңгыраган тәнкыйтьләргә җавап бирү теләге белән З. Вәлиди 1934 елны Австриядә «Комга күмелгән унҗиде шәһәр һәм Садри Максуди бәй» исемле китабын әзерли. Китап өч бүлектән гыйбарәт булып, беренчесендә аның язылу максаты күрсәтелә (3–7 б.), икенче бүлек Садри Максуди һәм аның юлдашларына тәнкыйть белән сугарылган (7–34 б.), өченче бүлектә 1932 елны узган Тарих конгрессында яңгыраган Урта Азиядәге корылык һәм унҗиде шәһәр белән бәйле сорауларга җаваплар бирелә (34–52 б.).

Китап язуның төп мотивы С. Максуди белән конгресста узган бәхәс түгел, ә аннан соң Әхмәт Мүхип һәм Шәрәф бәйләрнең З. Вәлидигә каршы юнәлгән тәнкыйтьләре була: *«“Хакимияти миллия” газетасында (13 гыйнвар, 1934) Әхмәт Мүхип миңа каршы авыр сүзләр яза. Минем әхлагым һәм «Әнкара тарих конгрессында» тарихи чыганакларны ялган күрсәтүдә гаепләнүем турында фикер йөртә. Шулай итеп, мәкаләнең авторы минем якка авыр гаеп ташы ыргыта. Әдирнә шәһәреннән депутат Шәрәф бәй «Хакимияти миллия» газетасында (21 гыйнвар, 1934) чыккан мәкаләсендә мине начар әхлаклы булуда гаепли һәм утыз еллык эшчәнлегемә кара мөһер куярга тырыша»* [Velidi, 1934, s. 3]. З. Вәлиди үзенең бу тәнкыйтьләрне кире кагарга тиеш булуын аңлата.

Икенче өлештә З. Вәлиди С. Максуди белән Россиядән башлап Төркиягә кадәр дәвам иткән мөнәсәбәтләре турында яза. Үз күзлегеннән чыгып, Русиядә узган сәяси вакыйгалар турында фикерләре белән уртаклаша һәм С. Максудига, Г. Исхакыйга җитди гаепләүләр ташлый. Өченче өлешендә ул С. Максудиның Конгресста әйткән сүзләренә җавап бирә.

Тарих конгрессында (1932) бәхәс куптарган 17 шәһәр турында болай ди: *«Отрар, Җәнд, Сус, Янгикәнт, Сыгнак Атлак, Атбаш, Алмалык, Баласагун, Талас, Кулан, Барсхан, Суяб, Нүзкет, Сүткәнт, Илибалык, Селчи ком белән күмелгән дип карала. Тик бу шәһәрләрнең*

*берсе дә ком астында калмады. Аларның кайберәүләре бүген башка исемнәр астында әле дә бар. Ә ком астында калган шәһәрләрнең урыннары билгеле, санап узган шәһәрләр хәзер авылларга һәм башка торак пунктларга әйләнделәр»* [Velidi, 1934, s. 34–51].

З. Вәлиди С. Максудины һәм башка галимнәрнең үзләрен китапларны, чыганакларны дөрес күрсәтмәүдә һәм өземтә итүдә гаепли [Velidi, 1934, s. 34–51], барлык бәхәсләрне шәхси дошманлык белән бәйләп кабат аңлата.

М. Чокаев[1] китапка рецензиясендә болай ди: *«60 битлек китапта фәнгә бары тик 20 бит бирелгән, 6 бит биография һәм Зәки Вәлиди тарафынннан язылган китап, мәкаләләр исемлеге алып тора. Калган 34 биттә, ягъни брошюраның яртысыннан күбрәгендә, автор Садри Максуди, Гаяз Исхакый һәм татарларга каршы пропаганда һәм дошманлыкны аңлату белән мәшгуль»* [Из истории российской эмиграции, с. 122].

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: С. Максудиның тарихи карашлары Россия һәм Көнбатыш Европа ориенталистикасы йогынтысында формалаша, ләкин тарих белеменең объектив һәм оригиналь системасын булдырырга омтылышы төрки милли үзаң позициясеннән торып башкарыла.

Галим 1930 елларда төрек укучыларына, яшь буынга ата-бабаларның үткән шанлы тарихы, кешелек дөньясында төркиләрнең роле һәм урыны турында белешмәләр бирү теләге белән янып йөри. С. Максуди төркиләрнең тарихын күтәрүне үзенең бурычы итеп саный. I Төрек тарих конгрессында ул халыкның этник үзаңын уяту, милли бердәмлек идеясен тарату өчен тарихның зур әһәмияткә ия булуын һәм чыганаклардан, документлардан алынган мисалларны күрсәтү максаты белән чыгыш ясый.

**Әдәбият**

Birinci Türk tarih kongresi, Temmuz 1932. 2 bsk. Ankara: Türk Tarih Kurumu, 2010. 631 s.

*Ersanlı B.B.* İktidar ve Tarih. Türkiye’de «Resmi Tarih» Tezinin Oluşumu (1929–1937). İstanbul: AFA Yayınları, 1992. 230 s.

*Galip R.* İkinci oturuş // Birinci Türk tarih kongresi, Temmuz 1932. 2 bsk. Ankara: Türk Tarih Kurumu, 2010. 631 s.

*Galip R.* Türk Irkı ve Medeniyet Tarihine Umumi bir Bakış // Birinci Türk tarih kongresi, Temmuz 1932. 2 bsk. Ankara: Türk Tarih Kurumu, 2010. S. 99–161.

İkinci oturuş // Birinci Türk tarih kongresi, Temmuz 1932. 2 bsk. Ankara: Türk Tarih Kurumu, 2010. 631 s.

*İnalcık H.* Sadri Maksudi Arsal (1879–1957). Ölümünün beşinci yılı dolayısiyle // Türk Kültürü. 1963. Mart. S. 49–52.

*Koçak K.* «Talim ve Terbiye»nin Türk Eğitim ve Kültür Politikalarındaki Tarihi Yeri. Ankara, 2008.

[1] Мостафа Чокаев (Шокаев, Чокай-оглы; 1890–1941) – казакъ җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, юрист, журналист, әдәбиятчы, Бердәм Төркестанның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәш идеологы.

*Maksudi S.* Tarihin Amilleri // Birinci Türk tarih kongresi, Temmuz 1932. 2 bsk. Ankara: Türk Tarih Kurumu, 2010. S. 339-364.

*Maksudi S.* Türk dili için. Ankara, 1930. 517 s.

*Özbek N.* Zeki Velidi Togan ve Türk Tarih Tezi // Toplumsal Tarih. 1997. 8 (45).

Sadri Maksudi Bey Zeki Velidi Beyin Esassız Fikirlerine Cevap Veriyor // Hakimiyet Milliye. 1932. 29 Temmuz. S. 2.

Üçüncü oturuş // Birinci Türk tarih kongresi, Temmuz 1932. 2 bsk. Ankara: Türk Tarih Kurumu, 2010. S. 389–400.

*Velidi Z.* İkinci oturuş // Birinci Türk tarih kongresi, Temmuz 1932. 2 bsk. Ankara: Türk Tarih Kurumu, 2010. S. 375–376.

*Velidi Z.* Onyedi Kumaltı Şehri ve Sadri Maksudi Bey. İstanbul. 1934. 61 s.

*Velidi Z.* Ortaasiya'da Kuraklık Meselesi // Birinci Türk tarih kongresi, Temmuz 1932. 2 bsk. Ankara: Türk Tarih Kurumu, 2010. S. 167–176, 369–376.

*Валиди Тоган З.* Воспоминания: Книга 2. Уфа: Башкирское изд-во «Китап», 1998. 368 с.

Из истории российской эмиграции: письма А.-З. Валидова и М. Чокаева (1924–1932 гг.) / сост. С.М. Исхаков. М., 1999. 128 с.

*Исхакый Г.* Әсәрләр. Т. 14: хатлар һәм автобиографик язмалар [томны төз., текст. һәм аңлат. әзер., кереш сүз авт. Ф. Фәйзуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 479 б.

Муса Җаруллах Бигиев: фәнни-биографик җыентык / авт.-төз.: Хәйретдинов А.Г. Казан: Җыен, 2022. – 832 б.

*Тард Г.* Законы подражания. СПб., 1892. https:// viewer.rusneb.ru/ ru/000199_000009_003632067? page=1&rotate= 0&theme=white. (Мөрәҗәгать итү вакыты: 05.06.2023.)

***Гайнанова Миләүшә Рамил кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 94(470.41)

***Э.К. Сәлахова***

# ТӘТЕШ ӨЯЗЕ ТАТАР АВЫЛЛАРЫ МӘКТӘП-МӘДРӘСӘЛӘРЕ ТАРИХЫННАН (XIX гасыр уртасы – XX гасыр башы)

Статья посвящена анализу развития образовательной системы на территории Тетюшского уезда Казанской губернии в середине XIX – в начале XX в. Цель автора – показать достойное место региона в истории просвещения и образования народов Среднего Поволжья. Исследователь на архивных документах и на материалах татарской периодической печати начала XX века создаёт картину духовного развития и просвещения населения Тетюшского уезда, выявляет населённые пункты, где были расположены важные учебные заведения, имена авторитетных наставников.

**Ключевые слова:** история татарского народа, краеведение, образование, медресе, шакирды, история населённых пунктов, Тетюшский уезд.

The article is devoted to the analysis of the development of the educational system on the territory of the Tetyushsky district of the Kazan province in the XIX – early XX century. The author aims to show the worthy place of the region in the history of enlightenment and education of the peoples of the Middle Volga region. The researcher uses archival documents and materials of the Tatar periodical press of the beginning of the XX century to create a picture of the spiritual development and enlightenment of the population of the Tetyushsky district, identifies settlements where important educational institutions were located, the names of authoritative mentors.

**Keywords:** history of the tatar people, local history, education, madrassas, shakirds, history of settlements, tetyushsky district.

Мәгълүм булганча, Казан ханлыгы дәүләт буларак яшәүдән туктаганнан соң, татарның мәгариф үзәге шәһәр җиреннән авылларга күчә. XIX–XX гасырлар аралыгында татар авылларында эшләгән атаклы мәдрәсәләр шактый. Мәдрәсә буш җирдә ачыла алмый, аны оештыручы укымышлы зат, шәкертләрне җәлеп итәрлек хөрмәткә лаек остаз-мөгаллим һәм бу мәдрәсәләргә матди ярдәм күрсәтеп торырлык хәлле кешеләр булырга тиеш. Мисал өчен, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Казан губернасында 30 мәдрәсә, 680 мәктәп эшләгән. Алар арасында, Казан шәһәре мәдрәсәләреннән кала, Кышкар авылы мәдрәсәсе, Курса авылы, Чистай шәһәре мәдрәсәләре, Чистай өязенең Әлмәт, Кизләү авыллары, Чар өязе Ура авылы, Мамадыш өязенең Сатыш, Кече Сөн, Саба авыллары мәдрәсәләре билгеле уку йортлары рәтендә [ТР ДА. 92 ф. 2 тасв., 23954 эш. 106–107, 108–110 б. кгз.].

Татар мәгарифе тарихында халыкның төрле типтагы укыту системасын күрә алабыз. Шулардан иң борынгысы – мәктәп. Мәктәп – ул башлангыч белем бирә торган һәр мәчет каршында эшләгән уку йорты.

Шул ук вакытта, халыкның мәдрәсәләре дә булган. «Мәдрәсә» сүзенең килеп чыгышы гарәп телендәге «дәрес» сүзеннән, ягъни бу дәрес бирә торган, лекция укыла торган уку йорты, анда урта һәм югары белем бирелгән. Мәдрәсәләр аерым мәчет мәхәлләсенә карарга да мөмкин, яисә алар аерым автоном уку йорты статусында да була алалар. Һәрбер мәхәллә мәктәпле була алса да, һәр мәхәллә мәдрәсәле була алмаган. Мәдрәсә ачылсын өчен, аның материаль базасы, остазы, тиешле белемле мөгаллимнәре, кабул ителгән уку программасы, уку тәртибе булу да шарт [Медресе Казанской губернии..., с. 263–287]. Халык телендә дини уку йортларының барысын да мәдрәсә дип атау кабул ителгән. Шунлыктан, татар телле чыганакларда башлангыч уку йорты булган мәхәллә мәктәпләре дә мәдрәсә дип күрсәтелә, әмма аларны урта һәм югары белем бирә торган мәдрәсәләр белән бутарга ярамый.

Тәтеш өязе – Казан губернасының административ-территориаль берәмлеге, ул 1781 елда Казан наместниклыгы составында оеша, һәм кантон булып үзгәртелгәнче, 1920 елга кадәр, шушы исем белән йөри. Хәзерге вакытта Тәтеш өязе җирләре Татарстан республикасының Тәтеш, Апас, Кама Тамагы һәм Буа районының бер өлешенә карый. Тәтеш өязе – татар-мөселманнар күпләп гомер кичергән төбәк. 1897 елгы Бөтенроссия халык санын алу мәгълүматлары буенча, өяз халкының зур күпчелеген, ягъни 49,1% ын, татарлар тәшкил иткән, моннан кала руслар, чувашлар һәм мордвалар яшәгән [Первая всеобщая перепись, с. 3–8]. XX гасыр башында Казан губернасы авылларының К.П. Берстель төзегән исемлегенә караганда, Тәтеш өязе 247 авылны үз эченә алган. Шулардан 101 авылда бары татарлар гына яшәгән, 15 авылда татарлар руслар, чувашлар һәм мордвалар белән бергә гомер кичергәннәр [Список селений, с. 121–136]. Мөселман татарлар яшәгән авылларның һәр мәхәлләсендә диярлек дини белем бирә торган мәктәпләр эшләгән, алар мәчеттә, яисә мулла өендә урнашып, мәхәллә халкының матди хәле нык булганда гына мәктәп өчен аерым бина булдыру мөмкин саналган. Татар кешесе башлангыч белем алган, әмма халыкның рухи тормышы югарырак булсын өчен, югары белем бирә торган мәдрәсәләре, яисә башка төр уку йортлары эшләргә тиеш. Без хәзер Тәтеш өязендә эшләгән уку йортларының, мәдрәсәләрнең төгәл санын атый алмыйбыз, тулы картинаны күз алдына китерерлек чыганаклар да сакланмаган. Татарстан Республикасы архив идарәсе тарафыннан «Медресе Казанской губернии второй трети XIX – начала XX в.» дип аталган архив документлары җыентыгының әлеге бушлыкны тутыруда өлеше зур, әлбәттә. Рәсми документларда, мәгариф өлкәсен тикшергән түрәләрнең хисапларында сакланган мәгълүматлар буенча, беркадәр статистика да күзаллана. Мисал өчен, 1909 елга рәсми органнар тарафыннан Тәтеш өязендә 112 татар дини мәктәбе эшләгәнлеге теркәлгән [Медресе Казанской губернии, с. 139]. Аларның бары тик рәсми документлар гына булуын да истән чыгарырга ярамый, рәсми сан чынбарлыктагысыннан бермә-бер

азрак була, чөнки бөтен уку йортлары да рәсми рәвештә теркәлеп эшләмәгән, тикшерүләрдән азат булу өчен, кайберләрен махсус теркәмәгәннәр. Шуңа күрә, документларга таянып, төбәктә уку-укыту эше җәелү географиясенең реаль картинасын булдыру мөмкин түгел, мәкаләдә андый максат куелмый да. Безнең беренчел бурыч – киң чыганаклар базасында мөмкин кадәр тулы мәгълүмат туплау. Зур мәгариф учакларын өйрәнгән хезмәтләр дөнья күрсә дә, кызганычка каршы, төбәкләрдә халыкның рухи халәтен билгеләгән уку йортлары, мөгаллим-остазлар турында хезмәтләр юк дәрәҗәсендә, мондый мәгълүматларны төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең тырышлыгы белән генә таба алабыз. Мәкаләдә мәгариф эшләрен яктыртканда Тәтеш өязе чикләреннән чыгарга да туры килә, чөнки рухи тормыш билгеле бер административ-территориаль кысаларга гына сыймый, бу очракта территориаль чикләрне формаль кабул итү кирәк. Төбәк халкы бер-берсе белән аралашып яшәгән, билгеле уку йортына күрше өязгә барып та белем эстәгән. Халыкта данлыклы уку йортларының абруе бик зур булуын да онытмаска кирәк.

Тау ягында мәдрәсәләр күп булмаса да, булганнары шул төбәкнең мәгърифәт үзәге саналып, шул як авыллары өчен муллалар тәрбияләгән. Халыкка белем-тәрбия бирүдә аларның роле зур [Салахова, с. 65–70]. Кайбер очракта мәдрәсә дәрәҗәсендә булмаган уку йортлары – мәктәпләр дә укыту-тәрбия эшен мәдрәсәнеке күләмендә алып барганнар. Мисал өчен, Тәтеш өязенә кергән, хәзерге Апас районына караган Болын-Балыкчы авылы мәктәбе шул заманның атаклы уку йортларыннан саналган, анда гыйлем иясе Бикчәнтәй хәзрәт белем биргән. Бу мәктәпкә киләчәктә педагог, тарихчы булып танылган Гайнетдин Әхмәрев Татар Наратлысы авылыннан (Яшел Үзән районы) килеп укыган [Гайнетдин Әхмәрев, б. 14].

Тау ягындагы Сембер өязе Шәйморза авылында яшәүче кари, коръәнхафиз Әбүбәкер хәзрәткә, Коръән укырга өйрәнү өчен, җәй айларында Россиянең төрле төбәкләреннән шәкертләр килә торган булган. Җамал Вәлиди язуынча, әлеге төбәкнең рухи мәркәзе булган бу авылда ул зур мәдрәсә тоткан [Медресе Казанской губернии, с. 263–287].

XX гасыр башы Буа шәһәре мәдрәсәсенең ролен аерым билгеләп үтү зарур. Бу мәдрәсәнең тарихы бик борынгыдан килә, ул 1805 елда ук шәһәрнең мөселман мәхәлләсе акчасына ачыла. XIX гасыр ахыры–XX гасыр башында биредә имам-хатип, мөдәррис Нургали Хәсәнев дәресләр биргән. Бу мәдрәсә Буа сәүдәгәре Габдулла Шарин йортында урнашкан булган [ТР ДА. 92 ф. 1 тасв. 19936 эш. 5 б–6, 10 б–11, 11 б–17, 18 б–19 кгз.]. Моннан кала, Буа өязенең шушы як төбәк авылларының рухи тормышына хезмәт иткән, халыкка белем биргән уку йортлары Буа районы авыллары Янтуганда – 2, Вольнистанда 3 мәдрәсә, Ташкичү, Кырык Садак, Югары Лашчы, Норлатта, Чүпрәле районының Чепкас-Илмәт, Үби, Чувашстанның Сориле (Ишмурзино-Суринск) авылларында 50–80 шәкерте булган

мәдрәсәләр эшләп килгән [ТР ДА. 92 ф. 1 тасв. 19936 эш. 5 б–6, 10 б–6, 10 б–11, 11 б–17, 18 б–19 кгз]. Сакланып калган архив документлары буенча, бу мәдрәсәләрнең тарихы XIX гасырның беренче яртысыннан билгеле, әмма кайберләренең күпкә борынгырак тарихлы булуы да ихтимал.

Озак еллар бу төбәкнең кадими белем үзәге Буа шәһәрендә булса, XIX гасырның 70 нче елларыннан төбәкнең җәдиди үзәге Чуел өязе Акъегет авылы (Яшел Үзән районы) мәдрәсәсе тирәсендә туплана [Сәлахова, б. 127–133]. Территориаль яктан бу үзәкләрнең уртасында булган Тәтеш өязе халкы әлеге ике югарылыктагы рухи тормыш көчен тоеп яши. Бу мәдрәсә Себер ягында сату итеп мал туплаган бертуган Шәфигуллиннар һәм Архангельск шәһәрендә сәүдә иткән Акъегет авылы кешесе Закир Ишмәмәтев акчасына булдырыла һәм алар булышлыгы белән яши [ТР ДА. 1 ф. 4 тасв. 6183 эш. б. 6–8 кгз.]. 300 шәкерткә белем биргән бу уку йорты төбәкнең мәгариф һәм мәдәният үзәге булып кына калмыйча, XX гасыр башы инкыйлаблары заманында яңа фикер туу урыны да булган. Акъегет мәдрәсәсе, ул мәдрәсәне тоткан Заһидулла Шәфигуллинның тирә-як авыллары тормышына да йогынтысы зур булган. З. Шәфигуллин акчасына мәчетләр салынган, алар каршында мәктәпләр ачылган.

XX гасыр башында Тау ягының кайбер башка авылларында да атаклы мәктәп-мәдрәсәләр ачылган. Бу вакытта, 1913 елгы бер документта хәбәр ителгәнчә, Акъегет авылы мәдрәсәсендә шәкертләр санының кимүе бу төбәктә башка мәдрәсәләр ачылу белән аңлатыла. 1913 елның сентябрендә Чүти авылында мәдрәсә эшли башлый, бу авылда мәчет салганда да, мәдрәсә ачканда да З. Шәфигуллин зур ярдәм күрсәтә. Мәдрәсә ачылганчы ук мәчет каршында мәктәп эшләп торган. Тәтеш өязе Чирмешән авылы (Апас районы) мәктәбе XX гасыр башыннан ук эшләгән, ул Садыйк Сабитов акчасына төзелгән. 1908 елда хәзерге Буа районына караган Норлат авылы мәдрәсәсе ачылган һәм бөтен тирә-юньдә данлыклы уку йортына әйләнгән [ТР ДА. 160 ф. 1 тасв. 1576 эш. 270–272 кгз.], әмма кайбер чыганакларда бу уку йорты 1840 елда ачылган дип күрсәтелә [ТР ДА. 92 ф. 1 тасв. 19936 эш. 5 б–6, 10 б–6, 10 б–11, 11 б–17, 18 б–19 кгз.]. Безнең фикеребезчә, ул башта мәктәп булып, XX гасыр башында мәдрәсә югарылыгына күтәрелгән булырга тиеш. Тәтеш өязе Яңа Чәчкап авылы (Буа районы) мәдрәсәсе бик зур булмаса да, шәкертләр үз иткән атаклы уку йорты булган [Госманов, б. 463]. Кызганычка каршы, бу уку йортлары эшчәнлеге белән бәйле материаллар безнең көннәргә кадәр сакланмаган. Без алар хакында бары тик тикшерүче органнарның документлары, яисә халык хәтерендә калган истәлекләр аша гына белә алабыз.

Конкрет мәдрәсәләрнең тарихын кадими һәм җәдидигә аерып карау дөрес тә булмас, чөнки җәдитчелек хәрәкәте электән эшләп килгән кадими уку йортларына килеп керә, бу үзгәрешләр бер-ике көн эчендә генә бармый, мәдрәсәләрдәге хәл, укыту тәртибе акрынлап үзгәрә.

Җәдиди мәктәп фәлән елда ачылган дип, яңа оешкан мәдрәсәләргә карата гына әйтә алабыз, ә озын тарихка ия мәдрәсәләр турында сүз барганда, конкрет датаны атау дөрес булмый, чөнки үзгәрешләрнең дистә елларга сузылуы мөмкин. Аның кадими чоры да, җәдиди чоры да – бербөтен тарих, нинди типтагы уку йорты булуга карамастан, максаты – шул заман шартларыннан чыгып, халыкка белем, рухи тәрбия бирү, яшьләрне тормышка әзерләү. Татар җәмгыятендә башланган модернизация Казан шәһәрендә, яисә татарлар яшәгән башка рухи үзәкләрдә тизрәк барса, традицион тормыш рәвешен үзгәртергә бик ашкынып тормаган авыл җирендә бу процесс соңрак башланган һәм озаккарак сузылган. Җәдитчелек күренеше XIX гасырның 80 нче елларында гына киң үсеш-таралыш алган, үзәктән ерак урнашкан авылларга аның бәрәкәтле җимешләре XX гасыр башында гына килеп җиткән.

1910 елгы рәсми документта күрсәтелгәнчә, Тәтеш өязендәге бары бер генә уку йорты җәдит методы белән эшләгән [ТР ДА. 1 ф. 4 тасв. 5482 эш. 115 кгз.], әмма шул ук вакытта үзен кадими уку йортлары буларак танытканнары эчендә дә акрынлап булса да үзгәрешләр башланган. Тикшерүчеләрнең игътибарын артык җәлеп итмәс өчен, татарларга үз мәктәпләрен кадими дини уку йортлары дип күрсәтү уңайлырак тта булган. XX гасырда мәктәпләр санының артуы күзәтелә, алар – җәдит мәктәп булмасалар да, заман таләбе белән ачылган уку йортлары. Рәсми документлар буенча, 1909 елда – 112 [ТР ДА. 1 ф. 4 тасв. 3932 эш 106 кгз.], ә 1913 елда 132 кадими мәктәп булган. Тәтеш өязе уку йортлары саны буенча бары тик Казаннан (201) һәм Мамадыш (171) өязеннән генә калышкан. 132 мәктәптә 7827 ир бала, 5456 кыз бала белем алган. Аларда 132 мулла, 131 остазбикә хезмәт куйган [ТР ДА. 1 ф. 4 тасв. 5482 эш. 103–104 кгз.].

Авыл мәдрәсәләренең тормышы җиңел булмаган, аларның халык, мәхәллә акчасына көн күргәнлеген исәпкә алсак, тиңе юк уку йортлары булуларына тагын бер кат инанабыз. Мәктәп-мәдрәсәләрне яшәтүдә, тотуда аерым кешеләрнең ярдәме зур игътибарга лаек. Әмма бу уку йортлары арасында бөртекләп җыелган ярдәм хисабына көн күргәннәре дә җитәрлек. Тәтеш өязенә кергән Черкен авылыннан (Буа районы) моңа бер мисал китереп була. Имам Габделхәкимнең мәдрәсәсендә түзә алмаслык дәрәҗәдә салкын була, имам ягарга утын юклыгына зарланып, халыкка мөрәҗәгать иткәч, шушы авыл кешесе, Мариуполь заводында эшләгән Гайнетдин Таҗетдинев иптәшләре арасында 16 сум акча җыеп җибәрә. Бер эшченең тырышлыгы белән күпме балага белем алу мөмкинлеге тудырыла. Гайнетдингә газета аша рәхмәт тә белдерелә [Тәшәккер]. Бу мисал татар халкының мәгарифкә хөрмәтле мөнәсәбәтен күрсәтә.

Шулай ук, Тәтеш өязе Әлки авылы халкы мәдрәсә тота алмый башлагач, Кызыл Хаҗ җәмгыятеннән килгән бер рус хатыны, бу хәлне күреп, мәдрәсәне төзекләндерүгә ярдәм оештырып, балаларга яңадан белем эстәү мөмкинлеге тудырган [Бикмиев].

*Хәлфәләр, остазлар*

XX гасыр башында Тәтеш өязе мәктәпләрендә укыткан муллалар, хәлфәләр арасында үз заманы өчен яхшы гына белем алган, атаклы мәдрәсәләрне тәмамлаган кешеләр күп булган. Мисал өчен, Идрәс Тенки авылы (Апас районы) имамнары, укытучылары Әхмәтҗан Габделгаффаров, Олы Кариле авылыннан (Кама Тамагы районы) Шаһиәхмәд Нурмөхәммәтов, Атабай авылыннан (Кама Тамагы районы) Шаһимөхәммәд Госманов Казанда Әҗем мәдрәсәсен тәмамлаганнар. Келәнче авылыннан (Кама Тамагы районы) Шиһабетдин Мифтахетдинев Буа мәдрәсәсе шәкерте булган, Олы Тормы (Тәтеш районы) авылыннан Зыяэтдин Шәрәфетдинев Казан шәһәрендә атаклы Апанай мәдрәсәсендә укыган. Атабай авылы мулласы, хәлфәсе Шаһимөхәммәд Госманов ысулы җәдит дәреслекләре авторы буларак та билгеле. Ул – яңа система буенча укыту, яшьләрне тәрбия кылу буенча нәсыйхәтләр язган имам. Аның китаплары сәүдәгәр Әхмәт Хөсәенев акчасына басылган һәм яңа метод белән укырга теләүчеләргә бушлай таратылган [ТР ДА. 1 ф. 6 тасв. 99 эш. 29–34 б кгз.]. Шушы муллалар, мөгалимнәр Тәтеш өязендә ысулы саутия белән белем һәм тәрбия бирүче уку йортлары тотканнар. Аларның шәкертләре алга таба үзләре дә мөгаллимлек иткән. Мондый үзәкләр татарлар яшәгән бик күп төбәкләрдә булган [Модернизационные..., с. 394–395].

Дәреслекләргә килгәндә, татар теленнән шул заман мәктәпләрендә иң популярлары – Әхмәтһади Максудиның «Мөгаллиме әүвәл»е, «Әдәпле бала», «Нәсыйхәт»; язудан – «Хөснел хат»; шәригать белеменнән – Коръән, Һәфтияк һ.б. [ТР ДА, 97 ф., 1 тасв., 123 эш, 2, 15–16 кгз.].

*Рус-татар мәктәпләре*

Мәгълүм булганча, 1870 елның 26 мартында «О мерах к образованию населяющих Россию инородцев» дип исемләнгән Кагыйдә буенча рус булмаган халыкларның мәгарифенә дәүләт тарафыннан яңалык өстәлә. Шәһәрләрдә һәм татарлар күпләп яшәгән авылларда дәүләт хисабына башлангыч уку йортлары ачу күздә тотыла. Шул чор халык мәгарифе министры Д.А. Толстой сүзләренә караганда, «конечной целью образования всех инородцев, живущих в пределах отечества, бесспорно, должно быть обрусение их и смешение с русским народом» [Список.., с. 1555–1566], дигән максат куела. Кабул ителгән тәртипләр буенча, рус теле укытучысы хөкүмәттән хезмәт хакы алган, әмма татарларга бу уку йортында, теләгән очракта, дин дәресләре укытырга рөхсәт ителгән, әмма бусы инде мәхәллә халкы хисабыннан түләнергә тиеш булган. Ә мәхәллә мәктәпләренең эшләү шарты – аларда рус сыйныфы булу.

Мәхәллә мәктәпләренә әлеге чыгымнар да өстәлгән, моннан кала рус теле укытуны руслаштыруның бер алымы дип уйлаганнар. Шуңа күрә рус теле укытучыларына җиңел булмаган, мәхәллә халкы аларны

гел кимсетергә генә торган, дошман күргән. Хөкүмәт документларында рус теле укытылмаган мөселман дини уку йортлары «түбән» дәрәҗәле дип күрсәтелә. 1905 елда Тәтеш өязе уку йортларын тикшерү хисапларында «мөселман уку йортларында укыту-тәрбия эшенең куелышы, һәр яктан караганда да берьяклы итеп кенә оештырылган. Мөселманнар фикеренчә, аларда бары үз дини тәртипләрен һәм гадәтләрен өйрәнү генә максат итеп куела. Алар дин сабагын гына тырышып үзләштерәләр, ә башка предметларга тиешле игътибар бирелми. Максатны шулай тар аңлау сәбәпле, татарлар авылда рус теле дә укытыла торган уку йорты ачуга ризалык бирергә ашыкмыйлар» [ТР ДА. 97 ф. 1 тасв. 123 эш. 2, 15–16 кгз.], диелә. Булганнарында да рус сыйныфларында укыган шәкертләрнең русча белүләренең чамалы икәнлеге билгеләнә. Әмма бу очракта уку йортында белем бирү дәрәҗәсе гомумән түбән булган, дигән ялгыш караш туарга тиеш түгел.

1871 елда ук Казан губернасы халык мәктәпләре инспекторы В.В. Радлов Казан уку округы попечителе П.Д. Шестаковка мәктәпләр ачуның авырлыгыннан, укытырга кеше юклыктан зарлана [ТР ДА. 92 ф. 1 тасв. 10464 эш. 4–7 б кгз.]. Бу мәсьәлә татар җәмәгатьчелеге арасында да тикшерелә: «Йолдыз» газетасында «Авылларга школа кирәкме?» дигән мәсьәләдә фикерләшү бара. Андый мәктәпләр ачыла, әмма алар һәрвакыт халыкның каршылыгына, имамның нәфрәтенә очрый. Еш кына авыл имамы белән мәктәпнең рус теле укытучысы арасында зур конфликт туу, имам балаларының рус классларында укучыларны кагуы хакында хәбәрләр күп ишетелә. Заман таләпләре буенча, мондый уку йортлары да үз урынын табарга тиеш була, чөнки Россиядә көн күрү өчен рус теленә ихтыяҗ туа. Моның кирәклеген раслап, «Урысча белгән балаларның һәммәсе бер эшкә керә ... белмәгән балалар гади авыл кешесе булып кына калалар» [Авылларга школа кирәкме?], дип яза мәкалә авторы. Бары тик 8 яшьтән 12 яшькә кадәр генә русча уку булачак та, мөселман баласы белемсез кала, дигән ялгыш фикер дә таралып өлгерә. Автор, газета аша, моның алай түгеллеген, 1908 елгы программа буенча 2 сәгать рус теленә бирелсә, 3 сәгатьнең дин сабагына калдырылачагын, моннан кала татарча язу, сызу, хисап гыйлеме булачагын искәртә. Рус теле укытыла торган мәктәпләр ачу форсатын кулдан ычкындыру дөрес булмас иде, ди. Авторның бу сүзләре белән килешми мөмкин түгел, чөнки халык хисабына мәктәпләр тоту, бер яктан, бик күркәм күренеш булса да, икенче яктан, халык матди яктан авырлыклар кичергән, әлеге хөкүмәт мәктәпләрендә һәм дин сабагы өйрәнү, һәм дөньяви белем алу мөмкинлеге тудырылган. ХХ гасыр башында Казан өязендә 130 рус-татар мәктәбе (русско-татарская школа) эшләгән [Авылларга школа кирәкме?]. Мондый мәктәпләр Тәтеш өязе авылларында да булган. Мисал өчен, Тәтеш өязе Ындырчы авылында (Апас районы) рус-татар мәктәбе 1881 елда ук крестьян Фәтхуллин өендә ачылган. Йорты кечкенә булу сәбәпле, 12 генә бала сыйган. Шунлык-

тан укытучы балаларны өч сменада укытырга мәҗбүр булган. Аннан мәктәпкә Громыкин милкендә булган элеккеге почта станциясе бинасын сатып алганнар. 1884 елда Халык мәгарифе министрлыгы бина алу һәм аны ремонтлау өчен 500 сум акча биргән [РДТА. 733 ф. 171 тасв. 878 эш. 1–4 кгз.]. Болын-Балыкчы авылында (Апас районы) 1911 елны ачылган шундый мәктәп бер ел гына эшләгән дә, рус теле укытучысы юклыктан, эшен туктаткан, хәтта авыл мулласы Каюм Бикчәнтәев газета аша үз авылына рус теле укытучысы булырлык кеше эзләгән [Идарәдән мәктүпләр].

Югарыда әйтелгән Кагыйдә нигезендә тәүге мәктәп хәзерге Апас районының Чирмешән авылында эшли башлаган. Ул 1878 елның 16 февралендә үк Уфа татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган Мөхәммәдсафа Биккенин тырышлыгы белән ачылган, ул аның беренче укытучысы да булган. Шул елны ук мәктәпкә 35 бала кабул ителгән. Бу мәктәпкә 1894 елның 1 сентябрендә Зәңгәр мәчет, «Касыймия»[1] мәдрәсәләре, Казан татар укытучылар мәктәбендә (КТУШ)[2] белем алган Габдрахман Рәфыйков укытучы итеп билгеләнгән. Авыл халкы аны шикләнебрәк каршы алса да, мөгаллим үзенең белеме, тәрбиясе белән бик тиз абруй казанган [Муртазина, с. 4–5]. Ул эшләгән елларда уку йорты тирә-якка танылып өлгергән.

*Мәктәпләргә инкыйлаби карашларның керүе*

XX гасыр башында, бигрәк тә революция якынлашкан елларда, татар мәктәп-мәдрәсәләренә дә инкыйлаби фикерләр үтеп кергән, гадәти халәттән риза булмау көчәя барган. Казан шәһәрендә шәкертләр хәрәкәте башлангач, авыл мәктәп-мәдрәсәләре шәкертләре дә дөнья вакыйгаларыннан бихәбәр булып ята алмаганнар. Шәкертләр хәрәкәтенең кайтавазы Апас районы Чирмешән авылында да яңгыраган. Бу авылдагы хәлләр сәяси бунт дәрәҗәсенә күтәрелгән. 1903 елга кадәр Чирмешән авылында дәүләт карамагындагы бер мәктәп эшләп килгән, анда, әлбәттә, мәҗбүри рәвештә рус теле укытылган[3]. Шушы мәктәптә 130 шәкерт белем алган. 1912 елда Икенче Чирмешәндә Минһаҗетдин Хөснетдин улы үз акчасына татар мәктәбе төзеткән, мәктәп ачылуга, дәүләт карамагында булган мәктәптән барлык укучылар диярлек шунда күчеп беткән, бары 5 кенә укучы калган. Яңа ачылган мәктәпкә заманча фикерләүче, Казанда Галиев («Мөхәммәдия») мәдрәсәсен тәмамлаган, элекке укытучының адашы Габдрахман Шиһабетдинев мөгаллим итеп билгеләнгән. Ул авылның икенче мәхәлләсендә имам да булып торган. Мәктәптә дин гыйлемен

---

[1] Кайбер мәгълүматлар буенча, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте.

[2] Рус-татар мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү максаты белән 1876 елда ачылган уку йорты.

[3] Бу мәктәпнең элекке укытучысы Габдрахман Рәфыйков авыл халкының рус теленә булган каршылыгын җиңеп, үз шәхесе аша халыкта бу уку йортына уңай караш булдыруга ирешә. Г. Рәфыйков 1896 елның 21 ноябреннән үз эшчәнлеген Казан шәһәрендә дәвам иткән.

Фатыйх Шәмсетдинев укыткан. Әлбәттә, дәүләт карамагындагы мәктәп укытучылары Мөхәммәдсафа Биккенин һәм Мөхәммәдсабир Гаффаров аның мәктәбе популяр булуга, шәкертләрнең бөтенесе диярлек шунда күчүгә тыныч кына карый алмаганнар. Алар бу мәктәпне рөхсәтсез эшләүдә гаепләп, халык мәктәпләре инспекторын чакыртканнар, инспектор Алатырцев белән бергәләп килеп караганнар, аннан, инспектор киткәч, татар мәктәбенең өч шәкерте аларның уку йортына килеп, патша сурәтен алып ташлаганнар, дип гаеп тагканнар: 16 яшьлек яшүсмерләр – Шәһәретдин Минһаҗетдинев, Сабир Вәлиев, Салаватулла Гафуровлар гаепләнгән, ә егетләр исә бу нахак гаепне танымаганнар. Вакыйга мулла Габдрахман Шиһабетдиневне «сәяси ышанычсыз» дип тану һәм өч елга Тула губернасына сөргенгә сөрү белән тәмамланган. Авыл халкы, бу трагик хәлгә җавап итеп, Габдрахман муллага багышлап бәет чыгарган. Бу бәет «Татар халык авыз иҗаты. Бәетләр» томына да кертелгән [Милли-мәдәни мирасыбыз..., б. 22].

Тумышы белән хәзерге Буа районы Тәүгелде авылы (элекке исеме – Яңа Күлкәш) кешесе Габдрахман Шиһабетдинев заманча тәрбияләнгән, укымышлы, белемле кеше булган. Аның хатыны шул ук өязнең Әлки авылының (Буа районы) атаклы имамы Баһаветдинев кызы – Бибираимә. Мулланың анасы – Бибилатыйфа Сираҗетдинева бик көчле рухлы ханым, 60 яшьтә булуына карамастан, үз улыннан гаепне алдыртуга ирешкән. Мулла үзенең хокуклары чикләнмәгән статуста туган төбәгенә кайткан [ТР ДА, 1 ф. 4 тасв. 886 эш. 2–93 кгз.]. Бу вакыйгалар, бер яктан, мәгариф эшендәге каршылыклар – укыту системасына карата төрле караш һәм төрле ысул көрәше булып күренсә дә, чынлыкта исә, җәмгыятьнең үзгәрүен чагылдыра, килеп туган ситуацияне анализлап бәяләү күренә. Шул ук вакытта татар җәмгыятендәге каршылыкларда кешеләрнең бер-берсенә карата көнчелек һәм матди ихтыяҗлар ятуын да ачык күрергә мөмкин. Әмма, ничек кенә булмасын, татарлар арасында барган үзгәрешләр, аерым алганда, мәгариф өлкәсендәге алгарышларның үзәктән шактый ерак урнашкан гап-гади татар авылларына да килеп җитүе сиземләнә.

1917 елгы инкыйлаб чоры татар мәгарифенә дә үзгәрешләр алып килә. Өяз мөселманнары арасында заманча белем алуга омтылыш бермә-бер арта, чөнки халык җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне күрә, вакыйгалар агышында югалып калмас өчен, белем кирәклегенә төшенә. Тәтеш өязе мөселман мәктәпләре мөдире Исхак Казаков өяздәге хәлләрне, белем дәрәҗәсен ачыклау өчен, авылларга Шиһап Шәрәф, Җәләл Таһиров, Шаһит Гаделшин, Мозаффар Мөштәриев, Сабир Салихов һәм Абдуллиннарны җибәрә. Алар авыл мәктәпләре буйлап йөреп, мәгълүмат җыеп, «Мәктәпләр шурасы»на доклад бирергә тиеш булалар [Тәтеш өязе мөселман мәктәпләре]. Нәтиҗәдә авылларга 262 ләп мөгаллим җитмәгәнлеге ачыклана. «Тәтеш оешмасы» газетасында «Бәгъре Янган» дигән псевдоним астында бер автор «Бу нинди гаҗәп эш! Урыс кулына кергәннән бирле бер уянмый йоклаган бөтен

Тәтеш өязе мөселманнары бүген уянганнар. Бүген үзләренең дөньяда яшәргә омтылуларын күрсәтәләр, бүген үзләренең өстенә капланган кара пәрдәләрне ертып, ак, пакь дөньяга чыгарга ашкыналар. Өяздә укытырга теләп, Мәктәпләр шурасына 250 мөгаллим вә мөгаллимә укытырга урын сорыйлар!» [«Бәгъре Янган»] Хәтта Тәтеш төбәгеннән чит җирләрдә укытып йөргән мөгаллимнәр үз җирләренә кайтып эшлисеиләре килүен, кайберләре эш хакы күпме булуга да карамастан, бүгеннән күчеп кайтырга риза булуларын белдерәләр. «Мәктәпләр шурасына» бер остазбикә түбәндәге эчтәлекле хат юллый: «Сезне һәр җирдә мәктәп ачасыз, дип ишеттем. Безнең авылымызны кызлар мәктәбе ачудан мәхрүм итеп калдырмасаңызла. Мин үзем картайдым, укыта да алмыйм, күзем дә күрми. Безнең авылга кызлар мәктәбе ачсаңыз, Аллаһ ризалыгы өчен, мин дә картымнан калган йортымның яртысын кызлар мәктәбе өчен бушлай биреп торыр идем. Зинһар, кызларымызны укытудан мәхрүм итмәсеңезлә» [«Бәгъре Янган»], дип яза. Кызганыч, чыганактан кайсы авыл турында сүз баруы аңлашылмый, әмма бу мисал өяздәге кызларга белем бирү теләгенең нинди көчле булуын күрсәтә. «Бәгъре Янган» псевдонимы астындагы автор бу остазбикәне «Бу нинди изге карчык! Бу – Аллаһның җиргә төшкән бер фәрештәсе!» [«Бәгъре Янган»] дип зурлый. «Бу гаризаны укыгач, шатлыгымнан ике күземә мөлдерәп яшьләр килде. Бөтен вөҗүдем шатлык берлән, өяземезнең алга атлавына ышанган бер рәхәт берлә тулды. Шул кузгалган авылларны бер күз белән барысын күрәсем килә башлады. Күңелем аның каршысына барып кулларын үбеп рәхмәт укырга әзерләнә башлады» [«Бәгъре Янган»].

1917 елның 27 сентябрендә Тәтеш өязе мөселман укытучыларының өченче гомуми җыелышы була. Җыелыш Гариф Халиди рәислегендә эшли, Президиумга Исхак Казаков, Кариб Вәли, Шәһит Гаделшин, Кадыйр Халидовлар сайлана. Җыелышның көн тәртибенә мөһим сораулар чыгарыла: шуларның берсе – муллаларны рәсми мөгаллим итеп тану дөресме, юкмы? мәсьәләсе. Ул аерым секция утырышында каралып, 4 маддәле резолюция кабул ителә [Тәтештә укытучылар җыены].

1918 елның 25 июнендә Мозаффар Мөштәриев рәислегендә Тәтеш өязе укытучыларның съезды үтә. Рәис урынбасары итеп Кариб Вәли, сәркатиплеккә Фәйрүзә Маликова, аның урынбасары итеп Маһруй Мозаффария сайланалар [Солтан Гарифуллин].

Тәтештә дә татарлар яшәгән һәр төбәктәге кебек халык тарафыннан ачылган, мәхәллә хисабына тотылган уку йортлары – мәктәп-мәдрәсәләр һәр авылда диярлек булган. Мөгаллим-остазы булган авыллар тирә-як халкы өчен мәгариф үзәгенә әйләнгән. Бер регионда андый ике-өч мәдрәсә булу да шул төбәк халкының рухи тормышында зур роль уйнаган. Тәтеш төбәгендә Бикчәнтәй хәзрәт җитәкләгән Болын-Балыкчы мәдрәсәсе дә, Яңа Чәчкап авылы мәдрәсәсе дә һ.б. шулар исәбендә. Акъегет мәдрәсәсе һәм аны матди яктан тәэмин итеп торган З. Шәфигуллин Тәтеш өязе мәктәп-мәдрәсәләренә яңача –

җәдитчә уку-укыту алып килгән. Бу төбәк халкы бу яңалыкны тиз кабул итеп, алга таба заманча белем бирә торган уку-укыту системасын гамәлгә куйган. XX гасыр башына Тәтеш төбәге татар мәгарифенең мөһим бер үзәге булып җитешкән.

**Әдәбият**


Авылларга школа кирәкме? // Йолдыз. 1912. 15 гыйнвар.

«Бәгъре Янган». Өяздә укытуга сусау // Тәтеш оешмасы. 1917. 10 октябрь.

*Бикмиев Әхмәдҗан.* Авылда мәктәпләр // Казан мөхбире. 1906. 11 сентябрь.

Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык / төз.-авт. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. Казан: Җыен, 2011. 384 б.

*Госманов М.* Каурый каләм эзеннән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 463 б.

Идарәдән мәктүпләр // Йолдыз. 1912. 31 гыйнвар.

Медресе Казанской губернии второй четверти XIX – начала XX в.: сборник документов и материалов / отв. сост. Л.В. Горохова; сост.: Р.А. Гимазова, О.В. Федотова, Н.И. Шарангина; под общ. ред. Д.И. Ибрагимова. Казань: Главное архивное управление при Кабинете Министров Республики Татарстан, 2012. 287 с.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. Казан: Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, 2011. 287 б.

Модернизационные процессы в татарско-мусульманском сообществе в 1880–1905 гг.: документы и материалы. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан, 2014. 531 с.

*Муртазина Л.* Династия Рафиковых. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. 55 с.

Первая всеобщая перепись населения Российской империи 1897 г. / под ред. Н.А. Тройницкого. Казанская губерния. СПб.: Изд-е Центр. стат. комитета МВД, 1904. 284 с.

РДТА (Россия дәүләт тарих архивы). 733 ф. 171 тасв. 878 эш.

*Салахова Э.К.* Деятельность учебных заведений Горной стороны в дореволюционный период // Роль ислама в стабилизации социальных процессов. VI Международная научно-практическая конференция. Наб. Челны, 2021. С. 65–70.

*Сәлахова Э.К.* Бертуган Шәфигуллиннар һәм татар мәгарифе // Фәнни Татарстан. 2018. № 2. Б. 127–133.

*Солтан Гарифуллин.* Тәтеш өязе мөселман укытучыларының җыелышы // Тәтеш оешмасы. 1917. 7 июль.

Список селений Казанской губернии / сост. К.П. Берстель. Казань: Типолитография И.В. Ермолаевой, 1908. 263 с.

Список постановлений по Министерству народного просвещения. Т. 4. СПб: Типография Императорской академии наук, 1871. С. 1555–1566.

Тәтештә укытучылар җыены // Тәтеш оешмасы. 1917. 1 ноябрь.

Тәшәккер // Йолдыз. 1912. 17 гыйнвар.

[Тәтеш өязе мөселман мәктәпләре] // Тәтеш оешмасы. 1917. 26 сентябрь.

ТР ДА . 1 ф. 4 тасв. 886 эш.

ТР ДА. 1 ф. 4 тасв. 3932 эш.

ТР ДА. 1 ф. 4 тасв. 5482 эш.

ТР ДА. 1 ф. 4 тасв. 6183 эш.

ТР ДА. 1 ф. 6 тасв. 99 эш.
ТР ДА. 92 ф. 1 тасв. 10464 эш.
ТР ДА. 92 ф. 1 тасв. 19936 эш.
ТР ДА. 92 ф. 2 тасв. 23954 эш.
ТР ДА. 97 ф. 1 тасв. 123 эш.
ТР ДА. 160 ф. 1 тасв. 1576 эш.

***Сәлахова Эльмира Кадим кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының Яңа тарих бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 371.38

***Р.А. Гыйльмуллин,***
***Б.Э. Хәкимов,***
***М.Р. Шәехов***

# ГАМӘЛИ СЕМИОТИКА ИНСТИТУТЫНЫҢ ЗАМАНЧА ЛИНГВИСТИК РЕСУРСЛАРЫН УКЫТУДА КУЛЛАНУ

В статье описаны некоторые из готовых лингвистических ресурсов и IT-разработок Института прикладной семиотики Академии наук Республики Татарстан. Данные продукты успешно применяются в деятельности образовательных организаций среднего, профессионального и высшего уровня для повышения эффективности и вовлечения обучающихся в учебно-воспитательный процесс.

**Ключевые слова:** искусственный интеллект, IT-разработки, образовательные технологии, лингвистические ресурсы, обучение языкам, татарский язык.

The article describes some of the ready-made linguistic resources and IT developments of the Institute of Applied Semiotics of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. These products are successfully used in the educational process of educational organizations of secondary, professional and higher levels to increase efficiency and involve students in the educational process.

**Keywords:** artificial intelligence, IT developments, educational technologies, linguistic resources, language teaching, Tatar language.

Россия Федерациясендә белем бирү өлкәсендә предметларны укытуның эчтәлегендә генә түгел, ә мәгълүматны тапшыру формалары һәм укучылар белән эшләү методларында да зур үзгәрешләр күзәтелә. Хәзерге вакытта нәтиҗәле эшләүче укытучы үз эше буенча бурычларны хәл иткәндә һәм укытканда информацион-коммуникатив технологияләрне кулланмыйча булдыра алмый.

Бүгенге көндә ачык булган лингвистик ресурслар, аеруча ясалма интеллектка нигезләнгән цифрлы эшләнмәләр ярдәмендә уку-укыту процессын заманчалаштыру һәм тизәйтү, укытуга мотивацияне арттыру, аудитория белән үзара мөнәсәбәтне яхшырту, индивидуаль белем алу траекторияләрен төзү, контроль эшләр тикшерүне автоматлаштыру, уку барышын күзәтү, иң авыр үзләштерелгән темаларны билгеләү мөмкинлеге ачылды [Землякова, б. 127].

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Гамәли семиотика институты өч юнәлештә фәнни-гамәли тикшеренүләр алып бара һәм практикада кулланырлык продуктлар чыгара: 1) компьютер программаларын татар теленә локальләштерү; 2) табигый телне эшкәртү кораллары, гамәли программалар һәм лингвистик ресурслар төзү; 3) мәгълүмат эшкәртүнең интеллекту-

аль технологияләрен булдыру өчен татар теленең лексик-грамматик потенциалын когнитив яктан тикшерү [Сулейманов, с. 2]. Институт җитештергән продуктлар гомуми, урта һөнәри һәм югары белем бирү йортларында укыту процессында куллануга да юнәлтелгәннәр.

Аерым алганда, Гамәли семиотика институты хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән татар теленең лингвистик корпусын (https://tugantel.tatar) ике телле төркемнәрдә эшләүче укытучылар куллана. Корпус белән эшләү чараларын куллану телне өйрәнүнең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттырырга, укучыларның компетентлыгын, һәм телне гамәли белү дәрәҗәсен күтәрү өчен, текст белән эшләү методларын һәм алымнарын камилләштерергә мөмкинлек бирә [Мубаракшина, Хакимов, 2016; Мухамадьярова, Хакимов, 2016]. Лексик һәм грамматик параметрлар буенча күп функцияле эзләү ярдәмендә әдәби һәм иҗтимагый-сәяси текстлардан мисаллар табарга, аларны дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлек кысаларында алга таба анализлау һәм эшкәртү өчен материал буларак кулланырга мөмкин.

Аерым алганда, корпусны кулланучылар өчен Ә.М. Галиева төзегән инструкциядә (https://tugelant.tatar/help) түбәндәге уку биремнәре тәкъдим ителә: сүзнең (лемманың) һәм сүз формасының куллану ешлыгын билгеләү, сүзләрнең төп мәгънәләрен һәм типик контекстларын өйрәнү, идарә модельләрен һәм семантик рольләрне билгеләү, лексик берәмлекләрнең һәм грамматик конструкцияләрнең ешлыгын чагыштырып анализлау һ.б.

Мәсәлән, укучылар һәм студентлар белән шундый типтагы практик эш башкарырга мөмкин:

1. Татар теленең лингвистик корпусы ярдәмендә *яхшы* һәм *әйбәт* сүзләренең кулланылыш ешлыгын чагыштырыгыз (сүз формасы һәм лемма буенча).

2. Әлеге сыйфатлар белән кулланылган исемнәрне тикшерегез: «+» тамгасына басып, сүз өстәгез һәм «Билгеләр»дә исем сүз төркемен сайлагыз.

3. Мисалларны анализлап, һәрберсе өчен типик контекстларны билгеләп карагыз. Моның өчен морфологик үзлекләр буенча төркемләүдән файдаланыгыз.

Моннан тыш, корпус ярдәмендә фразеологизмнарның, тел-сурәтләү чараларының, синонимнарның төрле текстларда кулланылыш үзенчәлекләрен һәм мәгънә төсмерләрен тикшерергә мөмкин. Әлеге биремнәр укучыларның һәм татар телен өйрәнүчеләрнең тикшеренү күнекмәләрен үстерүгә юнәлдерелгән һәм тел материалын мөстәкыйль анализларга мөмкинлек бирә.

Татар теленең лингвистик корпусы укытучылар, методистлар һәм дәреслек авторлары өчен дә бай чыганак булып тора. Грамматик билгеләр буенча эзләп, практик биремнәр, дәрес эшкәртмәләре, дәреслекләр өчен төрле чорның төрле жанрдагы басма әдәбиятыннан һәм заманча яңалык текстларыннан бик күп тере мисаллар табарга мөмкин.

Шул ук вакытта заманча цифрлы инструментларның киң мөмкинлекләргә ия булуы тискәре нәтиҗәләргә дә китерә ала: укучылар белем алуда кызыксынуны югалтырга, нәтиҗә өчен җаваплылыкны башкасына күчерергә, өйрәнүдә мөстәкыйльлекне югалтырга мөмкин һ.б. Чыннан да, ясалма интеллект «арта торган потенциаль ресурсларга ия, ә аларны нәтиҗәле кулланмау куркынычы да арта бара» [Котельникова, б. 108]. Моны булдырмау өчен укытуда кулланыла торган чараларны даими анализлап торырга һәм куелган бурычларның үтәлешенә үз вакытында контрольлек итәргә кирәк.

Машина тәрҗемәчеләрен куллану да югарыда аталган куркынычларны тудырырга мөмкин. Гамәли семиотика институты җитәкчелегендә ясалма интеллект нигезендә ясалган русча-татарча һәм татарча-русча машина тәрҗемәчесе сыйфаты белән үзенең барлык аналогларыннан өстен тора [Хакимов, Шаехов, с. 214]. Шуңа күрә аңардан көндәлек ихтыяҗларда гади кулланучылар да, эш бурычларын чишүдә ярдәм итү өчен профессиональ тәрҗемәчеләр дә файдалана.

Моннан тыш, әлеге ресурс телчеләргә һәм тел укытучыларына машина тәрҗемәсенең уңышлы һәм уңышсыз очракларын табып, авыр очракларны анализлау һәм классификацияләү өчен файдалы [Шаехов, Хакимов, с. 216]. Моның өчен укучылар яки студентлар мөстәкыйль рәвештә түбәндәге практик эшне башкарырга мөмкин:

1. Татар телендә рус теле белән чагыштырганда кулланылышы белән аерылып торган берничә грамматик форманы яки конструкцияне сайлап алыгыз (мәсәлән, фигыльнең юклык яки төркемчә формасы, исемдә тартым яки килеш, сыйфат дәрәҗәләре һ.б.).

2. «Туган тел» корпусында (http://tugantel.tatar/) сайланган грамматик формага якынча 20–30 җөмлә туплагыз.

3. Барлык җөмләләрне берәм-берәм «Татсофт» тәрҗемәчесендә (http://translate.tatar/) тәрҗемә итеп чыгыгыз. Тикшерелә торган грамматик форманы тәрҗемә иткәндә килеп чыккан хаталы очракларны файлга туплагыз.

4. Тикшерелгән җөмләләр арасыннан ничәсе хаталы булуына карап, күзәтүләрне теркәп куегыз. Хаталар очрамаса, башка грамматик форманы алып карагыз.

5. Нәтиҗәләрне язып тапшырыгыз.

Кечкенәрәк сыйныф укучыларына әлеге тәрҗемәчедән дәрес вакытында яки дәрестән тыш чараларда төрле уеннар төзү өчен файдаланырга мөмкин. Мәсәлән, машина тәрҗемәсе ясаган фразеологизмнарның һәм мәкальләрнең оригинал телдәге татарча вариантларын табу һәм рус телендәге якын вариантны эзләү (*кәкре каенга терәтте – он прислонился к кривой березе*, *тетмәсен тетте – пусть не разрывает* һ.б.); классик татар шигырьләрен машина тәрҗемәсе ясаган өзек буенча тану (*«и родной язык, и красивый язык»* – «Туган тел»; *«Как двое детей в сказке. Берёзы взбирались на верши-*

*ны, Мальчик без двух штанов с миром Познакомились вместе...»* – «Мокамай» һ.б.)

Морфонология өкәсендәге тикшеренүчеләргә «Төрки морфема» (http://modmorph.turklang.net/tt) интернет-платформасы файдалы булачак. Әлеге продукт төрки телләрне чагыштырмача өйрәнү һәм тюрколог галимнәр катнашында уртак коллектив проектларны тормышка ашыру өчен лингвистик база булып тора. Портал төрки морфеманың структур-параметрик функциональ моделе нигезендә ясалган. Анда тел берәмлекләрен төрле лингвистик (морфологик, синтаксик, семантик) дәрәҗәләрдә тасвирлау мөмкинлекләрен бирүче мәгълүматлар базасы бар. Платформаның мәгълүматлар базасын шулай ук уку процессында төрки телләр буенча мәгълүмат-белешмә системасы буларак та файдаланырга мөмкин [Гатиатуллин, Кубединова, Прокопьев, Абдураманов, с. 222].

Бу порталда укучылар төрки морфемалар турында тулы мәгълүмат туплап, егермедән артык төрки телдә аларның кулланылышын чагыштыра алалар.

Аталган продуктлар һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Гамәли семиотика институтының телгә алынмаган башка заманча лингвистик ресурслары һәм ИТ-эшләнмәләре укыту процессын нәтиҗәлерәк итәргә, ә укучыларны материал белән кызыксындырырга мөмкинлек бирә. Әмма укытучылар әлеге чараларны куллану ешлыгын һәм урынын дәреснең максатларыннан чыгып билгеләргә тиеш.

### Әдәбият

*Гатиатуллин А.Р., Кубединова Л.Ш., Прокопьев Н.А., Абдураманов И.А.* Инструментарий портала «Тюркская морфема» для создания электронных корпусов тюркских языков в рамках единого концептуального пространства // Современная лингвистика: от теории к практике: III Казанский международный лингвистический саммит (Казань, 14–19 ноября 2022 г.): тр. и матер.: в 3 т. / под общ. ред. И.Э. Ярмакеева, Ф.Х. Тарасовой. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2023. Т. 1. С. 221–225.

*Землякова Т.А., Земляков В.Д.* Преимущества и недостатки использования искусственного интеллекта при изучении иностранного языка. // Психология и педагогика служебной деятельности. 2021. 2. С. 122–130.

*Котельникова Е.В.* Когнитивные аспекты осмысления смешанной речемыслительной деятельности межкультурной коммуникации // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2012. № 7 (18). С. 106–115.

*Мубаракшина А.А., Хакимов Б.Э.* К вопросу об использовании корпусно-ориентированного подхода в преподавании татарского языка // Труды Международной конференции по компьютерной и когнитивной лингвистике TEL-2016. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2016. С. 322–326.

*Мухамадьярова А.Ф., Хакимов Б.Э.* Использование корпуса текстов при обучении иностранному языку / // Труды XIV международной конференции по компьютерной и когнитивной лингвистике TEL-2016. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2016. С. 105–111.

*Сулейманов Д.Ш.* Инфокоммуникационные технологии и татарский язык // Труды X Международной конференции «Компьютерная обработка тюркских языков» «TURKLANG 2022» 16–18 июня 2022 г. Евразийский национальный университет им. Л.Н. Гумилева. Нур-Султан, 2022. С. 41–57.

*Хакимов Б.Э., Шаехов М.Р.* Сравнение качества машинных переводчиков в русско-татарской паре с помощью тестового параллельного корпуса // Түркі тілдерін компьютерлік өңдеу. X халықаралық конференция: Еңбектері = Компьютерная обработка тюркских языков. X международная конференция: Труды. Нұр-Сұлтан: «Булатов А.Ж.» ЖК, 2022. С. 212–222.

*Шаехов М., Хакимов Б.* Лингвистический анализ ошибок системы русско-татарского машинного перевода «Татсофт» // Материалы XVI международной конференции по компьютерной и когнитивной лингвистике TEL-2020 «Семантические модели и технологии» (Казань, 12–13 ноября, 2020). С. 215–219.

***Гыйльмуллин Ринат Абрек улы,***
*физика-математика фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Гамәли семиотика институты директоры*

***Хәкимов Булат Эрнст улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының*
*билингваль һәм цифрлы белем бирү кафедрасы доценты,*
*ТР ФА Гамәли семиотика институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Шәехов Марат Рәшит улы,***
*ТР ФА Гамәли семиотика институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 76.03/09

***О.Л. Улемнова***

## АЛАБУГАДА III БИЕННАЛЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Статья посвящена такому важному фактору развития современного изобразительного искусства как проведение международных графических биеннале и триеннале, которые стали характерной чертой художественного процесса в Республике Татарстан. Автор даёт краткий обзор форумов, проводимых в Казани и Елабуге, и подробно анализирует произведения, представленные на итоговой выставке III Елабужской биеннале уникального рисунка (2021). Автор подчеркивает, что такие регулярные выставки-конкурсы через обмен творческим опытом, внутрироссийские и международные художественные контакты стимулируют профессиональный рост художников и являются новым инструментом пополнения музейных собраний.

**Ключевые слова:** выставка графики, академический рисунок, художественные эксперименты, рисовальные техники, жанры.

The article is devoted to such an important factor in the development of modern fine art as the holding of international graphic biennales and triennials which have become a characteristic feature of the artistic process in the Republic of Tatarstan. The author gives a brief overview of the forums held in Kazan and Elabug, and analyzes in detail the works presented at the final exhibition of the III Elabuga Biennale of Unique Drawings (2021). The author emphasizes that such regular exhibitions and competitions through the exchange of creative experience, domestic and international artistic contacts stimulate the professional growth of artists and are a new tool for replenishing museum collections.

**Keywords:** exhibition of graphics, academic drawing, artistic experiments, drawing techniques, genres.

Татарстанда даими рәвештә халыкара һәм бөтенроссия графика күргәзмәләре – биеннале (2 елга бер тапкыр уздырыла), триеннале (3 елга бер) оештыру хәзерге заман сәнгать процессының төп үзенчәлеген тәшкил итә. Алар континентларны һәм халыкларны берләштереп, мәдәни диалогка һәм үзара аңлашуга булыша, халыкара коммуникациянең мобиль чарасы, төрле төбәк һәм илләр рәссамнары өчен иҗади тәҗрибә һәм сәнгати идеяләр белән уртаклашу урыны булып тора. Басма графика форумнары үткәрү аеруча киң таралган, бу күп очракта әлеге сәнгать төренең тиражлап басылу кебек үзенчәлегенә бәйле, чөнки авторлар үз әсәрләрен һич икеләнмичә оештыручылар карамагына тапшыралар. Мәсәлән, 2011 елдан Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее Казан рәссамнарының рәсми булмаган иҗат берләшмәсе «Графком» белән берлектә «Җайдак» Казан халыкара басма графика биенналесын үткәрә. Анда Россиядә һәм чит илләрдә басма графиканың хәзерге торышы, үсешенең яңа тенденцияләре чагылыш таба. Хәзер ул Татарстанда графика үсешен

билгеләүче мөһим факторга әверелде [Улемнова, с. 155]. 2012 елдан Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы Экслибрис триенналесын башта – бөтенроссия, ә 2015 елдан халыкара күләмдә уздыра [Паршикова, с. 162].

Мондый биеннале һәм триенналелар рәссамнарның һөнәри үсешенә көчле импульс бирә һәм Россия музейлары өчен музей тупланмаларын тулыландыруда яңа алым хезмәтен үти, чөнки күпчелек әсәрләр, сайлап алу конкурсы һәм йомгаклау күргәзмәсе узганнан соң, чараны оештырган музейлар фондында кала. Бу турыда ТР дәүләт сынлы сәнгать музее директоры Р.М. Нургалиева болай ди: «Казанская биеннале печатной графики стала важным фактором музейного развития, предоставив возможность начать формирование коллекций современной зарубежной и российской печатной графики» [2-я Казанская..., с. 4].

Оригиналь рәсем конкурслары аз үткәрелә, чөнки эксклюзив булулары белән алар авторларга бик кадерле. Россиядә: Строганов университеты (С.Г. Строганов исемендәге Мәскәү дәүләт сәнгать-сәнәгать университеты) оештырган Академик рәсем биенналесы, Архитектур рәсем халыкара биенналесы, «УРАЛ-ГРАФО» биеннале-фестивале, чит илләрнеке: Скопьеда (Төньяк Македония) Шәрык рәсем биенналесы (Osten Biennial of Drawing Skopje), Лондонда рәсем биенналесы (Drawing Biennial, Drawing Room, London), Риминидә рәсем биенналесы (Италия) (Biennale Disegno Rimini) һ.б.

2017 елдан Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы да әлеге мәртәбәле институцияләргә кушылды һәм уникаль рәсем биенналесын үткәрә башлады. Ул рус реалистик рәсем мәктәбе традицияләрен һәм оригиналь графиканы үстерүдә заманча тенденцияләрне популярлаштыруга юнәлдерелгән [Положение III Елабужской...]. Биеннале түбәндәге тәртиптә үткәрелә: музей-тыюлык адресына җибәрелгән эшләр читтән торып конкурс уздыру юлы белән сайлап алына һәм катнашучыларның йомгаклау күргәзмәсе оештырыла. Шуннан соң һәр рәссам үзенең бер эшен Алабуга музей-тыюлыгы фондына тапшыра [шунда ук].

III Алабуга уникаль рәсем биенналесы конкурсы – 2021 елның 1 февраленнән 31 августына кадәр, ә йомгаклау күргәзмәсе – 2021 елның 15 октябреннән 2 декабренә кадәр Хәзерге заман этник сәнгать музеенда узды [III Елабужская...]. Биеннале идеясенең авторы, Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы генераль директоры Г.Р. Руденко биенналенең төп бурычын ирекле темага классик рәсемне хуплау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү дип билгеләде. Аның сүзләренә караганда, «конкурс позволяет участникам в полной мере раскрыть свои возможности, показать все многообразие форм, техник, методов, школ и направлений, в которых проявляет себя современное графическое искусство» [III Елабужская..., с. 3].

Чыннан да, III Алабуга биенналесының конкурс комиссиясе тарафыннан сайлап алынган әсәрләргә (30 рәссамның 31 рәсеме) анализ

хәзерге заман оригиналь графикасын үстерүнең кайбер тенденцияләре белән танышырга мөмкинлек бирә. Аларда хәзерге чор өчен хас булган төрле төр һәм жанрлар, эш методлары һәм алымнары, стиль һәм юнәлешләр ачыла.

Рәссамнар натура буенча ясалган, фантазиягә нигезләнгән, этюд тибындагы, станоклы рәсемнәр тәкъдим иттеләр. Натурадан ясалган рәсемнәр рәссамның әйләнә-тирә чынбарлык белән турыдан-туры аралашуын, дөньяны танып белү, сәнгати төшенү процессын чагылдыра. Беренче турыдан-туры тәэсирләрне, тойгы һәм хисләрне теркәгән мондый рәсемнәр күбрәк яшь авторларныкы (35 яшькә кадәр), еш кына өстән-өстән генә ясалган булалар һәм башлыча пейзаж жанрына карыйлар. Аклы-каралы графикага якын кышкы мотивлар яшь рәссамнар арасында аеруча популяр булып чыкты. Екатерина Чикирева (Россия, Төмән шәһәре) «Буранлы кырлар» рәсемендә ритмнарга басым ясый. Ул аларны шәһәр читенең гадәти булмаган пейзажында тотып ала: анда хуҗалык корылмалары рәтләре артында кар каплаган басулар җәйрәп ята һәм офыкта караңгы урман күренә. Параллель штриховка ритмлылыкны ассызыклый, ә ак кәгазьгә капма-каршы куелган кап-кара төстәге күмер кышкы пейзажның контрастлыгын күрсәтә. Елизавета Нетреба (Россия, Екатеринбург шәһәре) Екатеринбургның киң билгеле күренешләреннән берсен – шәһәр яр буен сурәтләгән. Ул композицияне төрле күләм һәм фактураларны чагыштырып карауга нигезләнеп төзи – беренче пландагы рәшәткәләр агачларның, ап-ак боз каплаган елга тирәсендә урнашкан шәһәр биналары силуэтларының бердәм караңгы массасына кушылып китә. Константин Малеев (Россия, Юрьев-Польский шәһәре) Владимир шәһәрендәге түбәләрнең геометриясенә соклана, алар яңа яуган ак кар белән ассызыклана: түбә кыеклары зур булмаган чиркәү гөмбәзләре, ялангач агачларның үтә күренмәле ябалдашлары белән аралаша, офыкта яңа төзелеш силуэтлары белән тәмамлана. К. Малеев, аслык сыйфатында сары картоннан файдаланып, соус һәм акбур сылап ясалган тап һәм яссылык файдасына туры сызыктан баш тартып, матур эффектларга ирешә. Дарья Серова (Россия, Красноярск шәһәре) агач корылмаларның структурасы белән мавыга: ул аларны графит карандашның төрле – нечкә, юан, киң ягы белән ясалган сызыклары белән яза. Марина Демидованың да (Россия, Барнаул шәһәре) шундый ук мотивында җимерелү эстетикасы хөкем сөрә: ул йортларның һәм коймаларның реальлеген актив штрихлап аңлата, ә җимерелеп барган түбәләрнең һәм кыйшайган коймаларның диагональләре белән авыл йортларының тузуын ассызыклый.

Шунысы кызыклы, боларга охшаш сюжетларны өлкәнрәк буын рәссамнар ничек аңлата соң? Любовь Серованың (Россия, Чиләбе шәһәре) гап-гади мотивы – капка һәм шифер түбәле агач дивары галәмнең тирән эчтәлеккә ия символына әверелә. Предметлар дөньясын ул куе графит карандаш штрихлары аша, ә күкнең тирәнлеген һәм озынлыгын җиңел горизонталь сызыклар белән бирә. Дулкын сыман түбәдә яткан карның гаҗәеп аклыгы ап-ак кәгазь аша бирелгән. Ул күк

белән җирнең чиге буларак кабул ителә. Карның тиз эреп бетүчәнлеге, озакка бармавы бөтен реаль дөньяның вакытлы булуын гәүдәләндерә, ә дулкынлы чите тормыш процессларының цикллылыгы символы буларак кабул ителә. Кечкенә генә уем аша авыл йорты күренә. Бу – өстәмә мәгънәләр тудыра: киртә артында яшеренгән сер, аны ачу, шул чиксез киңлеккә үтеп керү, яңа дөньялар һәм аларның серләрен ачу теләге уяна. Елена Литвиненко (Россия, Стәрлетамак шәһәре) «Башкортстан киңлекләре» диптихында туган ягы ландшафтының ниндидер формуласын чыгара, урман массивлары һәм шәһәр кварталларының гармонияле аккордларын тудыра, табигый формаларны соң дәрәҗәдә турайта, түгәрәкләндерә, гомумиләштерә, аларны халык орнаменты белән ассоциацияләр тудырган декоратив композицияләргә әвереелдерә.

Владимир Гончаровның (Россия, Воронеж шәһәре) карандаш белән ясалган «Туган йорт» рәсеме аеруча эмоциональлек белән сугарылган (3 нче премия). Анда сурәтнең материальлеге бакчаның һәм йортның үз структурасын ачыклаган һәм ассызыклаган формаларны билгеле бер дәрәҗәдә гомумиләштерү һәм геометрияләштерү белән үрелә. Рәссам әйтерсең лә балачак хатирәләрен тотрыклы һәм үзгәрешсез мемориялләргә әйләндерә. Кәгазьнең рельефлы булуы хисабына өслекнең куе итеп штрихланган өлешләренә фактуралылык, ә кәгазьгә декоративлык өстәлә.

Биенналеда станоклы рәсемнәр өстенлек итә. Алар төп фикернең тирәнлеге, сәнгати форманың төгәлләнгән булуы, автор манерасының индивидуальлеге белән аерылып тора. Рәсем сәнгатен өйрәнүче Б.А. Соловьева аларның нәрсә белдерүе турында болай ди: «определенное суждение о жизни, понимаемое как слитность переживания, осмысления и оценки, – точнее, как некая идея, рождаемая этой слитностью» [Соловьева, с. 33]. Рәссамнарның аеруча пейзаж белән мавыгулары очраклы түгел. Алар интерпретациясендә пейзажның төрле вариантлары барлыкка килә. Табигатьне кабул итү аша, алар күбесенчә туган як табигате тәэсирендә формалашкан үз шәхесләрен ачалар, дөньяга мөнәсәбәтләрен белдерәләр.

Күп кенә рәссамнар төсле графикага, төрле эффектларга тартылалар, ә аларны бай график инструментлар һәм материаллар ярдәмендә булдырырга мөмкин. Елена Йованчованың (Черногория Республикасы, Челуга шәһәре) кара кәгазьдә пастель белән эшләнгән «Зәйтүн агачы» көчле һәм шомлы образ тудыра: куәтле кәүсәле һәм күперенке яшел ябалдашлы зәйтүн агачы җирдә көч-хәл белән генә басып тора – аның карт тамырлары җир өстенә чыккан, сары туфрак һәм кан кебек кызыл күк борынгы Урта диңгез өстендә туган куркыныч тойгысын тагын да көчәйтә. Игорь Репников (Россия, Томск өлкәсе) «Перекат» (биеннале дипломы) композициясендә төсле карандаш сызыкларын бөтерү юлы белән тау токымнарының катлаулы геометриясен һәм геологиясен, елганың көчле агымын һәм шарлавыкларны тасвирлый, шул рәвешле Себер табигатенең чиксез матурлыгын һәм көчен гәүдәләндерә.

Натюрморт – биеннале рәссамнарының дөньяны өйрәнү һәм танып белү ысулларының тагын берсе. Алар бу очракта да төрле алымнарга мөрәҗәгать итәләр. Ирина Киришина (Россия, Сухой Лог шәһәре) сарымсак бәйләмнәрен карандаш белән классик манерада штрихлап ясаган. Рәсем соң дәрәҗәдә реалистик булуы белән аерылып тора. Рәссам гади әйберләрнең, крестьян хезмәтенең, гадәти кеше тормышының кыйммәтен раслый. Светлана Рябова (Россия, Свердловск өлкәсе) остаханәдәге иҗади атмосфераны бирүгә ирешә. Моның өчен ул рәссам-графикның эш коралларыннан һәм материалларыннан ясалган натюрмортны автопортрет (стенага эленгән көзгедә авторның йөзен күрәбез) белән тоташтыра. Рябовада ышанычлылык декоративлык белән яраша. Ә соңгысына ул квадрат эченә сыйган үзәктәш композиция һәм төрле штриховкаларга нигезләнгән график фактура ярдәмендә ирешә. Виктор Рассадкин (Россия, Владимир өлкәсе) безнең тарихи хәтеребезгә, гади генә предметлар җыелмасы – сөт чүлмәге, ипи катысы, бабаларыбызның дивардагы фотосурәтләре аша мөрәҗәгать итә. Ул шул рәвешле теләсә кайсы крестьян гаиләсенә хас булган яшәү рәвешен күрсәтә.

Натюрморт жанры рәссамнарны сәнгати формалар белән эксперимент ясау өчен уңайлы кыр буларак та җәлеп итә. Ольга Предеина (Россия, Свердловск өлкәсе) миңлегөлнең (бегония) нәфис чәчәкләр белән бизәлгән купшы яшел массасында күләм һәм фактуралар белән уйнау мөмкинлеге эзли, ә Екатерина Савочкина (Россия, Чиләбе) кыр чәчәкләре киңлегендә орнамент тууны күрә һәм үзенең рәсемен яссы декоратив композициягә әйләндерә. Юрий Бычков (Россия, Төмән шәһәре) «Ишек күгәне» әсәрендә (1 нче премия) үзенең чын мәгънәдә рәсем ясау остасы булуын күрсәтә, ул гади техник предметны виртуоз рәвештә яңартып кына калмый, ә янәшәдәге предметлар белән үзара тәэсир итешкән, үз эстетикасы булган, нәзакәтле график фактура белән тудырылган җан иясе итеп сурәтли.

Россия халыклары мәдәниятенең күптөрлелеген чагылдырган этник тема рәссамнарда шулай ук зур кызыксыну уята. Чулпан Билалова (Россия, Мәскәү шәһәре) «Илдар бабай» рәсемендә (биеннале дипломы) туган җирне бергәләп эшкәртүче төрле буын вәкилләре арасында тыгыз рухи бәйләнеш атмосферасы тудыра. Геннадий Петухов (Россия, Йошкар-Ола шәһәре) үзенең «Сакраль мелодия»сендә урманлы якта дулкын-дулкын булып таралган һәм бөтен тирә-юньне үзенең күптавышлы җырына кушылырга мәҗбүр иткән милли музыка рухын бирүгә ирешә. Музыкантларның чиктән тыш реалистик сурәте белән фон һәм агачларның (кайрылары мари костюмы чигешен дәвам иткән бизәккә әйләнгән) шартлы декоративлыгы синтезы әкияти халык бәйрәме атмосферасы тудыра.

Амыр Укачин (Россия, Горно-Алтайск) төрки мифологиядәге алиһә образын гәүдәләндерә. Ул моны милли сәнгать орнаментларына һәм православие иконасының композицион системасына таянып, хатын-кыз, кош образларын һәм борынгы пиктограммаларны бердәм

композициягә туплап гамәлгә ашыра («Курагай-Кан – кошлар патшасы»). Салават Гыйләҗетдинов (Россия, Уфа шәһәре) рәссам ихтыяры белән кәгазь буенча җиңел шуып йөргән графит карандашның үзлекләрен һәм мөмкинлекләрен күреп ләззәтләнә. Ул нинди генә эзләр калдырмый: кадерле образларны һәм хәтта башкорт даласында узган балачагы исләрен дә гәүдәләндергәндә, нечкә сызыклар, штрих һәм нокталар әле таралып китә, әле куерып җыела («Озын-озак балачак» сериясеннән – «Җәй исе», 2 нче премия). Ирина Кочурова-Жумабекова (Россия, Серов шәһәре) «Купальщицы» классик сюжетының Көнчыгыш вариантын тәкъдим итә: рәссам үзенең оялчан ай йөзле кызларын суга шундый итеп чумдырган ки, аларның башлары һәм кул чуклары гына күренеп тора, стильләштерелгән чәчәкләр һәм су өслеге буйлап таралучы боҗралар белән бизәлгән сулык матур келәмгә әйләнгән. Валерий Воробьев (Россия, Сергиев Посад шәһәре) рус темасын ачу өчен көтелмәгән чишелеш тапкан, аны техник алгарыш яссылыгына күчереп, рус космонавтикасының крестьян тамырларын, рус халкының беркатлылыгын юмор белән күрсәткән, әмма бу рус халкына космосны беренче булып үзләштерергә комачауламаган («Рус космосы», биеннале дипломы).

Биенналеда катнашкан рәссамнар арасында тарихи жанрга мөрәҗәгать итүчеләр күп түгел. Алар, дөньядагы катлаулы сәяси вазгыятьне истә тотып, илебез тарихындагы кискен борылыш моментларын сюжет итеп сайлаганнар. Тамара Романова (Россия, Санкт-Петербург шәһәре) «болгавыр заман» вакыйгаларына мөрәҗәгать итеп, А.С. Пушкинның «Борис Годунов» трагедиясеннән кенәзләр Шуйский һәм Воротынский диалогын күрсәтә һәм киләчәктә коточкыч вакыйгаларга китерәчәк үзгәрешләрнең шомлы атмосферасын җиткерергә омтыла. Глеб Соловьев (Россия, Уфа шәһәре) «Дошманнар якын» рәсемендә Урта гасырлардагы үзара ызгышып-талашып яшәгән һәм тышкы дошманнар белән каршылыкта булган Русь тарихыннан алынган типик күренешне сурәтли.

Биенналеда портрет жанры бик аз тәкъдим ителгән (бер рәсем белән – Сергей Мельник (Россия, Уфа шәһәре), «Мария портреты»), бу җәмгыятьтә аерым шәхес һәм аның уйлары, өметләре белән кызыксынуның кимүе турында уйлануларга этәрә. Бу аспектлар Рафаэль Сәйфуллинның (Финляндия, Киско шәһәре) «Сентябрь» рәсемендә (биеннале Гран-прие) үтә үзенчәлекле һәм кызыклы итеп ачыла. Ул рәссамның эчке дөньясын бирә алган гадәти булмаган композиция төзеп, төрле жанрларны – портрет, пейзаж һәм натюрмортны берләштергән. Рәсемдә кеше йөзе (анда авторның үз образын күрәбез) зур план белән бирелгән, аның чикләре чиста кәгазь бите өслегендә эреп юкка чыга, һәм үзенең формасы белән образ, фикер һәм хисләр бәйләме куелган ваза белән ассоциацияләнә: рәссамның яшәү тирәлеге – чыршылар һәм яфракларын коючы агачлар белән әйләндереп алынган агач йортлар сурәтләнгән гади фин пейзажы; эш кораллары – карандаш, пумала, останың тормышын алардан башка күз алдына да

китереп булмый; йөзе рамка белән капланган хатын-кыз портреты, ул – авторның тормыш юлында очраган барлык хатын-кызларның җыелма образы. Сәйфуллин тирән фәлсәфи эчтәлекле әсәр иҗат иткән, анда аның рәссамның язмышы, иҗатка илһамландыручы музалар, гомернең бик тиз узуы турындагы уйланулары чагылган. Композициянең барлык элементлары, үзара фантастик планда ярашсалар да, чынбарлыкка туры килә һәм гадәтилек кысаларыннан читкә чыккан аерым атмосфера тудыра. Тушь белән рәсем ясау техникасы рәссамга нәзакәтле график фактура тудырырга ярдәм иткән: бормалы-сырмалы җиңел каллиграфик сызыклар пумаланы җиңелчә генә тидереп ясалган үтә күренмәле гризайль формалар белән бергә объектив чынбарлык метафизикасына төшенергә булыша.

Алабуга биенналесына нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: хәзерге заман сәнгатендә рәсем белән кызыксыну яңадан күтәрелеш кичерә, рәссамнар аның мөстәкыйльлеген һәм үзкыйммәтен тирәнтен аңлыйлар, төрле идеяләрне, фикерләрне һәм хис-кичерешләрне, күңелнең иң нечкә тирбәлешләрен гәүдәләндерергә мөмкинлек бирә торган тәэсир итү чараларына бай булуын искәртәләр. Реалистик академик рәсемгә зур игътибар бирү – сынлы сәнгатьнең башка төрләре өчен дә уңышлы үсеш нигезе ул. Ә авангардчыл экспериментлар тәҗрибәсе «коры» мәктәп академизмын баета һәм акрынлап үзгәрергә мәҗбүр итә, классик алымнарның кыйммәтен һәм аларның хәзерге заман таләпләренә җавап бирә алырга сәләтле булуын күрсәтә.

**Әдәбият**

2-я Казанская международная биеннале печатной графики. Посвящается графическому коллективу «Всадник» / авт.-сост. кат. и авт. вст. ст.: О.Л. Улемнова и др. Казань: Заман, 2015. 152 с.: ил.

III Елабужская биеннале уникального рисунка: Каталог / сост. кат. Г.А. Подноскова, Р.Р. Идаева; авт. вст. ст. О.Л. Улемнова. Елабуга, 2022. 52 с.: ил.

*Паршикова Е.А.* Региональные особенности развития печатной графики Татарстана на современном этапе // Четвёртые Казанские искусствоведческие чтения. Искусство печатной графики: история и современность. Материалы Всерос. науч.-практ. конф. с междунар. участием. 19–20 ноября 2015 г. Казань: Заман, 2015. С. 162–164.

Положение III Елабужской биеннале уникального рисунка. Елабуга, 2021.

*Соловьёва Б.А.* Искусство рисунка. М.: Искусство, 1989. 255 с.: ил.

*Улемнова О.Л.* Казанская международная биеннале печатной графики: опыт организации, проблемы, перспективы // Четвертые Казанские искусствоведческие чтения. Искусство печатной графики: история и современность. Материалы Всерос. науч.-практ. конф. с междунар. участием. 19–20 ноября 2015 г. Казань: Заман, 2015. С. 151–155.

***Улемнова Ольга Львовна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 73.05

***Н.М. Кириллова***

## ИЛҺАМЧЫСЫ – ТОРМЫШ
## (сынчы Л.А. Зиминаның (1933–2018) тууына 90 ел тулу уңаеннан)

Яркий представитель творчества художников Набережночелнинской организации «Союз художников России», скульптор Зимина Лидия Андреевна повышает интерес не только к монументальной, но и к станковой скульптуре. Она обогатила искусство скульптуры поэтической образностью, декоративной самобытностью, яркою фантазией, мягкостью силуэтов, жизненным содержанием. Она создавала объёмные произведения искусства из самых разных материалов (дерева, мрамора, бетона, гипса, глины). В работе использовала техники лепки, литья, резьбы и другие методики. В пропорциональных отношениях скульптор использовала классические и современные приёмы. Тема подвига во имя Родины воплощена Л.А. Зиминой в памятниках воинам Великой Отечественной войны, которые стоят на земле Украины и Татарстана.

**Ключевые слова:** культура, монументальная скульптура, монументально-декоративная скульптура, станковая скульптура, композиция.

A prominent representative of the creativity of artists of the Naberezhnye Chelny organization «Union of Artists of Russia», sculptor Lidiya Andreevna Zimina increases interest not only in monumental but also in easel sculpture. She enriched the art of sculpture with poetic imagery, decorative originality, vivid imagination, softness of silhouettes, and vital content. She created three-dimensional works of art from a variety of materials (wood, marble, concrete, plaster, clay). In her work she used sculpting, casting, carving and other techniques. In proportional relationships the sculptor used classical and modern techniques. The theme of heroic deed in the name of the Motherland is embodied by L.A. Zimina in the monuments to the soldiers of the Great Patriotic War which stand on the soil of Ukraine and Tatarstan.

**Keywords:** culture, monumental sculpture, monumental and decorative sculpture, easel sculpture, composition.

*«Реалистик, шул исәптән декоратив сәнгатьне дә яратам. Картларны һәм балаларны яратам. Физик эш яратам, бу – сугыш турындагы авыр хатирәләрдән арындыра».*

Л.А. Зимина

Зимина Лидия Андреевна (25.01.1933–03.06.2018) Уралда Чиләбе өлкәсенең Златоуст шәһәрендә туган. Ул –р эссам һәм скульптор, «Россия Рәссамнар берлеге» Бөтенроссия иҗтимагый иҗат оешмасы һәм Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы (1983 елның декабреннән). 1949 елдан Днепропетровск сәнгать училищесында укыган, 1958 елда Харьков сәнгать-сәнәгать институтын (скульптура бүлеген) тәмамлаган. 1961 елдан алып 1974 елга кадәр Харьков уенчыклар

фабрикасының баш рәссамы, УССР сәнгать фондында (Донецк шәһәре) монументаль эшләр буенча скульптор булып эшләгән.

Л. Зимина ничек сәнгатькә тартыла башлаган соң? Аның туганнан туган энесе Слава кечкенәдән үк рәсем ясарга яраткан. Лида да аңа ияргән: тирә-юнендә нинди кызыклы нәрсә күрсә, шуны ясаган. Каллиграфияне бик ошаткан. Рәсем белән мавыгуы шулкадәр көчле булган ки, ул профессиональ рәссам булырга ниятләгән. Гомумән, нәкышь белән мавыккан, әмма Днепропетровск сәнгать училищесына укырга кергәндә, укытучы аңа: «Син скульпторлар кебек фикерлисең, рәсемең зур», – дигән. Кыз аның киңәшенә колак салган. Күп еллар үткәч тә, Лидия Андреевна, үзенең укырга кергәндә ясаган рәсемнәренә карап, педагогының хаклы булуын кат-кат ассызыклаган, аны яратып, рәхмәт хисләре белән искә алырга яраткан. Материалны интерпретацияләүдә сәнгати күренеш буларак, пластика белән кызыксына башлаган. Үзенең иҗат гомерендә Лидия Андреевна Зимина төрле темаларга мөрәҗәгать итеп, төрле зурлыктагы – вак пластикадан алып биеклеге 5 метрга җиткән төрле сыннар ясаган оста. Аның эшләрен илебезнең төрле почмакларында очратырга мөмкин, әмма зур күпчелеге – Яр Чаллы шәһәрендә һәм Татарстан районнарында.

Зиминнар гаиләсе Яр Чаллыга (Татарстан) зур комсомол төзелешенә – «КАМАЗ»га 1974 елда килә. Искиткеч бай һәм данлы күпгасырлык тарихка ия бу шәһәр – бүген көчле һәм куәтле сәнәгать үзәге. Шишкин урманнарының читендә урнашуы һәм заманча мәдәни дәрәҗәгә ирешүе белән дә игътибарга лаек каланың тормышында кешеләр мөһим урын тота, аларның мәдәни потенциалын, Европа форматындагы шәһәр буларак, хәзерге Яр Чаллы формалаштыра. Бөек Ватан сугышы елларында чаллылыларның каһарманлыгына һәм ныклыгына таң каласың, алар Камада хезмәт батырлыгы күрсәтә, гомумән, бик талантлы һәм иҗат куәсе көчле халык яши биредә.

Шунысы игътибарга лаек: бу вакытта Л. Зимина шәһәрдә бердәнбер скульптор булып чыга. Лидия Андреевна бирегә һөнәри яктан тәмам җитлегеп килгән һәм кырык елдан артык гомерен яраткан Чаллысына һәм Татарстанга багышлаган, шәһәр һәм Кама аръягы төбәкләре скульптурасын үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән. Ул, РСФСР сәнгать фондының Яр Чаллы сәнгать-җитештерү остаханәләре монументалисты буларак, ТР сәнгать фондының иҗади-җитештерү участогында эшләгән. Аның төп иҗат юнәлеше – реализм.

Л.А. Зимина эшчәнлеге скульптураның барлык төрләрен диярлек колачлый: ул монументаль әсәрләрен, мемориаль композицияләрен зур тарихи вакыйгаларга багышлаган яки бөек кешеләр истәлегенә һәйкәлләр куйган. Эре масштаб, эчтәлек берлеге, архитектура-киңлек даирәсе белән гармония – монументаль скульптурасының үзенчәлекле билгеләреннән; декоратив-парк скульптурасында аның идеяләре ташка әверелгән сәнгати агитация белән генә чикләнми, бәлки миһербанлылык, кызгану, мәхәббәт хисләре уята, матурлыкка омтылыш тудыра. Декоратив-монументаль юнәлеш кысаларында

ул – бетоннан эшләнгән сыннар авторы. Яр Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрендә балалар бакчалары диварлары аның рельеф һәм чигешләре белән бизәлгән, Г.Х. Андерсен әкиятләре мотивлары буенча декоратив композицияләре (1980 еллар, агач) Яр Чаллы шәһәренең җәмәгать интерьерларында урын алган. Табигый зурлыкта эшләнгән станоклы скульптуралары (баш, бюст, фигура, группа) бихисап: хатын-кыз бюсты (1980 еллар, 51×68,6 см), хәрби кием кигән ир-ат сыны (кеше гәүдәсенең күкрәккә кадәр булган өске өлеше, 1980 еллар, 70,5×50,8), якут студенты скульптурасы (кеше гәүдәсенең муенга кадәр булган өске өлеше (1980 еллар, 50,3×50 см). Алар якыннан карап кабул итүгә исәпләнгән һәм әйләнә-тирәдәге предметлар, архитектура белән бәйле түгел. Аның иҗатына хас жанрлар төрлелеге (портрет, сюжет, символик яки аллегорик композиция, анималистик жанр); кече скульптура формалары – вак пластика. 1990 еллардан ул кече формалар скульптурасына һәм вак пластикага мөрәҗәгать иткән. Декоратив-гамәли сәнгать (керамика, фарфор) белән дә уңышлы шөгыльләнгән.

Л.А. Зимина иҗаты белән кызыксыну – закончалыклы күренеш. Аның эшләре пластик бөтенлеге, композицион чишелешләре, тирән кешелеклелек һәм патриотик эчтәлеге белән аерылып тора. Авторның күпсанлы шәһәр һәм республикалардагы иҗат тәҗрибәсе белән танышу бай материал җыярга һәм кайбер характерлы тенденцияләрне ачыкларга ярдәм итте.

Сынчының индивидуальлеге нәрсәдә соң? Гражданлык аңы скульпторның белем дәрәҗәсен киңәйткән, аның осталыгы үскән. Кыю фантазияне эшкә җигеп, чын талант тарафыннан иҗат ителгән әсәрләр тормыш позицияләренең катлаулылыгын, кеше гамәлләренең матурлыгын, кичерешләренең тирәнлеген ачкан.

Л.А. Зимина, нигездә, хәрби тематика өстендә эшләде. Лидия Андреевна «Сугышчан Сталинград балалары» ассоциациясе әгъзасы булып тора, шулай ук берничә тапкыр Бөек Ватан сугышында Җиңү хөрмәтенә Татарстан Республикасының истәлекле билгеләре белән бүләкләнә (2000, 2005, 2010).

Л.А. Зиминаның уналты кулъязмасы («йөрәкнең уналты кисәге») бар: «Снова повторилось», «Это частичка большой истории нашей Родины» (Письма с фронта (Часть 6. Слава) Дмитрий Зимин 2) [Зимина Лидия...] һ.б. Шул авыр вакытларда да адресатына барып ирешә алганнар бит алар.

«…Целый день хожу как ребенок. Радостно вспоминать о том, что ты жива, здорова и бабушка тоже… Зима. Падает снег», «…Мама, милая, если б ты знала, как я сейчас поднялся духом, когда получил от тебя письмо. Стало теплее и радостнее», «…Вот бы хорошо, мамочка, после войны вернулись мы все домой в родные места… Твой Слава», «… Сегодня в час дня переправился на правый берег и… снова в бой за Украину. Светит солнышко, уничтожая последние кромки льда своим весенним теплом. Смотрю на деревню, на минуту забываешься,

что идет война. 30.02.1944 г.». 1944 елның 2 мартында аның соңгы хаты килгән, ә 4 мартта кече сержант Слава Тушев, хәрби антына тугры калып, каһарманнарча һәлак булган. Слава Тушевның тормышын, мәхәббәтен һәм кабатланмаслыгын чагылдырган хатлары гына калган. Әнисе Наталья Захаровна Ветрова бердәнбер улының каберен таба алмый дөнья куйган (Николаев өлкәсе, Красноармейский посёлогы дип күрсәтелгән булса да) Аны әллә ничә запрос ясап, үзе йөреп, Лидия Зимина (әнисенең сеңлесе) эзләп тапкан («Шестнадцать мгновений любви», Станислав Васильевич Тушев – туганнан туган энесе, ни өчендер үзенә Слава дип дәшүләрен яраткан, 17 яшендә фронтка киткән).

Бу коточкыч сугыш темасы халкыбыз күңелендә аерым урын алып тора, һәм ул беркайчан хәтердән җуелырга тиеш түгел. Украина, Россия һәм Татарстан шәһәрләрендәге күпсанлы монументаль скульптуралар, Донецк һәм Сумы өлкәләрендә (Украина) һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлләр авторы шул дәвернең драматик киеренкелеген үз тойгы-кичерешләре аша үткәргән һәм: «Кешеләр, Бөек сугыш геройларын исегездә тотыгыз һәм белегез», дип әйтә кебек. «Факел тоткан солдат» (1968 ел, 2 м, бетон, Красноармейск шәһәре (Покровск, Украина)), «Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга» (1980 еллар, 74,8×40 см, бетон, Донецк өлкәсе Калинино авылы), «Җиңүче» (Украина, Донецк өлкәсе), «Ана» (Сумы өлкәсе Тучное авылы), «Ана-ватан» (1964 ел, 2,5 м, бетон, Славянск шәһәре), «Сумы анасы» (1967 ел, 3 м, оригинал гипс, тон, Украина), «Ватан-ана» (1974 ел, 4 м, бетон, Доброполье шәһәре, Украина) һәйкәлләре шундыйлардан.

Л. Зиминаның аеруча әһәмиятле эшләре арасында «Кызылармиячеләргә» (1967 ел, бетон, Таганрог трассасында, Украина һәм Россия чигендә урнашкан), «Кызылармиячеләргә» (1971 ел, 5×9 м, бетон, Новоазовск шәһәре), «Ачы хәсрәт» (эшче модель, бетон, Украина), «Рельеф 1941–1945» (1969 ел, 14×2 м, бетон, Сумы өлкәсе), «Тирән кайгы кичергән ана» (1970 ел, 3 м, бетон, Украина, Товста авылы) һәйкәлләре, «Сугышка» (7×3,5 м, бетон, Украина), Донецк өлкәсе), «Өч ана» (Украина) барельефлары бар.

Бу чорда иҗат ителгән монументаль скульптуралар арасында «Теннисчы кыз» (1969 ел, 2 м, УССР фонды милке), «Финиш» (1964 ел, 2 м, бетон, Донецк өлкәсе Дзержинск (Торецк) шәһәре стадионы), «Чиләк тоткан бозау караучы» (1964 ел, 1,5 м, бетон, Украина), «Панщинада» (1963 ел, 1,5 м, гипс, тон), «Үрдәк караучы колхозчы хатын» (Донецк өлкәсе Добропольский районы, Украина) әсәрләре игътибарны җәлеп итә..

Сугыш еллары, мәңге хәтердән җуелмаячак сугышлар аның сәнгатенә бик зур йогынты ясаган, совет кешесенең батырлыгы, намуслылыгы һәм каһарманлыгы турындагы фикерләрдән илһамланып эшләгән останың иҗатында Бөек Ватан сугышы темасы зур үсеш алган. Скульптор горельефның монументаль формаларын һәм скульптура төркемнәрен берләштерергә, сугыштагы батырлыкны, совет солдатының каһарманлыгын гәүдәләндереп, вакыйгаларны мәң-

геләштерергә омтылган. Ул күп фигуралы композиция чараларыннан һәм предметлы символлардан файдаланырга яраткан. Пластикада, комплексны пространство ягыннан оештыруда, вакыйгаларның драматик асылын образлы аңлатуда кырыс формаларны өстен күргән. Материал булып бетон хезмәт иткән. Ул үзенең салкын фактурасы һәм соры төсе белән әйләнә-тирә мохитнең тыныч һәм мәһабәт панорамасына экспрессив рәвештә килеп кергән. Ачык геометрик формалар кыска һәм ачык чишелешнең нигезенә яткан. Мәдәният һәм сәнгатьнең югары традицияләренә туры китереп, Бөек Ватан сугышы темасын эпик гомумиләштерүгә, мәһабәт монументальлеккә контраст тәэсирле чаралар системасы ярдәмендә ирешкән.

Сынчының сугыш темасы белән кызыксынуы очраклы түгел. Тугыз яшендә ул Сталинградта (Волгоград) бомбёжкага эләккән, абыйсы бомба төшкән йортта һәлак булган, Лиданың аяклары яраланган... Фашистлар дистәләгән гаиләләрне әсир итеп, бөтен Россия буйлап Германиягә куганда, алар Украинада Совет Армиясе тарафыннан азат ителгән. «Бомба, которая попала в мой дом, врезалась в мое сердце. И вот всю жизнь и воюю, я делаю памятники на военные темы. Все скульпторы делали, ставили памятники воинам. Надо рассказать людям правду. Ветераны, вы поверьте, людям это очень надо» («Дети опалённые войной», видеоинтервью с Зиминой Лидией 20.09.2017, г. Иваново).

Үлем, коточкыч сугыш шаһиты, «сугыш баласы» Л.А. Зиминаның иң яхшы әсәрләре – «Сугыш ялкынын кичкән», «Сугыш чоры балалары», «Минем балачак» – бала вакыты хатирәләренә багышланган («Сугышчан Сталинград балалары» циклы, «Сугыш ялкынын кичкән» скульптурасы (1987 ел, 78×27×27 см, гипс, тон бирү, Яр Чаллы картиналар галереясы). Кечкенә Лиданың кулында һәм аркасына аскан букчада әбисе киптергән икмәк. Германиягә китәр алдыннан, соңгы тапкыр туган йорты белән саубуллашу күренеше. Күз карашы балаларча түгел, үтә җитди. Бу баланың йөз-кыяфәтенә чыккан сагышны, тугыз яшьлек кызга хас булмаган олыларча карашны оныту мөмкин түгел. «Мин үземне тасвирладым»,– диде Лидия Андреевна: «Я была также одета, когда немцы гнали нас в Германию. Только на ногах были не сапожки, а ботиночки. Через себя я попыталась передать образ того страшного времени, когда дети становились взрослее, так как иначе невозможно было выжить. Бабушка, оказывается, еще до бомбёжки сушила сухари, и тут уж раскрылся секрет. Велела забрать их с собой в дорогу. Нагрузили мне мешочек с сухарями. Остальным пришлось нести пшеницу и сахар. И всего этого было – «кот наплакал» («В Германию» (Часть 4), «Побег» (Часть 5)) [Зимин. Дети Военного...].

«Һәлак булган сугышчыларга һәйкәл» (1975 ел, 24 кв. м, бетон, Сарман районы), Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышланган һәйкәлстела, «Ана» һәйкәле (Минзәлә районы), «Солдатлар» һәйкәле (1975 ел, 3,5×7 м, бетон, Сарман посёлогы, ТАССР) кебек монументаль әсәрләр авторның югары иҗади потенциалга ия булуын раслый.

«Три головы солдат разной национальности с автоматами. Воина татарина мама лепила со своего помощника Бахтияра», дип искә ала улы Дмитрий. Аның эшләре пластик бөтенлеге, композицион чишелеше, тирән гуманистик эчтәлеге белән аерылып тора. Л.А. Зиминаның катлаулы һәм төрле пластик алымнар белән эш итүен әсәрләре үк күрсәтеп тора.

Бөек Җиңүнең 60 еллыгына багышлап, Балтач районының Ор авылы өчен эшләнгән «Тирән кайгы кичергән ана» монументаль скульптурасы (2005 ел, 4 м, бетон) кеше язмышларының драматизмы белән сугарылган. Шундый ук дүрт метр биеклегендәге монументаль скульптураны (шәхси заказ) ул Самарада бетоннан торгызган. Зиминаның реализмы яңа төсмер алган: аның җыелма ана образы – борынгы милли киемнәр кигән татар хатыннары – нәфис лиризм белән өретелгән («Тирән хәсрәт кичергән хатын», Татарстан Республикасының Мөслим районы Калинин исемендәге колхоз). Скульпторга «Ватан хакына батырлык күрсәтү», «Ана булу», «Күп нәрсәдән мәхрүм балачак» темалары якын: «Тирән кайгы кичергән хатын-ана» барельефы (1980 еллар, 51×55,2 см, Яр Чаллы шәһәренең «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее»). Кулына лавр ботагы тоткан яшь хатын-кыз скульптурасы, бар буйга баскан килеш (1980 еллар, Яр Чаллы шәһәренең «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее»), «Икешәр канәфер чәчәге тоткан тол хатыннар» скульптурасы, бар буйга баскан килеш (1980 еллар, Яр Чаллы шәһәренең «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее»).

Күргәзмәләрдә автор станоклы скульптураларын тәкъдим итте. Төп тема – хәрби-патриотик. Тере характер белән эш итү, шәхеснең үзенчәлеген, рухи асылын аңлау – болары партизан, разведчик, Советлар Союзы Герое Зоя Космодемьянскаяны (1923–1941) («Таня») символлаштыра (1980 ел, 73×54 см, Яр Чаллы шәһәренең «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее»). Скульптурада кеше гәүдәсенең күкрәккә кадәрге өлеше сурәтләнгән. Бюст тулаем карасу-көрән буяу белән капланган. Кызның карашы кыю һәм нык. Җилкәләре бераз артка киткән. Уң җилкә һәм күкрәге аша гәүдәсе урап бәйләнгән бау уза.

Исеме аз билгеле партизанка Лиля Карастоянованың батырлыклары аның бюстында чагылдырылган (1988 ел, гипс, 19 нчы мәктәп, «Преодоление» музее, Яр Чаллы шәһәре), Лидия Андреевна «Кечкенә Лиля» китабын украинчадан рус теленә тәрҗемә иткән. Конкрет образлар үсеп, символга әверелә һәм аның иҗатының пафосын билгели. Яшь буынга патриотик тәрбия бирүне хуплап, ул 1 нче номерлы балалар сәнгать мәктәбе укучылары белән очрашулар үткәргән, Бөек Ватан сугышы чоры авырлыклары турында сөйләгән, китапханә фондына сәнгать турында китаплар тапшырган.

Станоклы скульптура әсәрләре Зимина иҗатында мөһим урын алып торган героик-патриотик темага багышлана. Киң портрет галереясында ул портрет-бюстның классик формасын модельнең дөрес һәм тәэсирле характеристикасы белән гаҗәеп уңышлы берләштерә. Бөек Ватан сугышында катнашкан кеше бюсты (1980 еллар,

60×51,4 см, гипс, әвәләү, Яр Чаллы шәһәре «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее»). Скульптура кеше гәүдәсенең күкрәккә кадәрге өлешен гәүдәләндерә. Күзләр, иреннәр кысылган, ияк туры. Ир-атның карашы кайдадыр еракка төбәлгән. Сул күкрәгендә – ике медаль. Беренче медальнең өске өлешенә – «Мәскәү оборонасы өчен», ә икенчесенә «Батырлык өчен» дип язылган. Медальләргә барлык язулар һәм сурәтләр калкытып төшерелгән. Скульптор гражданлык батырлыгы күрсәткән кеше турындагы күзаллауларын чынга ашырган. «Кызылармияче» скульптурасында шулай ук кешенең күкрәккә кадәрге өлеше сурәтләнә (1980 еллар, 45×71,5 см), «Кызылармияче» бюсты (1980 еллар, 82,9×68,1 см, Яр Чаллы шәһәренең «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее»). Түбәндәге портретлары бар: Советлар Союзы Герое Илдар Мәннанов (1975 ел, бюст 1,5 м, гипс, Яр Чаллы картиналар галереясы), «М. Җәлил» (1984 ел, бюст, мәрмәр, Минзәлә педучилищесы), «Советлар Союзы Герое Г.В. Вәҗетдинов» (1988 ел, бюст, төсле металл, Мөслим районы Татар Бүләре авылы). «Советлар Союзы Герое Газинур Гафиатуллин» (1990 ел, 1,5 м, гипс, Түбән Кама музее).

Гражданнар сугышында катнашкан татар революционеры һәм иҗтимагый-сәяси эшлеклесе Вахитов Мулланур Муллаҗан улының (1885–1918) бюсты (1980 ел, 9×48,5 см, әвәләү, Яр Чаллы шәһәренең «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее»). Бюст тулысынча ачык соры төстәге буяу белән капланган. Башындагы сарык тиресеннән тегелгән кубанкага Кызыл армия йолдызы беркетелгән. Бүрек астыннан маңгай чәче күренеп тора. Ян яклардан да чәче чыккан. Ябык йөзле, туры өркәч борынлы, кашлары матур, дуга сыман, күзләре янып тора, иреннәре нәзек, ияге туры. В.И. Ленин бюсты (300 кг) 1985 елда ак мәрмәрдән заказ буенча эшләнгән. Сынчы һәр персонажны үз холкы, кабатланмас үзенчәлеге белән бирә.

Л.А. Зимина иҗатында героик-романтик линия «Совет язучысы Николай Алексеевич Островский (1904–1936) «Надежда Константиновна Крупская» (1975 ел, 39,5×20,6×18 см, гипс, тон бирү, Яр Чаллы картиналар галереясы) тарихи портретларында дәвам итә. Г. Тукай портретында (1980 ел, 1,5 м, Татарстан Республикасы Тукай районы) классик формалар өстенлек алган. Г. Тукайның күкрәккә кадәр өлеше сурәтләнгән сыны да (1980 еллар, 68,7×50,6 см) бар. Батырлык темасы космонавтлар Ю.А. Гагарин (1987 ел), очучы-космонавт А.А. Леонов (1977 ел, гипс) портретлары белән дә бәйле. Аларда гадәти дөнья һәм иксез-чиксез Галәм чагыштырыла.

Аның портретлары һәрвакыт җентекләп уйланылган була, шәхес бөтен үзенчәлекләре белән бирелә. Скульптор, я йомшак кына әвәләү манерасын сайлый, я силуэтка басым ясап, пластик формаларны көчәйтә. Бу ысул әсәрләренең рухи эчтәлеген баета. Зимина хезмәт кешесенең шәхси сыйфатларын ышанычлы итеп бирә. Болар – авыл кызының ике метрлы фигурасы – «Үрдәк караучы» (1964, бетон), «Тавык караучы үзенең кош-кортлары белән» скульптур композицияләре (1980 еллар), «КАМАЗ» төзүче кыз» (1976 ел,

100×70 см, балчык), «Металл эретүче, Социалистик хезмәт герое Г.П. Боровиков» (1985 ел, гипс, тон бирү), «Сталевар», «Социалистик Хезмәт Герое» («Гигант» совхозы директоры Н. Зиатдинов) (1990 ел, 53см, гипс, әвәләү) (Яр Чаллы шәһәренең «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее»).

Агачтан эшләнгән «Музыкант» скульптурасында (1985 ел, 6×29×6 см, агач, кисеп-уеп бизәк төшерү, Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее) ир-ат сурәтләнгән. Башында бүрек, озын күлмәк, чалбар кигән, яланаяк. Кулында балалайка. Башы бераз сулга иелгән. «Эшче ялда» скульптур композициясе (1980 ел, 42×17,5 см, гипс, металл, әвәләү, сварка, заводта җыелган, Яр Чаллы шәһәренең «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее») эш киеменнән, башына каска кигән ир-ат. Каска астыннан чәче күренеп тора, йөзе тар, күзләре арыган. Аяклары тездән бөгелгән һәм күкрәгенә тиеп тора, аларны куллары белән кочаклаган. Уң якта саплы тимер таяк тырпаеп тора. «Диңгез тубыктан» (1980 ел, 48×22 см, гипс, агач, Яр Чаллы шәһәренең «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее»), көмеш төсендә, ком төсендәге фанерадан эшләнгән турыпочмаклы постаментка урнаштырылган. Гаиләнең хәрәкәттә вакыты сурәтләнгән. Ир кеше уртада, аның уң ягында хатын-кыз, сулда кечкенә бала, әтисе аны кулыннан тоткан һәм тартып бара. Хатынның таралган бөдрә чәчләре җилкәдән түбән төшеп тора, плащ кигән, ир кеше – озынрак пиджактан, чалбардан, баланы бүреге һәм башка кием-салымы өстеннән шәл белән төргәннәр. Ир кеше бер кулы белән хатынын кочаклый, үбә, тегесе яртылаш аңа таба борылган һәм кулын күкрәгенә куйган. Лирик атмосфера, бербөтен композиция, компактлы, бердәм халәткә «буйсындырылган». Характеры буенча камералы әсәр. Фигуралар бер-берсенә бик якын урнашкан, интим, композициядә бала фигурасы бар. «Ир-ат газаплары» (1985 ел, 11×36×9 см, агач, кисеп-уеп бизәк төшерү, Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее), агач композициясендә, ике ир-ат фигурасы сурәтләнгән. Уң яктагы ир буйга тәбәнәгрәк, күлмәк һәм чалбар кигән, кушырган кулларын күкрәгенә куйган. Икенчесе – озынрак, ябыграк, озын чәчле. Күлмәк һәм чалбардан. Башы уңга – янәшәдә басып торган ирнең башына авышкан. Икесе дә җырлый. «Кама» скульптурасы. (1980 еллар, 57×4×26,5 см, агач, кисеп-уеп бизәк төшерү, тон бирү, Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее). Бу түгәрәк скульптурада Кама елгасы татар милли киемендәге (билле озын күлмәк, алъяпкыч) яшь кыз образында сурәтләнгән. Кызның озын чәчләре дулкыннарны хәтерләтә. Гәүдәсе сулга борылган, куллары чәчләренә – «дулкыннар»га тоташкан.

«Яшь спортчы волейбол тубы белән» («Футболчы», прототибы – малайлар белән футбол уйнаучы улы Владимир) (1974 ел, 47,6×17×16,3 см гипс, тон бирү, Яр Чаллы картиналар галереясы), яшүсмернең рухи дөньясын аның шатлык-кайгылары, кәефе алмашыну аша ача. Әсәрнең образлы-пластик чишелеше бала күңеленең ышанучан һәм тиз яраланучан булуын, хыялый һәм ирекле балачак

образын ассызыклый. Түгәрәк скульптура. Шорты кигән малай уң кулына волейбол тубы тоткан, аны ботына кыскан. Уң аягы алгарак чыгып, тез тиңентен бөгелгән. Аякларында спорт аяк киеме. Уң аяктагысының башы тырналган. Сул кулы белән баш чүмечен тоткан. Фигура квадрат постаментка урнаштырылган.

«Җәлил» мемориаль-парк ансамблендәге (Яр Чаллы шәһәре) Муса Җәлил һәйкәле (авторлары – сынчы Лидия Зимина һәм архитектор Георгий Иванов) Гидротөзүчеләр бистәсе скверында куелган, зур пространствога исәп тотып эшләнгән. 1985 елның 8 маенда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 40 еллыгына ачылган. Шәһәрдә һәм республикада яхшы билгеле бу һәйкәл Җирле әһәмияттәге күчемсез тарих, мәдәният һәм архитектура истәлекләренең дәүләт саклау реестрына кертелгән (2002 ел). Мемориаль-монументаль һәм парк сәнгате комплексына органик рәвештә ярашкан. Монументаль композициядә һәр элемент, һәр деталь символик мәгънәгә ия. Таш плитә түшәлгән кабарынкы диск нигез хезмәтен үти (патриот-шагыйрь һәм аның иптәшләре җәзалап үтерелгән Берлин төрмәсенең символы). Дискның түбәсендә тагын бер әйләнә (мәңгелек тормыш символы) – түгәрәк цоколь-пьедестал, анда ачык соры травертин белән капланган ике стела күтәрелә: алар герой шагыйрь турында өч өлештән торган бердәм хәтер образын тудыра: бу – штык, каурый каләм һәм очлы татар аркасы (стелаларның чалыш кырыйлары белән барлыкка килелә) архитектур образы. Стелалар аша сузылган гранит байракта ачылган «Моабит дәфтәре». Аның битләрендә шагыйрь башы горельефы рәвешендә бирелгән. Байрак, китап һәм шагыйрьнең башы алсу-кызыл төсләрдәге Карелия гранитыннан эшләнгән. Ансамбльне корганда пластиканың күләм-киңлек үзенчәлекләре киң файдаланылган. Алар архитектураны, скульптураны һәм табигый компонентларны берләштереп тора. «Җәлил» композициясе скульптордан югары һөнәри осталык таләп иткән (балчык, металл, гранит, агач). Һәйкәл ялган патетикадан азат. Скульптураның иң көчле якларыннан берсе шунда: биредә образның тарихи дөреслеге монументның идея-мәгънәви эчтәлеге белән тоташкан.

Л. Зимина иҗатында балалар һәм картлар образлары зур урын алып тора. «Яша абый»да (бетон, сәнгать фонды) скульптор портретка да, жанр композициясенә дә мөрәҗәгать итә. Монда барыннан да бигрәк хисләрнең лирик җылылыгын бирергә омтылыш, хисси төсмерләр гармониясе һәм байлыгы сиземләнә. Стильләштерү, ана образын илаһилаштырып аңлату бар. Балачак – бик авыр сугыш елларына туры килсә дә, иң гүзәл вакыт. «Сугыш чоры балалары», «Минем балачагым» – авторның балачак хатирәләренә нигезләнгән. Аналар, яшьлек, мәхәббәт темаларына багышланган композицияләре сынчының биографиясе белән бәйле: «Дима» (улының портреты) (1975 ел, 24×16,5×19,5 см органик пыяла, тон бирү) – кечкенә малай башының түгәрәк скульптурасы. Йөзе түгәрәк, борыны почык. Ачык карашы каядыр төбәлгән. Чәче уңнан сулга ачылган. Колаклары

кечкенә, иреннәре кабарып тора, уеп куйган кебек. Иягендә чокыры бар. «Ана һәм бала» (1975 ел, 49,3×25,5×45,3 см, гипс, тон бирү, Яр Чаллы картиналар галереясы) – бала белән хатынның түгәрәк скульптур портреты. Хатын-кыз утырган килеш сурәтләнгән. Бераз югары күтәрелгән сул учында шәрә сабыен тотып тора, баланың күзләре анасына төбәлгән. Уң һәм сул аяклары бергә тоташкан. Соры тонда. «Ана» скульптурасы (1975 ел, 73,3×23×15 см, гипс, тон бирү, Чаллы картиналар галереясы). Урта яшьләрдәге хатынның скульптур портреты. Ул басып тора. Башы салынып төшкән. Йөзе кайгылы. Чәчләре (уртадан ярып) баш түбәсенә җыелган. Озын күлмәктән. Караңгы кызгылт-көрән тонда. «Балалы хатын» композициясе (1980 еллар, 43×15,5см, гипс, кулдан эшләнгән, Яр Чаллы шәһәренең «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее»). «Кулына бала тоткан хатын» (1980 еллар, 45,5×24 см, гипс, әвәләү, Яр Чаллы шәһәренең «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее») – бронза төсендәге композиция, турыпочмаклы постаментка урнаштырылган. Хатын утырган, баласы йөзе белән аңа борылган. Уң кулында түгәрәк әйбер, сулы белән баласын тоткан, терсәк турысында сөлге эленгән. Чәче озын, дулкынланып тора. Баласы муенына кагылганга, башын бераз артка җибәргән. Йөзе эре чалымлы, сулга караган, озын күлмәк кигән. Бала трусиктан гына.

«Төлке һәм торна» (1973 ел, 1,5 м, бетон, балалар бакчасы, Донецк шәһәре), 1980 еллар, 69,9×50,1 см). «Элли дуслары белән» (1976 ел, 1 м, гипс, тон бирү, 27 нче комплекс, балалар бакчасы), Волковның «Зөбәрҗәт каласы тылсымчысы», «Жираф һәм үгез бозау» әкияте (1976 ел, 1,5 м, гипс, тон бирү, балалар бакчасы, кышкы бакчада), агачка күләмле-рельефлы кисеп-уеп бизәк төшерү: «Белоснежка һәм җиде гном» (1978 ел, агач, гипс, Прибрежный паркы, Яр Чаллы шәһәре), «Алтын эзләүче», «Беркатлы кеше» (Гидротөзүчеләр урамы, Яр Чаллы шәһәре). «Бүре һәм Кызыл Калфак» скульптур композициясе (1980 еллар, 50,6×49,9 см), «Арыслан һәм кулына кечкенә эт тоткан кыз» (1980 еллар, 68,8×50,9 см), «Кар кызлары» (1980 еллар, 70×50 см), «Жираф һәм кәҗә бәтие» (1980 еллар, 70,2×50,4 см).

Скульптура әйләнә-тирә мохитне эстетик оештыруда әйдәп баручы ролен үти. Шәһәр ихтыяҗларын күздә тотып, ул парклар өчен «Чишмә янында» декоратив скульптурасын (1977 ел, бетон, Яр Чаллыдагы «Жемчужина» шифаханәсе территориясендә) эшли һәм бүләк итә.

1990 еллардан монументаль социалистик реализм һәйкәлләренә дәүләт заказлары кими, Л. Зимина кече формалар скульптурасына һәм вак пластикага мөрәҗәгать итә. Аның талантына хас лиризм һәм юмор нәкъ менә шуларда ачыла. Ул авыл тормышыннан алынган күренешләрне тасвирлый, көндәлек тормыш шигърияттен ачканда гадәти матурлык кануннарыннан ерак формаларны эшкә җигә. «Сабантуй. Көрәшчеләр» (1993 ел), «Татар малае этләр белән» скульптурасы (1980 еллар, 25×19 см, гипс, кулдан эшләнгән, Яр Чаллы шәһәренең «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее»).

Л. Зимина декоратив-гамәли сәнгать (керамика) белән дә уңышлы шөгыльләнә («Икәү» (1988 ел, фарфор). Яраткан материалы – агачны үзләштерүдә осталыгы артканнан-арта бара («Песине кызганам», Г. Тукай әкиятләре буенча (2006 ел, агач)).

Оригиналь композицион чишелешләр, материалны яңа алымнар кулланып эшкәртү кече формалар скульптурасын кызыклы итә, иҗади фантазияне эшкә җигә. Мондый күзаллау скульпторга теләсә кайсы сюжетта кабатланмас үзгәлекләр ачарга мөмкинлек бирә, тормыш күренешләрен, камера портретларын сурәтләүгә этәрә. Традиция буенча, образларның гармониясе һәм шигърияте турындагы күзаллауларны декоратив пластика белән бәйлиләр. Ул тамашачы белән иркле диалогка йөз тота, төрле мотив һәм сюжетларны аңлатуда рәссамның фантазиясенә тулы ирек бирә. Скульптор үзенең әсәрләрендә тормыш матурлыгы, яңа дөньялар шигърияте, азатлык өчен көрәштәге котылгысыз авыр югалтулар турында уйлануларын гәүдәләндергән. Хисси, эчтәлекле сюжетлар эзләү көчәйгән. Соңгы елларда милли тема ул яраткан темаларның берсенә әверелгән, пластик образларда (кече пластика) татар халкының көнкүреше һәм бәйрәмнәре белән бәйле күренешләр күрсәтелгән, ул җирле халыкның тарихын, көнкүрешен һәм яшәү рәвешен яратып тасвирлый. Сәнгатьнең үзенчәлеге тема һәм образлар, пластик ритмнар, материалны эшкәртү характеры аша ачыла. Шул ук вакытта ул башка халыкларның да мәдәнияте һәм көнкүреше белән кызыксынган («Көрәш» (1990), «Мәңгелек мәхәббәт» (1990, пластика), «Пират» (2007, бетон, Самара шәһәре), «Агач ат» (2007, пластилин), «Бабай» (1981, агач), «Флора» (1991, шамот), «Гитаристка» (1991, шамот), «Мария» (2007, гипс).

Декоративлыкка рәссам скульптурага төсләр кертеп ирешә, шул рәвешле ул фактураны баета. «Чуар тавык» (1992 ел, 18×9×8 см, яндырылган балчык, бизәк, Яр Чаллы картиналар галереясы, керамикадан эшләнгән, куыш скульптураның аркасында вак акча өчен тишеге бар. Канатлары, койрыгы, башы кызыл-алтын төсләр белән бизәлгән. «Юлчы» – өстенә ике төймәле озын кием кигән ир-ат фигурасы. Уң кулында таяк. Уң җилкәсе аркылы (сул җилкәгә таба) авызы бәйләнгән капчык аскан. Йөз чалымнары ачык, мыеклы, сакаллы, чәчләре куе, бөдрә. Якасы һәм манжетлары кабарып тора (2012 ел, 29,5×15,5×13 см, яндырылган балчык, тон бирү, Яр Чаллы картиналар галереясы). «Чеби караучы» – кулларына түгәрәк тәлинкә тоткан хатын-кыз фигурасы. Башына яулык бәйләгән. Йөз чалымнары шартлы. Озын күлмәгенең итәге бераз киңәеп киткән. Итәк өлешендә вертикаль сызыклар бар (2012 ел, 18,5×10,5×9 см, яндырылган балчык, Яр Чаллы картиналар галереясы).

«Гаилә» дип аталган күп фигуралы композициядә биш кешедән торган гаилә сурәтләнгән. Алгы планда уенчык ат өстендә бер малай утыра. Ул уң кулын баш өстенә күтәргән. Аннан соң – дүрт кешелек төркем. Сул кулына бала тоткан ир-ат уң кулы белән хатынын кочаклый. Алда биш яшьләр чамасы бер кыз басып тора. Хатын

(йөкле) сул кулы белән корсагын тоткан. Ачык кызгылт-көрән төстә (2007 ел, 22,5×13,5×10,5 см, пластик, тон бирү, Яр Чаллы картиналар галереясы).

«Комсыз» – чүгәләп утырган камзуллы малай сыны. Ашамлык тулы зур тәлинкәне күкрәгенә кыскан. Башында түбәтәй (2000 ел, 12×7,8×9,8 см, яндырылган балчык, Яр Чаллы картиналар галереясы»). Шулай итеп, Л. Зимина керамикада уңай перспективалар ача. Шамотны кече пластика кысаларында үзләштерү скульптура сәнгатенең чикләрен киңәйтә. Шамотның пластик сыйфатларын заманча күрсәтү иҗатка уңай йогынты ясый, аның һөнәри мөмкинлекләрен һәм образлы фикерләвен баета. «Сон пастуха с собаками» (1986, шамот) әсәре моңлы лирик сагыш белән сугарылган. Балалар һәм хайваннар образлары аеруча сыгылмалы һәм күңелгә ятышлы. Лирик жанр композицияләре 1980–1990 елларда да дәвам итә, аларда ул геройларының рухи халәтләрен ятратып һәм йомшак юмор белән тасвирлый. «Ветераннар чәй эчә» (1992 ел, 25×18×18 см, шамот, яндыру, тон бирү, Яр Чаллы картиналар галереясы) скульптурасында түбәтәй кигән ике өлкән яшьтәге ир-ат сурәтләнгән. Берсе касәдән чәй эчә, икенчесе касәсен кулына тотып, беренчесенә карый. Бу эш (1993 елның 14–17 декабре, Тольятти – Яр Чаллы) һәм 1995 елда Парижда (Франция) оештырылган күргәзмәләрдә күрсәтелде [Пудакова, с. 33].

Л. Зимина 1956 елдан башлап шәһәр, республика, Россия, бөтенсоюз күргәзмәләрендә катнаша. «Зур Идел» зона күргәзмәсендә була (Түбән Новгород, 2003). Тукай районы мәктәпләрендә, Яр Чаллы картиналар галереясында (1985, 1987, 2003) шәхси күргәзмәләрен оештыра, 2008 елда аның 100 дән артык эше экспозицияләргә (шуларның төрле материалларда башкарылган 36 сы – төп нөсхә) куелган иде. Ул игелекле эш – тәрбия һәм эстетик агарту белән шөгыльләнде. Аның инде сәнгате тарихка әйләнеп бара. Бүген без аның гуманизмга нигезләнгән иҗатына зур бәя бирәбез.

Л. Зимина – төрле материалларда башкарылган монументаль һәм станоклы эшләр авторы. Югары класслы профессионал. Үз почеркын булдырган скульптор. Аның эшләре Татарстан Республикасы һәм Россиядәге күп кенә шәхси коллекцияләрдә, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Яр Чаллы картиналар галереясы, Яр Чаллы шәһәренең «Тарих һәм туган якны өйрәнү музее»нда, дәүләт каталогында урын алган, шәһәр һәм төбәктәге күп кенә иҗтимагый биналарның интерьерларын бизи.

Аның иҗат биографиясенә гаҗәеп тотрыклылык, үзенә гадәттән тыш хезмәт сөючәнлек, гайре табигый зыялылык, тыйнаклык һәм мәрхәмәтлелек хас. Алар ире нәкышьче рәссам Александр Георгиевич белән ике малай (Владимир һәм Дмитрий) үстерделәр. 2013 елда Яр Чаллы картиналар галереясында ирле-хатынлы Зиминнарның «Зиминнар иҗаты» («Дары Зиминых») дип аталган зур күргәзмәсе эшләде. Анда аларның скульптурага, сынлы сәнгатькә караган һәм график эшләре күрсәтелде. Күргәзмәгә куелган бөтен эшләрен Л. Зимина

әлеге картиналар галереясына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музеена тапшырырга карар кылды.

Л. Зимина, шәһәр скульптурасы үсешенә зур өлеш керткән өчен, Мәдәният идарәсенең һәм Мәдәният министрлыгының күпсанлы мактау грамоталары белән бүләкләнгән. 1987 елда аңа «Коммунистик хезмәт ударнигы», «КАМАЗ төзелеше ударнигы» исемнәре бирелгән, 1989 елда аңа «Хезмәт ветераны» медале тапшырылган. 2013 елда Россия Рәссамнар берлеге секретариаты карары белән Лидия Андреевна «Рухият. Традицияләр. Осталык» Көмеш медале белән бүләкләнгән, ә 2014 елда нәтиҗәле хезмәте һәм Яр Чаллы шәһәре мәдәниятен үстерүгә зур өлеш керткәне өчен аның исеме «Мәдәният» тармагының Мактау китабына теркәлгән.

**Әдәбият**

Архив. Муниципальное бюджетное учреждение «Набережночелнинская картинная галерея имени Г.М. Хакимовой».

Архив. Муниципальное автономное учреждение культуры города Набережные Челны «Историко-краеведческий музей».

https://goskatalog.ru/portal/#/collections?q=зимина&imageExists=null&typologyId=3 (Мөрәҗәгать итү вакыты: 15.11.2023.)

*Гилаев. У.* История в полный рост // Вести КамАЗа. 2008. № 4. С. …

Государственный каталог Музейного фонда Российской Федерации. URL: https://goskatalog.ru/

Дизайн городской среды 1970–1980 гг. Электронный каталог / сост. Е.А. Паршикова; авторы текста: Е.А. Паршикова, С.А. Сафина, 2022 г.

Зимина Лидия Андреевна // Энциклопедия города Набережные Челны / гл. ред. Б.Л. Кузнецов, М.Ш. Бибишев; отв. ред. Б.А. Канеев. Казань: Идель-Пресс, 2007. С. 118

*Зимин Д.А.* Дети Военного Сталинграда «Снова повторилось» // URL: https://proza.ru/2022/09/28/944

*Зимин Д.А.* Семейный Архив Зиминых.

*Пудакова О.В.* Два Автограда. Тольятти – Набережные Челны. 1995 г.

*Силатьева Н.* «Шестнадцать мгновений любви», музей-панорама «Сталинградская битва», государственное хранение. Полевая почта, газета «Вечерний Волгоград», 1990.

*Султанова Р.Р.* Искусство новых городов Татарстана. Казань, 2001.

*Светлов И.С.* О советской скульптуре 1960–1980 очерки. М.: Советский художник, 1984.

*Фаткуллин С.А.* Набережные Челны и Тольятти. Два Автограда. 14–17 декабря 1993 г., г. Набережные Челны.

***Кириллова Надежда Михайловна,***
*Яр Чаллы шәһәренең 1 нче номерлы*
*балалар сәнгать мәктәбе укытучысы*

УДК 09/2-23

***Н.Г. Гәрәева***

# КАЗАН КОЛЛЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ УРТА АЗИЯДӘ КҮЧЕРЕЛГӘН КУЛЪЯЗМА КОРЪӘННӘР

Согласно актуальным на ноябрь 2023 года данным инвентарного учёта в собраниях арабографичных рукописей Казани хранится более 280 списков Корана, датируемых XVII – началом XX века. Среди них выявлено четырнадцать рукописей Корана, в основном привезённых татарскими шакирдами после учёбы в Бухаре и Самарканде. Десять рукописей содержат полный текст Корана. С художественной точки зрения к наиболее интересным рукописям относятся четыре полнотекстовых списка и один список с утратами текста. Классическое оформление имеют три рукописи: две из собрания Научной библиотеки Казанского университета и один из Национального музея Республики Татарстан. Две рукописи этих же собраний явно имеют общие особенности оформления (в декоре и почерке), но индо-афганский список Национального музея выделяется качеством исполнения, а университетский выполнен в подражание этой традиции письма.

**Ключевые слова**: Казанские собрания списков Корана, Средняя Азия, каллиграфия, маргиналии, декор, ‘унван, золочение, орнамент, тасмиййа, сура, айат, джуз.

According to current data (actual to November 2023) of the acquisitions inventories Kazan collections of Arabic manuscripts contain more than 280 copies of the Qur’an, dated from the 17th to the beginning of the 20th centuries. Among them there are fourteen manuscripts of the Qur’an which were mainly brought by Tatar shakirds to their homes after studying in Bukhara and Samarkand. Ten manuscripts contain the complete text of the Qur’an. From an artistic point of view, the most interesting manuscripts present four full-text items and one copy with losses in text. Three manuscripts have a classical decoration: two from the collection of the Scientific Library of Kazan University and one from the National Museum of the Republic of Tatarstan. The two manuscripts of the same collections clearly have common features in decoration and handwriting but the Indo-Afghan copy of the National Museum stands out for the quality of its execution and the university one is made in imitation of this tradition of writing.

**Key words:** Kazan collections of copies of the Qur’an, Central Asia, calligraphy, marginalia, decor, ‘unwan, gilding, ornament, tasmiyyah, surah, ayah, djuz.

Казанда утыз меңнән артык гарәп язулы мөселман кулъязмалары тупланган. Бу мирасның төп өлеше биш фәнни үзәктә саклана: Казан (Идел буе) федераль университетының кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә (КФУ ЛФК КСКБ), Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә (ТӘһСИ ЯМҮ), Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә (ТР МК КСКБ), Татарстан Республикасы Дәүләт архивында (ТР ДА). Гарәп

язулы кульязмалар, азрак күләмдә булса да, Татарстан Республикасы Милли музеенда (ТР ММ), Россия Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәге Үзәк китапханәсендә (РФА КФҮ ҮК), «Казан Кремле» Дәүләт тарих, архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгында, Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музеенда һәм шулай ук шәхси китапханәләрдә[1] бар. Санап үтелгән оешмалардагы материалларның саны соңгы еллардагы археографик экспедицияләрдә табылган һәм әле эшкәртелеп, исәпкә кертелергә өлгермәгән табышлар хисабына даими арта тора[2].

Казандагы бүгенге төп кульязма коллекцияләр 1960 елдан башлап, ел саен, Татарстан районнарына гына түгел, хәтта элеккеге СССРның (нигездә, РСФСРның), аннан Россия Федерациясенең татарлар төпләнеп яшәгән төрле төбәкләренә оештырылган археографик экспедицияләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә тупланган. Казан университеты һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты экспедицияләрне даими һәм системалы рәвештә оештыра килә. 1990 еллардан, университет белән бергә, Татарстан Милли китапханәсе хезмәткәрләре дә экспедицияләргә чыга башлый. Хәзерге вакытта исә фәкать Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты гына фәнни экспедицияләр оештыруын дәвам итә.

Яңа кульязма коллекцияләр туплануда археографик экспедицияләрнең ярдәме зур булды, Казан федераль университеты һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фондларында гарәп телле кульязма һәм басма китапларның саны бермәбер артты. Әмма соңгы чор тупланмаларының үзәген татар интеллектуаллары һәм китап сөючеләренең шәхси китапханәләрендәге кульязма китаплар тәшкил итә. Алар – XVIII–XIX гасырларда мәшһүр гаиләләрнең берничә буыны тарафыннан җыелган мирас. 1920 елларда шундый китапханәләрнең күбесе Үзәк Көнчыгыш китапханәсендә саклана, 1930 елларда Казандагы бер төркем дәүләт учреждениеләре үзгәртелеп, яңадан формалаштырылганнан соң, кульязмалар Казан университеты китапханәсенә тапшырыла. Археографик экспедицияләр оештырыла башлаганчы, университет китапханәсендә чама белән өч мең ярым гарәп язулы кульязма кодекс исәпләнгән.

Әлеге мәкаләбездә Татарстан Фәннәр академиясе тупланмаларында, Казан федераль университеты, Милли музей, Россия Фәннәр академиясе Үзәк фәнни китапханәсендә, «Казан Кремле» музей-тыюлыгында саклана торган кульязма Коръәннәргә күзәтү ясала. Аларның саны 280гә җитә. Әлеге кульязмаларның иң зур күпчелеге – Коръәннең шәхси куллану өчен башкарылган татар нөсхәләре. Аларда текст язганда төп игътибар, хәтта каллиграфия күзлегеннән

---

[1] Фольклорчы галим Нәкый Исәнбәт (1899–1992) коллекциясеннән кала, алар сирәк һәм санаулы нөсхәләр булып исәпләнә.

[2] КФУ ЛФК КСКБ (15 мең сакл. бер.), ТӘһСИ ЯМҮ (8 меңнән артык сакл. бер.), ТР МК КСКБ (9 меңнән артык сакл. бер.).

караганда да, бизәлешкә түгел, ә юллар арасында *тәҗвид* кагыйдәләрен җентекле күрсәтүгә, шулай ук текст язылган битнең якягында калган буш урыннарда Коръән текстының бүленеш (кодификация) билгеләрен куеп чыгуга (сүрә, аятьтән тыш), сәҗдә һәм рөкүгъ урыннарын күрсәтүгә бирелә. Чөнки боларның барысы да – Коръәнне укыганда үтәлергә тиешле кагыйдәләр.

Шул ук вакытта әлеге 280 нөсхә арасында Урта Азия һәм Якын Көнчыгыш кулъязмалары да бар. Аларны, гадәттә, Бохара яки Сәмәркандта белем алган шәкертләр яисә Истанбулга, Каһирә, Мәккә, Мәдинә кебек шәһәрләргә барган, хаҗ кылган кешеләр алып кайта торган булган. XIX гасыр урталарына таба Казанда китап сәүдәсе җайга салына, бу чорда китап сатучы сәүдәгәрләр аша кулъязма һәм басма китапны заказ белән дә, соңрак исә Урта Азия, Әфганстан (Кабул, Һират), Һиндстан (Лахор) һәм Якын Көнчыгыштан (Каһирә, Бәйрут) һ.б. җирләрдән почта юлы белән дә кайтартып булган.

Казан коллекциясендә Урта Азия Коръән нөсхәләре күп булмаса да, алар үзенчәлекле текст бизәлешенең региональ традицияләрен аңлау, өйрәнү өчен яхшы үрнәк булып тора.

Бүгенге көндә Казан җыелмалары арасында ундүрт кулъязма Коръәннең Мавәраэннәһердән[1] булуы ачыкланды.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фондларында Коръәннең 200 дән артык нөсхәсе саклана, шуларның бишесе – Урта Азиядән. Алар арасында *Һәфтияк* (39 нчы фонд, сакл. бер. 232) – Институт тупланмаларына 1962 елда археограф галим Сәет Вахидинең (1887–1938) шәхси коллекциясе белән кергән. Бу кулъязманың тексты өстендә эш тәмамланмыйча калган. Сүрәләрнең исемнәре язылмаган, Коръәннең алдагы сүрәләреннән булган «Бәкара» сүрәсенең беренче аятьләре китерелмәгән, «Фатиха» сүрәсеннән соң «Ясин» сүрәсе килгән. Мәһҗан Шәфигуллин коллекциясеннән XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башына караган тулы текстлы ике нөсхәнең берсе Институтка 1974 елда Ш. Мәрҗани мәчетеннән кабул итеп алынган (39 нчы фонд, сакл. бер. 377). Бу кулъязмада икенче *җүздән* соң килә торган һәрбер *җүзнең* башы караңгы кызыл, сирәгрәк, җирән төстәге ноктапар белән аерымланган.

Икенче нөсхәне (39 нчы фонд, сакл. бер. 2044) 1978 елда Институт тарафыннан оештырылган археографик экспедиция вакытында Бөгелмә шәһәре мәчетеннән алып кайтканнар. Сыйфатлы *нәсех* язуы белән башкарылган бу нөсхәдә Коръән тексты кара һәм кызыл төсләрдән торган, алтын йөгертелгән өч кат сызыклы кысага алынган. «Фатиха» һәм «Бәкара» сүрәләре язылган битләрнең беренче ягы орнамент белән һәм алтын йөгертеп бизәлгән. *Тәсмия* кысага алынган, ә сүрәнең исеме бөтенләй башка кеше кулы белән тиз язу ысулын

[1] Мавәраэннәһер дигәндә классик кабул ителгән, ике елга арасына караганда киңрәк территорияләр – Һиндстанның төньягын һәм Әфганстанны да кертеп, мөселман Урта һәм Үзәк Азия территорияләре күздә тотыла.

кулланып язылган, кысасыз гына бирелгән. Шул рәвешчә, нөсхәне төзү эшендә берничә кеше катнашканлыгы ачыклана. *Басмәлә* өчен кысаның фоны берничә вариантта бирелгән: алтынланган үрнәген дә күрергә мөмкин яисә алтынсу төстәге кара белән геометрик бизәкләр (вак ромблардан гыйбарәт челтәр) ясалганы һ.б. бар. Шунысы да мөһим: сүрәнең исеменә, гадәттә, сүрә исеме генә түгел, ул иңгән урын, аятьләр саны да керә. Кайбер кульязмаларда исемнең бирелеше киңәйтелә: сүрәдәге сүз, хәреф, рәкәгать саны да куела. Бу нөсхәдәге кыса өстендә кызыл кара белән язылган сүрә исемнәре тезмәсе дә гел үзгәреп тора. Иң киң бирелгән сүрә исемнәреннән берсе түбәндәгечә: *«“Ганкәбут” сүрәсе, туксан тугыз*[1] *аятьтән тора. Мәккәдә иңгән сүрә. 4157 хәрефтән, 1780 сүздән тора. Сүрәдә 6 әгъшар* (унынчы өлеш), *7 рәкәгать. Аның башы “Рум” сүрәсеннән соң иңгән...?». Җүз* башланып китә торган аятьнең фоны яшькелт төстәге челтәр сызыклардан гыйбарәт. Кульязма битендә текст кысасы периметры буйлап, алтынсу карадан зыян күргән урыннар бар.

ЯМУ тупланмаларындагы XIX гасырга караган калган ике нөсхә тулы түгел. Аларның берсе (39 фонд, сакл. бер. 2234; Коръән тексты – 2:74–68:17) 1973 елгы археографик экспедиция вакытында Пермь өлкәсендә табылган; ул башкаларыннан бераз зуррак булуы белән аерылып тора (*бит* үлчәме – 30×16,5 см). Икенче нөсхәнең (39 фонд, сакл. бер. 2234) фондка ничек килеп керүе хакында мәгълүмат юк, үлчәме – 16,5×10,5 см.

Әлеге кульязмалар барысы да ярым үтә күренмәле Урта Азия кәгазенә язылганнар, алар форматы, каллиграфиясе һәм Коръәннең бүләк итеп бирергә дип әзерләнгән затлы нөсхәләре бизәлешеннән күпкә кайтышрак булсалар да, үзләренә генә хас сәнгатьчә бизәлешләре белән аерылып торалар. Аларның тулы тасвирламасы Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 2022 елда дөнья күргән Коръән каталогында [Гараева, 2023, с. 12–45] бирелде.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә сакланган 42 Коръәннең икесе (сакл. бер. 854г, 709г) – Урта Азия нөсхәләре, әмма аларның икесендә дә югалган битләр күп. Берсендә[2] *тәсмия* гадәти итеп язылмаган: *басмәләдә,* гадәттә, *син* хәрефенең соңгы өле-

---

[1] Кульязмада аятьләрнең саны хаталы күрсәтелгән. 29 нчы «Ганкәбут» сүрәсендә 69 аять. Күчерүче ялгышкан да булырга мөмкин.

Коръән аятьләренең саны, тәртибе турында күп гасырларга сузылган бәхәсләр бүген дә дәвам итә. Ләкин, шунысы мөһим, 1928 елда Каһирәдә Коръәннең иң борынгы күчермәләренә нигезләнеп төзелгән басмасы дөнья күрә. Мөселман галимнәре бер фикергә килеп, басмада аять номерлары куела. Белгечләр тарафыннан алга таба Коръән аятьләренең тәртибе өйрәнелгәндә дә аларның номерларын үзгәртмәү турында карар кабул ителә.

[2] Кульязма археографик экспедиция вакытында Абитова Нурҗиһан Хәлил кызыннан (1946 елгы, Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районы Яңа Земница авылы) кабул итеп алынган. Параметрлары: бит – 14,5×25,2 см; текст – 9×17,5 см; киңлеге – 4,5 см; һәр биттә 13 юл.

ше сузылып языла торган булса, бу нөсхәдә исә «*әр-рәхман»* сүзендә *хә* хәрефе ярты битне алып тора (ТР МК, сакл. бер. 709г). Пөхтә нәсех язулы нөсхәдә кайбер сүрәләрнең исемнәре төшеп калган, ә сары-кызыл кара белән язылганнары кайвакыт исемендә китерелгән мәгълүмат белән аерыла. Аятьләрнең кайда иңгәнлеген һәм санын гадәти искә алып китү урынына кайбер сүрәләрдә исем бик нык киңәйтелгән. Мәсәлән, *«Сүрә Йуныс, Аллаһының сәламе барып ирешсен! Йөз дә тугыз аять. Мәккә сүрәсе. 5567 хәрефтән тора. 1832 сүздән тора. 15 әгъшар* (уннан бер өлеш?) *һәм тугыз аять. 11 рөкүгъ*».

Саннар хакындагы мәгълүматның бизәлеше билгеле бер кагыйдәләргә буйсынган: бары тик аятьләрнең күләмен күрсәткәндә генә саннар сүз белән язылган, калган статистика гарәп саннары белән бирелгән, кара төстәге кара белән язылган. Битнең буш калган кырыйларында *җүз* структур билгесеннән тыш, *сәбгә* (җиденче өлеш) һәм аның яртысы күрсәтелгән.

Милли китапханә тупланмасындагы Коръән тексты язылган икенче кулъязма (сакл. бер. 859г) нибары 61 кәгазьдән гыйбарәт[1]. Шуны искәртик: бу кулъязмада поляларда *җүз* һәм аның яртысын күрсәткән бүленеш билгеләреннән кала һәр ун аять артыннан куелган *гошер* маркерлары да бар.

Казан федераль университеты Фәнни китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Коръәннең 27 нөсхәсе саклана. Әмма чынлыкта, коллекцияләрнең әлегә ябык, эшкәртелә торган тупланмаларын да исәпкә алганда, бу сан, һичшиксез, күбрәк, алар хакында мәгълүматлар кулланылышка чыгарылган каталогка кертелмәгән. 27 нөсхәнең дүртесе – Урта Азиядән кайтартылган. Шуларның өчесе – тулы текстлы күчермәләр (КФУ ЛФК КСКБ, сакл. бер. 719ар, 431ар, 3101ар), ә безнең көннәргә кайбер югалтулар белән килеп җиткән дүртенчесендә (КФУ ЛФК КСКБ, сакл. бер. 2718ар) Коръәннең яртысыннан күбрәк өлеше теркәлгән. Бу нөсхәдәге «Маидә» (5 нче), «Йуныс» (10 нчы) һәм «Исра» (17 нче) сүрәләре текстларының башлам өлеше алтынсу төс белән бизәп, затлы итеп эшләнгән. Бит башындагы орнаментларда сүрә исемнәре язылмаган, әмма бизәлеш җәһәтеннән алар бик үзенчәлекле. Кулъязмада Коръән тексты тулаем яхшы каллиграфик язу белән башкарылган, һәр биттәге текст алтын төстәге кысага алынган, аятьләрне аерып торган билгеләр шулай ук алтынсу төстә, алтын төстәге кара белән китап бите кырында *сәҗдә* урыннары һәм текстның структур бүленеше күрсәтеп барылган. Китаби блокны кабат төпләгән вакытта (Россиядә төпләнгән булуы ихтимал) бизәлгән битләр арасына мамык (микалент) яки папирос кәгазе куеп эшләгәнгә охшый. Китапның киселеше дә алтынсу төс белән капланган.

Кечкенә форматлы (битнең 1/8 өлеше) нөсхәнең тулы текстлы атрибуциясе бераз шик тудыра (КФУ ЛФК КСКБ, сакл. бер. 3101ар).

---

[1] Параметрлары: бит – 15,5×21,1 см; текст кысасы – 10,6×16,2 см; кыр киңлеге – 2,7 см; биттә 15 юл.

Әлеге нөсхә яшел төскә буялган яхшы сыйфатлы күн белән тышланган, каптырмасы да бар. Кулъязмада Урта Азия кәгазе өчен характерлы булмаган кәгазь кулланылган, шулай ук Коръән текстының *хизеб* дигән өлешләргә (алтмыштан бер өлеш) бүленгәнлеге дә Урта Азия кулъязмаларына хас түгел. Юл араларында *тәҗвид* кагыйдәләренең бик күп булуы – Урта Азия нөсхәләре өчен типик күренеш, кабул ителгән атрибуция файдасына сөйли. Коръән текстын күчереп язуда татар нөсхәләренең дә шул ук традициягә таянып эшләнүе билгеле. Кулъязма, күрәсең, бизәлергә тиеш булып, ни сәбәпледер, бу эш башкарылмаган.

Текст Коръән өчен гадәти булган кысаларсыз гына бирелгән, беренче сүрәләрдә өстә буш калган урыннар да декорсыз. Кулъязманың Европа төпләнмәләрендә (алар Казанда ясалган булырга да мөмкин) форзац өчен – мәрмәр кәгазь, ә өстәмә форзац бите өчен саргылтяшел чәчәкләр рәсеме төшкән ачык төстәге декоратив кәгазь кулланылган. Коръән текстының яңа төпләнмәсенә соңрак сүрәләр башланган бит күрсәтелгән саннар язылган фихрист өстәлгән.

1930 елда Казан университеты коллекциясенә мөфти Галимҗан Баруди (1857–1921)[1] китапханәсеннән Коръәннең соңрак чорга карый торган тулы текстлы нөсхәсе кергән. Кулъязмада өч урында классик декоратив бизәлеш кулланылган: текст башында, «Исра» сүрәсе башында һәм Коръәннең ахыргы сүрәләре битендә. Текст кысасындагы бизәкнең график схемасы өч урында да бер үк. Каймалап алган бизәк үзәгенең элементлары исә бер-берсеннән аерыла. Китап эчендәге ике битне берләштерә торган кәгазьгә үзгә бизәк төшерелгән: уртада алтынсу фонда бите күрсәтелгән текстлар урнашкан, алар үсемлек орнаментлы тар турыпочмаклы кысага алынган. Текстлы битләр фигураның уртасында, алар сигез таҗлы хәрефне хәтерләтеп торалар; зәңгәр фондагы таҗларның очы алтынсу төстәге дуга формалы бизәк белән каймаланган һәм болар барысы композицияне тәэсирле итә.

Сүрәләрнең исеме алтын фонга ак төс белән язылган. Текстның беренче, җиденче һәм соңгы юлын артык ачык булмаган яшел төс тә бизәп тора. Бер биттә, гадәттә, 13 юл, әмма китаби блок ахырына биттәге юллар саны кими. Бу кулъязманың цифрлы копиясе КФУ Фәнни китапаханәсе сайтына урнаштырылган: https://repo.kpfu.ru/jspui/handle/net/21456.

Казан университетының Фәнни китапханәсендә игътибарны үзенең зурлыгы белән җәлеп итә торган тагын бер Коръән нөсхәсе[2] бар. Ул шулай ук Галимҗан Баруди тарафыннан кайтартылган була. Кулъязма бик күп зыян күргән, күп битләре коелган, югалган. Аны Казанда реставрацияләгәннәр, күк төстәге кәгазьдә кабат торгызганнар. Ертылган урыннарын ныгыткан вакытта һәм төпләмне яңартканда

[1] Татар галиме, «әд-Дин вә әл-әдәб» журналының нашире, Үзәк Диния нәзарәте мөфтие.

[2] Үлчәмнәре буенча кулъязмалар бер зурлыкта (КФУ ЛФК КСКБ, сакл. бер. 431ар һәм ТР ММ, сакл. бер. КП-106026/а).

китаби блок читләре бик нык киселгән, хәтта кайвакыт текст кысага терәлеп үк тора. Кәгазьне ямап, ертык урыннарны кискәндә текстнең бик күп структур һәм сәҗдә-рөкүгъ билгеләре югалган. Сакланып калган өлешләре буенча нөсхәнең бизәлешендә төрле төстәге орнаментларны күрергә мөмкин, һәр *җүздән* соң аять фрагментларының алтынга охшаган кара белән аерымланганлыгын чамаларга була. Аятьләрнең бу өлешендәге сүзләр алтынсу кара белән бик нәзек итеп язылган, аннан кара кара белән әйләндереп алынган. Сүрәләрнең исеме кысалап бирелгән. *Аллаһ* сүзе бөтен урында кызыл кара белән язылган. Нөсхәнең кабат торгызылган өлешенең каллиграфиясе оригиналь язу белән чагышмый. Кулъязманың элекке текстында юл араларында Коръән сүзләренең фарсыча аңлатмалары бирелә, ә яңартылган өлешендә әлеге алым кабатланмый. Гадәти булмаган язуы гарәп каллиграфиясе кагыйдәләренә буйсынмый. Китаби блокның үлчәме, бизәлеше һәм күчерүченең почеркы буенча Коръәннең Татарстан Республикасы Милли музеенда сакланган һинд-әфган нөсхәләре арасында шактый охшашлык табарга мөмкин.

Татарстан Республикасы Милли музеенда Коръәннең өч нөсхәсе исәптә тора. Аларның икесе – Мавәраэннәһер кулъязмалары – Коръәннең Казандагы кулъязмалары арасында иң матур һәм иң кызыклыларыннан санала.

Боларның берсе (ТР ММ, сакл. бер. КП-115397) – XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башында күчерелгән кулъязма, аны музейга 1951 елда мәшһүр китап сөюче һәм сирәк китаплар җыючы Александр Модестович фон Вилькенның (1874–1934) хатыны Вера Петровна Вилькен бүләк иткән. Коръән тексты классик стильдәге сәнгати бизәлештә бирелгән. Кулъязманың бераз бозылган урыннары да булган, ул 1980 елларда Мәскәүдә академик И.Э. Грабарь исемендәге Бөтенроссия сәнгать фәнни-реставрация үзәгендә яңартылган. Ләкин реставрация вакытында кайбер декор билгеләре һәм текстның фоны тулысынча торгызылмаган. Тәүге сүрә һәм «Бәкара» сүрәсе текстының алгы өлешендәге бизәге, мәсәлән, беренчел рәвешеннән күп үзгәргән. Текст укылса да, орнамент өлеше дымнан зыян күргән. Беренче сүрәләрнең исемнәре бу нөсхәдә үсемлек орнаменты белән кысаланган. Беренче «Фатиха» сүрәсе тулысынча китап эчендәге ике битне алып тора. Текст кысасы эчке яктагы фигуралы медальоннар белән өч өлешкә бүленгән. Югары бүлемнәрдә уң яктан – «Фатиха» сүрәсенең исеме, сулда иңгән урыны һәм аятьләр саны китерелгән; үзәктәге эре секция-медальоннарда унда – «иййәәкә нәгбүдү вә иййәәкә» (1:5) дип бетә торган беренче аятьләр; сулда – сүрәнең калган 5–7 нче аятьләре. Аскы бүлемдәге медальоннарда 56 нчы «Вакыйга» сүрәсенең 79–80 нче аятьләре язылган, унда – «ләә йәмәссүһү илләл-мүтаһһәрүүн» («Аңа чистарынганнарның гына кагылырга хакы бар») (56:79), сулда – «тәнзиилүм мир-рабби-л-гәәләмиин» («Ул дөньялар хакиме тарафыннан иңдерелгән») (56:80). «Бәкара» сүрәсе беренче ике биттән соң башланып китә. Уң як биттә беренче тугыз

аять урнашкан[1]. Сүрә исеме бай бизәлгән декоратив гонван астындагы кысага куелган. Калган сүрә исемнәренең кысалары шактый таррак, үлчәме кечерәк. Исем кую өчен калдырылган урынның фоны нечкә каләм белән юка гына итеп төшерелгән төрле төстәге үсемлек орнаментыннан гыйбарәт. Әлеге фонда сүрә исемнәре ак кара белән язылган. Аятьләрне бер-берсеннән алтын төстәге алты таҗлы эре бизәк аерып тора. Кайвакыт шундый ук бизәк биш я ун аять саен текст бирелгән кыса тышындагы кырда да ясалган. *Басмәлә* бер юлга сузып язылган, *син* хәрефенең «койрык өлеше» юлның дүрттән өч өлешен биләп тора. Коръәннең азагында, *басмәләдән* соң, текстсыз гына тагын бер горизонталь кыса китерелгән. Мондый ысул текстның төрле өлешләрендә, күрәсең, бушлыкны каплап тору өчен кулланылган. «Нас» сүрәсе бизәлешендә игътибарны өстәмә декор җәлеп итә. Анда сүрәнең соңгы сүзе аерым кысага алынган. 114 нче сүрәдән соң, Коръәнне укып бетергәч кылынырга тиешле доганың исеме китерелә. Тексты исә алдагы биттән башланып, ул үзенең бизәлеше белән Коръән тексты бизәлешеннән нәфислеге, затлырак булуы белән аерылып тора.

ТР Милли музее (сакл. бер. КП-106026/а) тупланмасындагы икенче кулъязма да бик кызыклы. Аның кайдан керүе хакында мәгълүмат юк. Якынча, XVIII–XIX гасырлар нөсхәсе дип билгеләнә. Аксыл-көрән төстәге кәгазьнең сыйфатына караганда, ул Төньяк Һиндстан һәм Әфганстаннан килгән булырга тиеш. Кулъязманың югалган битләре, ертылган урыннары XIX гасырда Урта Азиядә реставрацияләнгән. Тышлыгын Казанда китап төпләүче Сәххәф Мөхәммәдгали Болгари (1839) яңарткан. Реставрация вакытында, бәлки Урта Азиядә үк, кулъязманың китаби блогы, 7,6–7,8 см калдырып, бераз киселгән. Шул вакытта кулъязма читендәге декоратив бизәлгән медальоннар да (шәмсияләр) кыскартылган, киселгән. Моннан чыгып, кулъязманың оригиналында кыр киңлеге 2–2,5 см га артыграк, текст кырыенда калдырылган урын 10 см тирәсе булган, дип фикер йөртергә нигез бар. Югалган битләр ярым үтә күренмәле Сәмәркәнд кәгазе белән алыштырылган (1–5, 193, 391–395 битләр), текст гадәти каллиграфик нәсех белән бирелгән, ул кулъязманың оригиналь язуыннан бик нык аерылып тора. Кулъязма үзенең үлчәме[2] һәм күләме[3] белән үзенчәлекле. Игътибарны иң нык җәлеп иткәне – аның декоратив бизәлеше һәм язу рәвеше. Хәрефләрнең горизонталь күренеше киң итеп, ә вертикаль өлеше бик нәзек *нәсех* белән язылган. *Фәтхә, кәс-*

---

[1] Кулъязмаларның алдагы ике битендә гадәттә Коръәннең беренче ике сүрәсе языла: уң якта – «Фатиха» сүрәсе, сулда «Бәкара» сүрәсенең беренче биш аяте китерелә. Кайбер кулъязмаларда дүрт аять бирү очраклары бар. Коръәннең элгәреге Казан басмаларында да дүрт аять урын ала.

[2] ТР ММ, сакл. бер. КП-106026/а. Параметрлары: тышлыгы – 30,5×42,5 см; төпләнмәсе – 8 см; китап блогы төпләмәсенең калынлыгы – 4 см; бите – 30,5×41,8 см; текст кысасы – 20,5×29,3 см.

[3] ТР ММ, сакл. бер. КП-106026/а. Параметрлары: китап блогы төпләмәсендә барлыгы 398 б.; Коръән тексты – Б. 1б–395а.

*рә, даммә, сөкүн, тәшдид, сыйлә* билгеләрен кара төстәге нәзек каурый белән гадәти булмаган озынча формада язганнар. Кулъязманың оригиналь өлешендә текст кысаланган, кысасы төсле каралар белән сызылган, сулдан уңга – зәңгәр-шәмәхә, җирән, кара, алтын, яшел сызыклар. Коръән кулъязмаларында сүрә исемен кысага алу еш очрый. Бу нөсхәдә исә, сүрәнең исеме кысага алынмыйча, кызыл кара белән алдагы сүрәнең соңгы сүзләре белән бер юлда язылып киткән.

Югарыда күрсәтеп узганча, сүрә исеме тезмәсендә аның иңгән урыны һәм аятьләр саны китерелгән. Шунысы да күзгә ташлана: Коръән текстын башкарган останың кулы белән чагыштырганда, сүрә исеме каллиграфик яктан йомшаграк башкарылган. Гадәттә, *тәсмия* (икенче сүз белән әйткәндә б*асмәлә)* һәм *җүз* башындагы аять кысага алына. *Басмәлә* кысасы өч тигез өлештән тора, кысаның уң һәм сул яклары вак чәчәк орнаментлы; *басмәлә* үзе урта өлештә кара кара белән китерелә. *Син* хәрефенең «койрык өлеше» 1 см га озынрак*,* тезмәдәге *Аллаһ* сүзе кызыл кара белән *би-сми* сүзендәге *мим* хәрефе өстендә бирелгән. *Җүз*ләр башындагы аятьләр кысасы *басмәлә* кысасы кебек өч өлешкә бүленгән: уң һәм сул яклардагы өлешләр уртадагысыннан кечерәк һәм төрле төстәге вак чәчәк орнаменты белән бизәлгән. Уртада кызыл кара белән язылган аять тексты урнашкан.

*Тәсмия* һәм *җүз* башы аятьләре кысалары кулъязма читендә дәвам ителеп, зур чәчәк бутоны кебек, төсле-төсле декоратив медальон белән тәмамлана. Медальоннарның кайбер өлешләренә алтын йөгертелгән. Күп медальоннарның уртасына *сәҗдә* яки ع *рөкүгъ* кылу билгесе төшерелгән.

Сүрәнең башы белән *җүз* башы туры килгән очракта кыса икеләтелгән: беренчесендә *басмәлә* билгесе булса, икенчесендә сүрә аяте язылган була. Мәсәлән, 46 нчы «Әхкаф» сүрәсе, 58 нче «Мүҗадәлә», 67 нче «Мүлк» һ.б. шундый тәртиптә күчерелгән.

Коръән текстында сүрә исемнәреннән, тәҗвид кагыйдәләре билгеләреннән, *җүз* башларыннан тыш, *Аллаһ* сүзенең кызыл кара белән язылуы күзгә ташлана. Шулай ук *Ибраһим, Адәм, Муса, Исхак, Гайсә* пәйгәмбәрләр, *Мәрьям Ана* исемнәре дә кызыл кара белән аерымланган. Кулъязманың кырыйларында Коръән текстына ияреп килә торган структур (*җүз, нисыф, рубгъ*), һәм уку (сирәк куела торган тәҗвид билгеләре), һәм гыйбадәт кылу тәртибе билгеләре (*сәҗдә, рөкүгъ*) тиешле конфигурацияле картуш эченә язылган. Текст читендә ачык төстәге турыпочмаклы яки квадрат орнаментта *вәкыф мәнзил* (Коръәннең җидедән бер өлеше) билгеләре күрсәтелә барган (кулъязманың тулы тасвирламасы: [Гараева, 2022, с. 189–194]).

«Казан Кремле» музей-тыюлыгы фондларында Коръәннең барлыгы өч нөсхәсе саклана, берсенең караханилар (IX–XIII гасыр башы) чорына караганлыгы ачыкланды.

Казан университеты тупланмасындагы Коръән нөсхәсе (сакл. бер. 719ар) – Мавәраэннәһердән кайткан тулы текстлы ун Коръән

арасында иң камиле һәм оригиналь эшләнеше тулысынча саклангаты дип әйтергә мөмкин. Милли музей тупланмаларының икесе дә, реставрацияләнгән булуларына карамастан, шулай ук әһәмиятле саналалар. Һинд-әфган традицияләрен саклап, бизәп төзелгән кулъязманы (сакл. бер. КП-106026/а) Казан университеты кулъязмасы (КФУ ЛФК КСКБ, сакл. бер. 431ар) белән янәшә куярга мөмкин, күләме белән алар икесе дә зур Коръәннәрдән санала.

Мавәраэннәһердән кайткан кулъязма Коръәннәрнең күбесе, бигрәк тә кечерәк форматтагылары, татарлар арасында аеруча популяр булган. Кагыйдә буларак, Коръән битенең чит-читләренә өстәмә билгеләр ясалган. Кайвакыт андый өстәмәләр кызыл кара кулланып, каллиграфик язу белән бирелгән. Өстәмәләрнең бер өлеше Коръәннең Казан басмасын кабатлый.

Казан фәнни үзәкләре фондларында саклана торган Коръән нөсхәләренә ясаган күзәтүебезгә өстәп, шуны әйтергә кирәк: мондый эзләнүләрнең потенциалы бик зур, әле алга таба да ачыклыклар, төгәллекләр күп кертелер. Урта Азия һәм татар кулъязмаларында кулланылган *тәҗвид* кагыйдәләренең билгеләрен аерым өйрәнү таләп итела. Коръәннең Урта Азия һәм татар нөсхәләрендә утыздан артык *тәҗвид* билгесе аерымланган, ә күп кенә билгеләрнең мәгънәсе, Е.А. Резван искәрткәнчә [Резван, с. 478], я онытылган, я аңлашылып бетми.

Гомумән, Казан фәнни үзәкләре фондларындагы Мавәраэннәһердән кайткан Коръән нөсхәләре – мөселман дөньясында һәм Россия империясе чикләрендә барган китап алмашының бары бер генә ягы. Алар мөселман классификациясенә нигезләнгән гыйлемнәрнең киң спектрын чагылдыра, Идел буе һәм Үзәк Азия мөселманнарының мәдәни багланышлары хакында сөйлиләр.

**Әдәбият**

*Васильева О.В*. Нить жемчуга: Иранское книжное искусство XIV–XVII веков в собрании Российской национальной библиотеки. СПб.: Изд-во «Российская национальная библиотека», 2008. 131 с.

*Гараева Н.Г.* Татарская рукописная традиция: Кораны в собрании ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Каталог. Казань: ИЯЛИ, 2022. 224 с.

*Гараева Н.Г.* Грани мусульманской книжности Казани. Каталог // Памятники исламской культуры в собрании Национального музея Республики Татарстан. Казань: Заман, 2023. С. 12–45.

*Гилязутдинов С.М.* Описание рукописей Корана из хранилища Центра письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ. Казань, 2013. 92 с.

*Ласикова Г.* Мусульманская рукописная книга от переплёта до колофона. URL: http://mardjanifoundation.tilda.ws/muslimhandwrittenbook?fbclid=IwAR2_ug4s0KEskBjbEMYewACsxdMjw-Je3VVMub5ET1HL5yP_v8aiyJ7WTNw (Время обращения: 10.11.2023.)

*Резван Е.А.* Коран и коранистика в России // Ислам. Историографические очерки. М.: Наука, 1991. С. 15.

*Резван Е.А.* Коран и его мир. СПб.: Петербургское востоковедение, 2001. 608 с.: 1 л. ил.

*Саламех Х.* Манускрипты Корана в исламском музее ал-Харам аш-Шариф в Иерусалиме. М.: ИД «Магистр-Пресс», 2004. 206 с.

*Ястребова О.М.* Особенности художественного оформления списков Корана. Режим доступа: https://expositions.nlr.ru/ve/RA3999/rukopisnye-korany-oformlenie

The Qur'an and Callifraphy. A Selection of Fine Manuscript Materials. London: Bernard Quaritch. Catalogue 1213. 145 p.

Islamic manuscripts. Leaves. Islamic manuscripts. Texts. London: Bernard Quaritch. Catalogue 1366.

*Stoilova A., Ivanova Z.* The Holy Qur'an through the Ctnturies. A Catalogue of the Exhibition of Manuscripts and Printed Editions preserved in the SS Cyril and Methodius National Librar. Sofia, February 1995. 64 p.

Handlist of Manuscripts in the Library of Makkah al-Mukarramah. Qur'an & Qur'an sciences. Prepared by Muhammad al-Habib al-Hilah. London: al-Furqan Islamic Heritage Foundation, 1994. – 145 pp. (на араб. яз).

***Гәрәева Нурия Габделәхәт кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*Гали Рәхим*

## «ДИМ БУЕНДА»

В ноябре отмечается день рождения Гали Рахима – одного из талантливейших людей, оставивших глубокий след в истории татарской литературной и научной арены. В связи с этим на страницах журнала представляется его критическая статья, опубликованная в 1915 году в газете «Ил» от 8 марта «Дим буенда» («На берегах Дёмы»). В ней речь идёт о романтической повести писателя, прозаика, переводчика, публициста Садри Джалала (Садрислам Хайрутдинович Валидов, 1891–1943) «Дим буенда» («На берегах Дёмы»), опубликованной на страницах журнала «Анг» в 1914 году. Произведение, показывающее любовь между героями Фаридой и Рустамом, через призму которой указывается исчезновение рода знатных мурз XIX века, подверглось жесткой критике Г. Рахима. Критик относит повесть к разряду «чопорных произведений», отмечая, что у писателя нет надежды на то, что в литературе удастся создать достоверное и неповторимое произведение.

**Ключевые слова:** Гали Рахим, Садри Джалал, татарская литература, периодика, критика.

In November, the birthday of Gali Rahim is celebrated – he was one of the most talented people who left a deep mark in the history of the Tatar literary and scientific arena. In this regard, his critical article, published in 1915 in the newspaper «Il» from March 8 «Dim buenda» («On the banks of the Dema»). The article is about the romantic story of the writer, novelist, translator, publicist Sadri Jalal (Sadrislam Khairutdinovich Validov, 1891–1943) «Dim Buenda» («On the banks of the Dema»), published on the pages of the magazine «Ang» in 1914. The work shows the ideal love between the heroes Farida and Rustam, through the prism of which the disappearance of the noble Murz family of the XIX century is indicated, was severely criticized by G. Rahim. The critic refers the story to the category of «prim works», noting that the writer has no hope that it will be possible to create a reliable and unique work in literature.

**Keywords:** Gali Rahim, Sadri Jalal, Tatar literature, periodicals, criticism.

*Ноябрь аенда татар әдәбияты, фәне мәйданында тирән эз калдырган талантлы шәхесләребезнең берсе Гали Рәхимнең туган көне. Шул уңайдан журнал битләрендә аның 1915 елда «Ил» газетасының 8 март санында «Дим буенда» исеме белән басылган тәнкыйть мәкаләсе тәкъдим ителә.*

*Мәкаләдә сүз язучы, прозаик, тәрҗемәче, публицист Садри Җәләлнең (Садрислам Хәйретдин улы Вәлидов, 1891–1943) 1914 елда «Аң» журналы битләрендә басылган «Дим буенда» романтик повесте хакында бара. Эчтәлеге буенча геройлары Фәридә белән Рөстәм арасындагы идеаль мәхәббәтне, шуңа бәйләп XIX йөз затлы морзалар нәселенең юкка чыга баруын күрсәткән әсәр Г. Рәхимнең көчле тәнкыйтенә очрый. Тәнкыйтьче повестьны «чиле-пешле әсәрләр» рәтенә кертә, иҗатындагы табигый сәләтен шик астына ала. Язмасында галимнең романтизм, реализм кебек иҗат ысулларына карата мөнәсәбәте дә чагыла.*

*Әдәби тәнкыйтьтә бәхәсләр кузгатса да, әсәр соңрак киң җәмәгатьчелек тарафыннан җылы кабул ителә. Сәхнәләштерелеп, Татар дәүләт драма театрында (1925–1926), повесть мотивлары буенча композитор*

*Х. Вәлиуллин, драматург Х. Вахит язган опера М. Җәлил исемендәге театрда уйнала (1965–1966). 20–30 нчы еллар әдәби процессын өйрәнгәндә әсәр лирик-психологик әсәрләр рәтенә кертелә һәм күзәтү төсендә бәяләнә.*

Әдәбият – бер галәм, бер дөнья. Дөньяда бик күп кешеләр яшәп, дөньяда торган вакытларында азмы-күпме эшләп, азмы-күпме хезмәт итеп, аннан соң үлеп юк булып китәләр. Үзләре дә, исемнәре дә, эшләгән эшләре дә бер дә булмаган шикелле онытылалар. Арада гомум арасыннан аерылып, аерата бер истигъдад[1] күрсәткән бик аз гына кешеләр онытылмыйлар, эшләгән эшләре дә онытылмый, мәңгегә халык күңелендә аларның сурәтләре сызылып кала.

Әдәбиятта да шулай. Бик күп әдәби әсәрләр дөньяга чыга, китап базарына ыргытыла; вакытында аларны укучылар да табыла. Ләкин заманнар узуы белән шул бик күп әсәрләр арасыннан кайберләре генә онытылмаенча әдәбиятның «могалләкаты сәбга»сына *(исламгача мәшһүр гарәп шагыйрьләренең Мәккәдәге гыйбадәт йорты стенасына – Кәгъбәгә асып куелган сайланма җиде шигыре)* теркәлеп калалар. Алар яңадан-яңа җитешеп торган буыннар тарафыннан укылалар, язучылары да «милли әдипләр» фиһристенә[2] тезелә баралар.

Һәр халыкның әдәбият тарихында шундый исемнәре онытылган йөзләп язучылар һәм шагыйрьләр табыла. Безнең дә шул 25–30 еллык тарих дип әйтергә дә көлке булган әдәбият тарихыбызда да инде шактый гына шундый ташланган, онытылган әдипләрне таба алабыз. Без, бу заман кешеләре, үзебез шул әдәбият белән бергә үскәнгә, аларны беләбез, хәтта санап та күрсәтә алабыз. Ләкин бездән соң киләчәк буыннар өчен инде алар бөтенләй юк хөкемендә булачаклар.

Менә С. Җәләл әфәнденең «Аң»да басылганнан соң китап шәкелендә нәшер ителгән «Дим буенда» исемле романын да мин шул кыйсем әсәрләрдән дип әйтәсем килә.

Гадәттә бер әдипнең чын истигъдадка малик булып, эшләнеп килә торган «милли әдәбият» бинасына яңгыр җебетеп агызмаслык таза кирпечләр сала алырлыкмы, түгелме икәнлеге аның беренче әсәрләрендә үк билгеле була.

Мөәллифнең[3] күзгә күренерлек беренче әсәре булган бу романы аның әдәбиятыбызга төпле вә югалмый торган әсәрләр бирүенә өмидләндерми. Дөрестен генә әйткәндә, бу кешедә табигый булган әдәби истигъдад һәм көч сизелми.

Башка халыкларның әдәбиятында мондый әһәмияте аз булган әсәрләр бик күп чыгып тора. Алар китапны бары укырга бер әйбер булганга күрә генә укучылар тарафыннан укылалар. Җитди тәнкыйть андый әсәрләргә илтифат итми; чөнки алар, тиреслектә үсә торган эшкә яраксыз гөмбәләр шикелле, берсе артыннан берсе сансыз-хисапсыз чыгып

---

[1] Истигъдад – сәләтлелек.

[2] Фиһристенә – исемлегенә.

[3] Мөәллифнең – язучының.

торганга, игътибарга алып бетерергә дә мөмкин түгел. Чын кыйммәтле әсәрләр аңлы укучылар тарафыннан үзләре сайланалар.

Минем бу китапка зур бер мәкалә багышлавым исә, бердән, әле безнең әдәбиятта андый әсәрләрнең игътибарга алып бетермәслек күп булмавы, икенчедән, әле безнең яңа гына укырга өйрәнеп килә торган укучыларыбызның тәмйиз[1] куәте бик бала, бик җитлексез хәлдә булуыдыр.

«Дим буенда» безнең әдәбиятыбыз хәзинәсендә бер кыйммәткә малик була алырлык түгел. Бәгъзе бер урыннарында чибәр генә тасвирлары, кышкы матурлыклары белән укучыны кызыктырырлык булса да, төптән уйлап караганда, романның бер дә эшләнмәгән, ашыгыч язылган, кирәк өслүбе, кирәк күрсәтергә теләнгән типлары пешеп җитми, конспект хәлендә калган икәнлеге күренә. Романда кирәк татар тормышы, кирәк кешенең эчке, рухани тормышы өчен тулы һәм төпле материал табарга мөмкин түгел. Аның эчендә «менә бер хакыйкый, җанлы, этрафлы тасвир ителгән, дөрест татар тибы» дип әйтерлек бер тип табар хәл юк.

Романда аны башыннан ахырына кадәр бер ноктага җыя торган төпле бер фикер, бер идея дә юк. Әсәрнең сюжеты бик гади, һәрбер инсан җәмгыятендә булырга мөмкин булган, руслар тарафыннан общее место[2] атала торган нәрсәләрдән гыйбарәт. Романның каһарманы Рөстәм бала чакларыннан бирле бергә үскән Фәридә исемле бер кызга гашыйк була. Кыз да аны сөя. Ләкин язмышның шаяруы аларның арасына үзләренең рухани халәтләреннән килә торган кичәлмәслек киртә сала. Рөстәм Фәридәдән ераклаша. Икенче кызга, бер яһүди кызына өйләнә. Ләкин бәхетле була алмый, эченнән һаман Фәридәне сөя. Роман каһарманнарның бер-берсен аңлаша алмауларын, шуның белән газап чигүләрен тасвир итә; әсәр дә мәйданга чыгарылган бөтен гаиләнең, таралып бетеп, эзләре дә калмый, җир йөзеннән югалуы белән тәмам була.

Хисапсыз «иде»ләрдән котыла алмаудан куркып булырга кирәк, китап бөтенләй хәл сыйгасында[3] «берничә айлар узып китә. Рөстәм Мәскәүдә укып бетереп өйгә кайта... Ләкин күңеле һаман да карар тапмый...» дигән төсле җөмләләр белән язылган. Бу өслүбтә язу бездә яңа эш. Ләкин муаффәкыятьле[4] дип әйтеп булмый. Хосусан, роман өчен хәл сыйгасының бер дә килешмәве күзгә бәрелеп тора. Бу әлләнинди эшләнмәгән материал, план, конспект кына төсле тоела. Бигрәк тә романның күп урынында озын вакытлар эчендә булган эшләрнең берничә җөмлә белән генә сөйләнеп узылуы бу тәэсирне арттыра.

Романның эчпошыргыч җәһәтләреннән берсе – мөәллифнең үзенә охшаган бәгъзы бер җөмләләрне ике сүзнең берендә арага китереп кыстыруыдыр. Мондый тәкрарлардан иң күп очрый торганнары – «Рөстәмнең ямьсезрәк тавышы белән борын эченнән шыңшып йөрүе»

---

[1] Тәмйиз – аера белү.

[2] Кириллицада бирелгән.

[3] Сыйгасында – формасында.

[4] Муаффәкыятьле – уңышлы.

белән кучер Хисаминың «үтте ич рәхәт җәйләре!» дип җырлавы. Бу җөмләләрне китапта һәр өч битнең берендә диярлек очратырга мөмкин. Бәлки мөәллиф әфәнде бу җөмләләрдә бөтен романга аһәң (тон) бирә торган бер әһәмият һәм тәэсир таба торгандыр; ләкин бу чамадан тыш тәкрарлар бик көлке булып чыга, ачу китерә һәм укучыны ялыктыра, әсәргә бертөрлелек бирә. Бу –әлбәттә, әсәрнең хосусый кимчелекләреннән берсе. Эзләгәндә мондый җитешсезлекләрне күп табарга мөмкин. Бу турыда сүз озайтмыйк.

Әсәрнең бер күзгә чагылырлык ягы булса, ул да – аның романтизмга буялган булуыдыр. Каһарманнарның гомумнән югары тора торган аристократлар-мирзалар сыйныфыннан булуы, хикәянең башында «гөрләп торган» бер гаиләнең фаҗигалы рәвештә эзсез-нисез дөньядан югалып китүе, йортларының ташландык хәрабәләре генә калуы, төннәрдә шул хәрабәләрдә ишетелә торган шомлы «мәче башлы ябалак» тавышлары, әбиләрнең орчыкларын эрли-эрли балаларга шул хәрабә турысында әллә нинди куркынычлы экиятләр сөйләүләре, һәммәсе – романтизмнан туган хыяллар, романтизм тудырган сурәтләр.

Кеше үз гомерендә балалык һәм хыялга маил яшьлек дәверен уздырган шикелле, ахры һәрбер халыкның әдәбияты да романтизмда дәверен үткәрергә тиештер, дип күңелгә килә. Яурупа халыклары мәдәниятләре белән бергә үскән карт халыклар булганга, аларның әдәбиятында бу дәвер табигый рәвештә озын дәвер булып кичте. Рус әдәбияты да гомумән рус мәдәнияте шикелле бераз көчләнебрәк, ашыктырыбрак барлыкка китерелгәнгә, ул шул вакытта Яурупада хөкем сөргән әдәби формаларга куелды. Ул вакытта Яурупада романтизм дәверенең бетеп килгән заманнары иде. Рус әдәбияты кыска гына романтизм дәверен үткәргәннән соң, Яурупа әдәбияты белән бергә реализмга күчте.

Безнең әдәбиятыбыз туган вакытта әдипләребезнең алдында әзер булган реализм формалары бар иде. Яшь әдәбиятыбыз башлануы белән шул юлдан китте. Ләкин яшь мәдәниятле, яңа тормыш юлына чыккан яшь милләтнең күңеле романтизмга мәел итми кала алмый ахры. Хәзер дә, соңра калыбрак булса да, әдәбиятыбызда реализм белән бергә романтизм да баш күтәрде. Реалист Гаяз Исхакыйлар, Фатих Әмирханнар белән беррәттән, Галимҗан Ибраһимов татар романтизмына нигез корды. Галимҗан әфәнденең «Яшь йөрәкләр»е – шул нигезнең иң зур ташы, башка әсәрләре – ваграк ташларыдыр.

*Мәкалә «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасының 3.19 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

*Басмага әзерләде:*

***Хөснетдинова Гөлназ Азат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81'38

*Э.Х. Кадирова*

## ФӘНГӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР
## (тел галиме Илида Басыйр кызы Бәшированың юбилее уңаеннан)

Научные труды доктора филологических наук Илиды Басыровны Башировой посвящены исследованию проблем стилистики татарского языка, языка произведений художественной литературы, истории татарского письменного литературного языка, современной лексикологии, семасиологии татарского языка. В данной работе представим обзор исследований учёного в области истории татарского литературного языка. Научная деятельность И.Б. Башировой является наглядным примером истинного служения верно избранного ею направления в тюркологии – изучения истории татарского литературного языка.

**Ключевые слова:** Илида Басыровна Баширова, татарский язык, история литературного языка, семасиология, стилистика.

The scientific works of PhD Ilida Basyrovna Bashirova are devoted to the study of problems of stylistics of the Tatar language, the language of works of fiction, the history of the Tatar written literary language, modern lexicology, semasiology of the Tatar language. In this paper we present an overview of the scientist's research in the field of the history of the Tatar literary language. Scientific activity of I.B. Bashirova is a clear example of the true service of her correctly chosen direction in Turkology – the study of the history of the Tatar literary language.

**Keywords:** Tatar language, history of literary language, semasiology, stylistics.

Илида Басыйр кызы Бәширова 1938 елның 23 ноябрендә Оренбург өлкәсе Матвеевка районы Иске Әшер авылында укытучылар гаиләсендә туа. 1956 елда Оренбург өлкәсе Шарлык районы Яңа Муса авылында унъеллык урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар бүлегенә укырга керә. Университетны уңышлы тәмамлагач, И. Бәширова 1960–1963 елларда Куйбышев өлкәсе Камышлы районы Бакай авылында татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. 1963 елда зур конкурс үтеп, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантурасына кабул ителә, 1966 елдан Институтның тел белеме секторында кече фәнни хезмәткәр вазифасында эшкә калдырыла.

Билгеле булганча, XX гасырның 70 нче еллары ахырында татар әдәби теле, әдәбияты, сәнгате тарихын өйрәнү мәсьәләләре игътибар үзәгендә була. Бу елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты җитәкчелеге әлеге юнәлештә эшләүче яшь кадрлар әзерләү, туплау эше белән шөгыльләнә башлый. Бөтен төрки дөньяда танылган диалектолог Л.Т. Мәхмүтова җитәкчелегендәге Тел секторына Ф.Х. Хәкимҗанов, И.Б. Бәширова, М.И. Әхмәтҗа-

нов, Ф.Х. Хәкимҗанов, Я.С. Әхмәтгалиева (Янбаева), Ә.Х. Исхакова (Алиева), З.А. Хисамиева (Казыйханова), Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Вафина (Кадирова) һ.б. кебек яшь белгечләр бер-бер артлы аспирантурага, эшкә кабул ителә. Бүгенге көндә аларның барысы да диярлек үзенә тәгаенләнгән фән тармагында филология фәннәре кандидаты, докторлары буларак фәнни эшчәнлекләрен дәвам итәләр.

Әлеге галимнәр белән берлектә, филология фәннәре кандидаты (1971), докторы (2000), Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (2005), татар әдәби теле тарихы өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге бүләгенә лаек булган (2018) Илида Басыйр кызы Бәширова да аспирантура елларында башлаган юнәлештә – татар теленең стилистикасы өлкәсендәге фәнни-тикшеренү эшчәнлеген дәвам итә. Кандидатлык диссертациясен язганда фәнни җитәкчесе итеп билгеләнгән Хәлиф Рәхим улы Курбатов – шул вакытларда рус филологиясендә стилистика, тел стильләре, сөйләм стильләре, матур әдәбият стиле турындагы шау-шулы фикер алышуларга кушылып, тел стиле дигән күренешнең юклыгын, ә сөйләм стиле генә булуын раслап, академик В.В. Виноградов белән бәхәскә кергән, француз, инглиз, немец телләрен үзләштереп, шул юнәлештә беренче мәкаләләрне яза башлаган галим – үзенең беренче аспирантына да катгый таләп куя: И. Бәширова шул телләрдә язылган әдәбиятны укырга, аңларга һәм аспирантка бирелгән өч ел вакыт эчендә «Татар поэзиясендә сүз-сурәт» дигән темага кандидатлык диссертациясен язып, якларга тиеш була. Диссертация әзерләнеп, җитәкчегә тапшырыла, тикшерүдән соң яклауга куела. Бәяләүчеләр һәм оппонентлардан уңай рецензияләр алынып, хезмәт басмага тәкъдим ителә һәм «Сүз белән сурәт ясау» дигән монография дөнья күрә [Бәширова, 1974].

И. Бәширова 1967 елдан «Татар мәгърифәтче әдипләренең индивидуаль стиле» дигән яңа тема буенча тикшеренүләрен башлый. Автор тарафыннан йөз еллык тарихы булган сәнгатьчә татар прозасында, сюжетны алып баручы затның укучыга нинди мөнәсәбәттә куелуына карап, хикәяләүнең, «кеше сүзен сөйләп», кыйссаи әдәбият ысулында (К. Насыйри, Ә. Уразаев-Кормаши, Г. Фәизхан һ.б.); авторның аерым үзенчәлекләре белән үз исеменнән сөйләп, мәгърифәтчеләр ысулында (М. Акъегет, З. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, Ш. Мөхәммәдов, З. Һади һ.б.); төрки дөньяда классиклар буларак танылган әдипләр иҗатында, укучыны күз алдына бастыру максатыннан, сүзнең мәгънә эчтәлеген катлауландыру ысулында баруы ачыклана. Бу хакта «Герой. Стиль. Осталык» (1972), «Метод. Стиль. Жанр» (1976) һ.б. фәнни җыентыкларда галимәнең күләмле мәкаләләре басыла. Аның тикшеренүләренең бер өлеше «Сәнгатьле чәчмә әсәрләр теле. Татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире» (1979) исеме белән китап булып басыла, «Татар әдәбияты тарихы»ның икенче томында урын ала (1985). Хезмәткә рецензия язган

галимә Ф.С. Сафиуллина әлеге басманы барлык төрки әдәбият әсәрләрен тикшергәндә кулланма була ала, дип бәяли [Сафиуллина, 1980].

1981–1985 елларда И.Б. Бәширова «Сәнгатьле күзаллау һәм аның тәгъбирләнеше» темасы кысаларында, Г. Бәширов, Ә. Еники, М. Әмир, И. Гази, Ф. Хөсни, Г. Әпсәләмов, А. Расих, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, Н. Фәттах, Р. Төхфәтуллин, М. Юныс кебек танылган татар совет әдипләренең хикәяләү осталыгын, сәнгатьле сөйләмен өйрәнә, аерым авторлар белән фикер алышулар үткәрә. Фәнни-тикшеренү эшенең нәтиҗәләре күпсанлы мәкаләләрдә чагылыш таба. Алга таба ул олуг әдип Г. Бәшировның кулъязмаларын өйрәнеп, «Җидегән чишмә моңы» исемле хезмәтен бастыра (1995).

1986 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының эш планы буенча, «Татар әдәби теле тарихы» дигән мөһим тема ачыла. Институт директоры һәм тел гыйлеме бүлеге М.З. Зәкиев җитәкчелегендә, тел секторы хезмәткәрләре Х.Р. Курбатов, И.А. Абдуллиннар белән берлектә, И.Б. Бәширова да әлеге өлкәдә фәннитикшеренүләр алып барырга тиеш була. Әлеге эшчәнлек нигезендә И.Б. Бәшированың «Х1Х гасыр ахыры–ХХ йөз башы татар әдәби теле: исем категорияләре һәм фигыль наклоненияләрендә әдәби норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылык» дигән күләмле монографиясе басыла. Авторның хезмәттәше – филология фәннәре кандидаты Т.Х. Хәйретдинова «Хәзинәләр кайтаручы» дигән мәкаләсендә: «...XIX гасыр ахыры – XX йөз башында татар әдәби теленең барлык стильләрендә җиде меңгә якын татар китабы, татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә чыга торган газета-журнал битләрендә тормыш-көнкүрешнең төрле ягына караган мәкаләләр дөнья күрә. Тик ул хәзинә гарәп графикасында басылган, аны хәзер эзләп табарга, җентекләп өйрәнергә, фәнни яктан аңлатырга кирәк. Илида ханым менә шул эш белән мәшгуль», – дип язган иде [Хәйретдинова, 1998].

Филология фәннәре докторы Хуҗи Мәхмүтов китап басылып чыккач язган бәяләмәсендә хезмәтнең «XIX гасыр ахыры – XX йөз башында татар әдәби теле: табигате, вазифасы, чыганаклары, өйрәнелеше» дип башлануына игътибар итә: «Димәк, биредә проблеманың куелышы ук яңача һәм үзенчәлекле булып тора. Әдәби телебезнең табигатен билгеләү һәм вазифасын күзаллау мәсьәләләре моңа кадәрге хезмәтләрнең берсендә дә махсус рәвештә куелмаган иде шикелле. «...Әдәби тел» төшенчәсенең моңа кадәр аңлатылып һәм өйрәнелеп килгән булуына да бүгенге көн таләпләреннән чыгып объектив бәя бирелә», – дип, хезмәтнең яңалыгына басым ясый [Мәхмүтов, 2000]. Илдар Низамов: «Докторлык диссертациясенә торырлык китап», – дип белдерә [Низамов, 2000]. И.Б. Бәширова 2000 елда докторлык диссертациясен яклый. Әлеге хезмәтнең тулыландырылган икенче басмасы, «XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: жанр-стильләр, аерым грамматик категорияләрдә норма һәм вариантлылык» исеме белән дөнья күрә [Бәширова, 2008]. Хезмәт турында

фикер әйтүчеләр хаклы була. Чыннан да, И. Бәширова гарәп графикасындагы һәр истәлекне ныклап өйрәнеп, бу катлаулы чордагы татар әдәби теленең исем һәм фигыль сүз төркемнәренә караган грамматик категорияләрен җентекләп тикшерә, бер үк вакытта аларны бүгенге әдәби норма һәм җанлы сөйләмә формалар белән чагыштырып бара. И.Б. Бәширова күпсанлы язма чыганаклардан тупланган мисалларны анализлау барышында, өйрәнелә торган чордагы татар әдәби теле үзенең асыл табигате белән функциональ вазифасын үтәгәндә, күптөрле экстралингвистик факторларга бәйле булганы хәлдә, җанлы сөйләм төрләреннән аермалы буларак, төрле функциональ-стилистик вариантлылыкта хәрәкәт итә ала; телнең субстанциональ табигате исә, һәр тел тармагының эчке мөмкинлегенә бәйле булганы хәлдә, әдәби норма һәм шул норма вариантлыклары белән яшәештә була, дигән ныклы нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта, ул Б.А. Серебренниковның «Об основных отличиях истории строевых элементов языка от истории литературного языка», Э.Р. Тенишевның «Принципы составления исторических грамматик и историй литературных тюркских языков» һ.б. кебек хезмәтләре аша, гомумтюркологик планда бара торган фикерләрне фәнни нигез буларак алып эш итә.

Галимәнең 1988–2006 елларда Казан дәүләт университеты татар филологиясе факультеты студентларына беренче мәртәбә ана телендә «Гомуми тел гыйлеме» курсы буенча лекцияләр укуы да ныклы белем чыганагы булып карала ала. Курсның объекты, максат-бурычлары, төп проблемалары турында «Тел һәм сөйләм» мәсьәләләре, «Телнең знаклар системасы булып яшәве», «Телнең структур төзелеше, аның бербөтен катлаулы система булуы», «Тел үсешенең типларын билгеләү, телнең функциональ вазифасы – кулланылыш үзенчәлекләре, эчке һәм тышкы шартларга бәйле булуы», «Тел стильләре һәм сөйләм стильләре мәсьәләсе», «Лингвистик методлар мәсьәләсе» кебек темаларга лекцияләр әзерләргә кирәк була. Нәтиҗәдә, студентлар өчен «Гомуми тел гыйлеме. Программа һәм аерым темаларның кыскача методик эшкәртмәсе» языла (Казан, 2003, 55 б.), «Татар стилистикасының теоретик нигезләре» хезмәте басыла (Казан, 2005, 28 б.). Укыту эшчәнлеген ул Татар дәүләт гуманитар институтында да дәвам итә. Илида Бәширова студентларга белем бирүне фәнни эшчәнлек белән тыгыз үреп алып бара, бер-бер артлы фәнни хезмәтләре дә нәшер ителә.

2001 елдан, Институт планы буенча, «Татар теленең күптомлы академик (тарихи) лексикологиясе» төзелә башлый. Татар телендә лексик-семантик категорияләрнең системасын күзалларга, лексик мәгънәгә караган проблемаларны хәл итәргә кирәк була. И. Бәшировага «Җәмгыять» тематик төркеменә берләшә торган сүзләрне барлау, системага салу, анализлау эше йөкләнә. Шулай ук ул «Лексикада системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр» дигән, татар лексикологиясендә кул тимәгән теманы эшкәртергә алына. Нәтиҗәдә, «Хәзерге татар

әдәби теле. Семасиология: татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр» хезмәте дөнья күрә [Бәширова, 2006]. Алга таба «Татар әдәби теле. Семасиология» дигән күләмле китабы басылып чыга [Бәширова, 2010]. Монография галимәнең хезмәттәшләре тарафыннан уңай бәяләнә [Сагдеева, Миннуллин, 2011].

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законы. 2004–2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»нда «...татар халкының рухи мирасы буларак, татар телен төрле яклап һәм тирәнтен, шул исәптән яңа лингвистик караш һәм дөньякүләм телләр үсеше тәҗрибәсе күзлегеннән чыгып, фәнни тикшерү» кирәклеге ассызыклана [Программа, 2005, б. 26]. Әлеге максатны, ягъни классик иске татар әдәби телен яңача өйрәнүне тормышка ашыру мәсьәләсе, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге хезмәткәрләренә тапшырыла. Проект җитәкчесе итеп И.Б. Бәширова билгеләнә. Бу чорга кадәрге тикшеренүләрдә XIII гасырдан алып XX гасырның беренче чирегенә кадәр дәвам итеп килә торган иске татар теленең табигате һәм вазифасы, үз дәвереннән аерылып, хәзерге стандартлашкан әдәби тел яссылыгына куеп бәяләнә [Бәширова, 2012, б. 8]. «Классик иске татар әдәби телен яңача өйрәнү» дигәндә, аның гасырлар буена эзлекле рәвештә дәвам ителеп килә торган тарихы булуын күз уңында тотып, фәнни тикшерүдә әлеге проблеманың төп нигез булуын аңлау юнәлешендә эш башлана. Хәзерге вакытта «Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы)» дип исемләнгән хезмәтнең өч томы (I т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык (Казан, 2015, 692 б.), II т.: Морфология. Грамматик категорияләрнең структурсубстанциональ үзенчәлеге һәм функциональ-стилистик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык (Казан, 2017, 885 б.), III т.: Лексика. Лексик-семантик категорияләрнең инвариантпарадигма үзенчәлеге һәм контекстуаль-синтагматик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык Беренче кисәк (Казан, 2019, 528 б.), Икенче кисәк (Казан, 2020, 588 б.)) басылды. Әлегә кадәр язылган тикшеренүләрдән аермалы буларак, хезмәттә һәр томның темасында күрсәтелгән категорияләрнең язма норма һәм аның вариантлары ачыклана торган тикшерү хәзерге тел кысасында башлана. Бу ысул барлык томнарны язганда методологик таләп буларак саклана. Икенчедән, һәр өч томда да төп игътибар төрки-татар сүзләренең, сүзформа, сүзтезмәләрнең язылышына, төп мәгънәсенең функция башкаруда ничек файдаланылуына юнәлтелә. Фонетикада ике (төрки һәм гарәп) әдәби тел нормасының параллель баруы күзәтелә, чөнки гарәп һәм фарсы сүзләре, сүзформалары катгый рәвештә үз теле кагыйдәләренә буйсына. III томда анализ лексикология фәнендә кабул ителгән тәртиптә эшләнелә, әмма «Җәмгыять» тематик

төркеме дип башламыйча, язма текстларга нигезләнеп, «Илаһи зат» тематик төркеменә караган ялгызлык исемнәр» турында мәгълүмат бирергә кирәк булуы ассызыклана.

Шулай итеп, XIII гасырдан XX гасыр башына кадәр эзлекле хәрәкәттә булган иске татар язма әдәби теленең иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга бәйле хәлдә үсеш-үзгәреше күзәтелә, XIII гасырдан XX гасыр башына кадәр язылган / басылган текстларда чагылыш тапкан иске татар әдәби теленең фонетика, графика, орфография, морфология, лексика тармакларына караган үзенчәлекләре барлана һәм анализлана. Шул ук вакытта тарихи планда язма норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылыкның үзара мөнәсәбәте, ягъни иске татар әдәби теленең төрле гасырлардагы табигате һәм вазифасы билгеләнә, аларның хәзерге татар әдәби теленә булган тәэсире тәгаенләнә. Проектның җитәкчесе буларак, И. Бәширова һәр том өчен гомумтеоретик керешне яза: бу юнәлештә, тел һәм әдәбият галимнәре, тарихчыларның әлеге мәсьәләләргә карата әйтелгән фикерләренә, язган хезмәтләренә мөнәсәбәт белдереп, тикшерелә торган проблеманың максат-бурычларын, методологик нигезен, метод-ысулларын күрсәтә. Аның тарафыннан беренче мәртәбә татар язма әдәби телен өйрәнүнең торышы турында бай һәм киңкырлы мәгълүмат бирелә, яңа исемнәр, яңа хезмәтләр китерелә.

Шулай ук һәр томда, хезмәтне язучы авторларның берсе буларак, галимәнең катлаулы һәм үзенчәлекле Х1Х гасыр ахыры – XX гасыр башы аралыгы татар әдәби теленең фонетикасын, морфологиясен һәм лексикасын өйрәнү буенча бай материалы урын ала.

И. Бәширова әдәби язма тел тарихына кагылышлы мәсьәләләрне тикшерүгә керешер алдыннан һәр очракта бу өлкәдә гомум тел белемендә, тюркологиядә, татар теле белемендә китерелгән терминнар мәсьәләсенә җитди килеп, аларның эчтәлегенә, нинди атамалар белән аталуына игътибар итә һәм бу көнгә кадәр булган фәнни әдәбиятка җентекле анализ бирә. Бу юнәлештә язылган бер генә мәкалә, китап, монография дә аның күз уңыннан читтә калмый. Бай фәнни аппаратка таянып алып барылган анализ галимә тикшеренүләре нәтиҗәләренең объектив, нигезле булуын күрсәтә. Автор шул ук вакытта галимнәр файдаланган термин-төшенчәләрне аңлата бару бурычын да куя. Ул шулай ук чыганакларның әдәби тел тарихын өйрәнүдәге әһәмиятен аерым ассызыклый, аларсыз тарихи-тел закончалыкларын күзәтергә һәм булган гипотезаларның дөреслеген исбатларга мөмкин түгел, дип раслый.

XIII гасырдан XX гасыр башына кадәр эзлекле хәрәкәттә булган иске татар язма әдәби телен анализлау каралган һәр хезмәттә И. Бәширова иң элек әдәби телнең 1) эшкәртелүен-шомартылуын, 2) функциональ-стилистик вариантлылыкка һәм 3) норма вариантлылыгына ия булуын, 4) диалектлардан өстенлеген, 5) дәвамчанлыгы – традициясе булуын [Тенишев 1988, с. 72–73] аңлап эш итү зарурлыгын ассызыклый [Бәширова 2012, б. 9]. Галимә әдәби тел-

нең табигатен һәм вазифасын барлыкка китерә торган бу билгеләрнең тарихын, аларның тел белемендә ни дәрәҗәдә өйрәнелүен карау кирәклеген тоя һәм шул мәсьәләләрне җентекләп тикшерергә алына. Аның «Татар әдәби теле тарихы. Гомумтеоретик мәсьәләләр» монографиясендә нәкъ менә шул сорауларга җаваплар бар [Бәширова, 2012]. Күпсанлы бүлекчәләрдән торган алты бүлектә автор төрки-татар язма әдәби теленең табигатен барлыкка китерә торган традиция-дәвамчанлык, эшкәртелү-шомартылу, диалектлардан өстен, норма һәм норма вариантлыгы, функциональ-стилистик вариантлылык дигән билге-шартларга һәм аларның өйрәнелешенә җентекләп аңлатма бирә. Автор тарафыннан һәр бүлектә аерым бер шартның эчтәлеге ачыла. Мәсәлән, «Төрки-татар язма әдәби теленең табигатен барлыкка китерә торган норма һәм норма вариантлылыгы дигән билге-шарты һәм аның өйрәнелеше» бүлегендә генә дә татар язма әдәби теленең үсеше, статусына һәм функцияләренә кагылышлы мәсьәләләрнең тулы бер комплексы карала. «Татар әдәби теле тарихы» томнарындагы гасырлар дәвамында эзлекле рәвештә яшәештә-хәрәкәттә булган иске татар әдәби теленең фонетика, морфология, лексика тармакларына хас булган язма традицияләрне, норма һәм норма вариантлылыгын, аларның төрле чорлардагы үсеш-үзгәрешен өйрәнү хәзерге татар әдәби теле нормаларының да нинди шартларда, ничек барлыкка килүен билгеләргә ярдәм итә.

И.Б. Бәшированың «Төрки-татар әдәби теле нәзарияте» [Бәширова 2018] исемле хезмәтендә авторның күпгасырлык тарихка ия булган татар язма әдәби теле тарихы һәм теориясе өлкәсендә озак еллар дәвамында алып барган фәнни эшчәнлегенең нәтиҗәләре гомумиләштерелеп бирелә. Аерым алганда, хәзерге татар әдәби теленең нигезендә яткан иске татар әдәби теленең формалашу һәм үсеш этаплары яктыртыла, борынгы язма чыганакларны өйрәнүнең теоретик нигезләре билгеләнә.

Галимәнең һәр китабы киң җәмәгатьчелек һәм галимнәр тарафыннан объектив бәяләнә. Хезмәтләрнең фәнни-теоретик тирәнлеге, фактик байлыгы, тирән эчтәлек белән характерлануы татар теле фәнен яңа биеклеккә күтәрә, яңа тикшеренүләргә нигез сала. Аның тарафыннан иҗат ителгән фәнни хезмәтләр бөтен төрки тел белемендә киң танылып, фәнни кулланылышта йөри. И.Б. Бәшированың фәнни эшчәнлеге төрки тел белемендә үзе дөрес сайлаган юнәлешкә – татар әдәби теле тарихын өйрәнүгә хезмәт итүнең чын мисалы булып тора.

**Әдәбият**

*Бәширова И.Б.* Сүз белән сурәт ясау. Казан: Татар кит. нәшр., 1974. 175 б.

*Бәширова И.Б.* Сәнгатьле чәчмә әсәрләр теле: татар прозасында хикәяләү стиленең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире. Казан: Татар кит. нәшр., 1979. 96 б.

*Бәширова И.Б.* Татар әдәби теле тарихы: XIX гасыр ахыры–XX йөз башы татар әдәби телендә исем категорияләре һәм фигыль наклонениеләрендә әдә-

би норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылык. Казан: КДТУ нәшр., 1999. 576 б.

*Бәширова И.Б.* Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: Татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр. Казан, 2006. 192 б.

*Бәширова И.Б.* XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: жанр стильләре, аерым грамматик категорияләрдә норма һәм вариантлылык. Казан, 2008. 340 б.

*Бәширова И.Б.* Татар әдәби теле. Семасиология. Казан, 2010. 532 б.

*Бәширова И.Б.* Татар язма әдәби теле тарихы. Гомуми кереш: Татар әдәби теленең табигатен һәм вазыйфасын барлыкка китерә торган традиция-дәвамчанлык, эшкәртелү-шомартылу, диалектларыннан өстенлек, норма һәм норма вариантлылыгы, функциональ-стилистик һәм социаль-функциональ вариантлылык мәсьәләләренең татар филологиясендә өйрәнелеше. Казан, 2012. 270 б.

*Бәширова И.Б.* Татар әдәби теле тарихы. Гомумтеоретик мәсьәләләр: татар әдәби теленең билге-шартлары һәм аларның өйрәнелеше. Казан, 2012. 255 б.

*Бәширова И.Б.* Төрки-татар әдәби теле нәзарияте. Казан: ТӘһСИ, 2018. 316 б.

Государственная программа Республики Татарстан по сохранению, изучению и развитию государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2004–2013 годы, Казань, 1995

*Мәхмүтов Х.* Әдәби тел тарихы мәсьәләләре // Мәгърифәт. 2000. 8 июль.

*Низамов И.* Докторлык диссертациясенә торырлык китап // Мәдәни җомга. 2000. 28 июль.

*Сагдеева Ф., Миннуллин Б.* Рец. на: Баширова И. Б. Татарский литературный язык. Семасиология: Монография. Казань, 2010. 532 с. // Ежегодник финно-угорских исследований. Вып. 4. Ижевск, 2011. С. 166–167.

*Сафиуллина Ф.С., Бәширова И.Б.* Сәнгатьле чәчмә әсәрләр теле // Советская тюркология. 1980. № 6. С. 84–85.

*Тенишев Э.Р.* Принципы составления исторических грамматик и историй литературных тюркских языков // Советская тюркология. Баку. 1988. № 1. С. 68–78.

*Хәйретдинова Т.Х.* Хәзинәләр кайтаручы // Мәдәни җомга. 1998. 25 декабрь.

***Кадирова Энҗе Хәнәфи кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81'2

***Ә.М. Шәрипов***

# ТЮРКОЛОГ-ГАЛИМ МАРСЕЛЬ БАКИРОВКА 90 ЯШЬ

Статья посвящена 90-летию со дня рождения профессора, доктора филологических наук Марселя Хаернасовича Бакирова. Автор описывает научные достижения ученого.

**Ключевые слова:** стихосложение, древняя история, комплексное изучение, М.Х. Бакиров, тюрколог.

The article is dedicated to the 90th anniversary of the birth of professor, PhD Marcel Khaernasovich Bakirov. The author describes the scientific achievements of the scientist.

**Keywords:** versification, ancient history, complex study, M.Kh. Bakirov, turkologist.

Агымдагы елның декабрь аенда күренекле шәхес, исеме тюркология дөньясында хөрмәт белән телгә алына торган татар галиме Марсель Бакировка 90 яшь тулды. Фән дөньясына Марсель Бакиров 1960–1970 елларда аяк баса һәм шул вакыттан бирле бертуктамый яңа темалар, яңа проблемалар өстендә эшләп килә. Бер-бер артлы саллы-саллы монографияләр чыгара. Ул хезмәтләрнең һәрберсе фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан фәндә яңа сүз, яңа вакыйга, яңа ачыш булып кабул ителә.

Галим буларак Марсель Бакиров үз алдына киң масштаблы, олы максатлар куеп иҗат итә. Ә бу исә үзе үк кешедән шундый ук зур тырышлык-фидакярлек, ихтыяр көче, үз-үзеңне аямыйча эшләүне таләп итә. М. Бакировның үз алдына куйган максатларының берсе – халкыбыз тарихының тирән, моңа кадәр ачылмаган катламнарына үтеп кереп, андагы рухи байлыктан энҗеләр табып, аларның сыйфат-үзенчәлекләрен өйрәнеп, халкыбызга яңадан кайтарып бирү. Шушы өлкәдә ул дистәләрчә еллар дәвамында үз-үзен аямыйча тырышып хезмәт куя. Ул үзе өйрәнә торган проблеманы һәрвакыт, сабырлыгын эшкә җигеп, җентекләп өйрәнә, мәсьәләнең «төбенә төшеп җитмичә» туктамый.

Марсель Бакиров 1972 елда төрки һәм татар шигыренең эчке ритмик-интонацион хасиятләрен һәм кануннарын тикшереп, кандидатлык диссертациясе яклады. Аның фәнгә керткән яңалыклары әнә шуннан башланып китә. Бу хезмәтендә ул төрки шигыренең үзенчәлекләрен башка халыкларның шигырь төзелешләре белән чагыштырып өйрәнде. Ә андый чагыштыруларны үткәрү өчен, әлбәттә, галимнән әлеге телләрне һәм беренче чиратта инглиз телен яхшы белү таләп ителә. Бу исә аңа үзе эшләгән өлкәдә дөнья күләмендәге

хезмәтләр, алардагы казанышлар белән танышу мөмкинлеген бирде. Галим төрки шигыренең үзәк проблемаларыннан булган төрки гарузының табигатен эксперименталь-фонетик аппаратлар белән тикшерде һәм төрки шигърияте өлкәсендә үзенең шәхси карашын, үз концепциясен булдыруга иреште. Әгәр бу өлкәдә моңарчы эшләгән И.В. Стеблева, М.К. Хамраев кебек галимнәр төрки-татар шигъриятенә гаруз системасы ясалма рәвештә кертелгән һәм төрки телнең табигатенә туры килми, дигән фикердә торсалар, М.Бакиров исә төрки гаруз ул төрки шигъриятенең үз казанышлары һәм уңай алшартлары белән гарәп-фарсы гарузы йогынтысы үзара кушылган җирлектә барлыкка килә, дип, яңа караш тудырды һәм шуны эксперименталь тикшеренүләр белән дәлилләп бирде: уртак казанышлар җирлегендә барлыкка килгән төрки гарузның да табигый яңгырашлы булуын, тел үзенчәлекләре белән үрелеп яшәвен күрсәтте. Бу бөтен тюркологиядә яңа караш һәм үзенчәлекле, кызыклы ачыш буларак кабул ителде.

1981 елда М. Бакиров Казан университеты нәшриятында «Фольклор жанрларын системалы итеп тикшерү тәҗрибәсе» дип аталган автордаш хезмәт бастырып чыгарды. Анда ул бәет жанрының генетик тамырларын, аның эволюцион үсеш-үзгәреш баскычларын ачыклады, аларны тематик төркемнәргә аерып, сәнгатьчә эшләнешен, поэтикасын күздән үткәрде. Бу басма фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан яратып, хуплап каршы алынды. Гыйльми ачышларны союз күләмендә пропагандалауның Самара шәһәрендә урнашкан фәнни-зона үзәге соңыннан аны үзенә соратып алдырды, һәм чит илләргә дә тарату максатыннан, АКШ, Англия һәм Германия китапханәләренә җибәрде.

Галим шул ук елларда фольклор өлкәсендәге тикшеренүләре белән беррәттән төрки-татар шигыре һәм борынгы төрки поэзиясенә бәйле эшләр дә алып барды. Үзенең остазы профессор Хатип Госманның хезмәтләрен дәвам итеп, ул гомумтөрки шигыренең һәм поэзиясенең чишмә башын ачыклау һәм иң борынгы жанрлар системасын реконструкцияләү буенча җитди эзләнүләр үткәрде. Шул максаттан чыгып, Мәскәү, Санкт-Петербург, Алма-Ата, Баку, Ереван, Бишкәк, Ташкент, Уфа кебек шәһәрләрнең үзәк китапханәләрендә үз темасына караган материалларны бөртекләп җыйды, тикшерде, анализлады. Шушы эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, 2001 елда яңа зур саллы хезмәт – «Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары» дигән монографиясе дөнья күрде. Авторның докторлык диссертациясе дә 1999 елда шушы монографиягә нигезләнеп якланды.

Бу хезмәт әле моңарчы тикшерелмәгән күпкырлы, гаять тирән һәм катлаулы темага багышланган. Монда да галим проблеманы комплекслы өйрәнгән – тикшеренүләрен шигырь белеме, сәнгать белеме, эстетика, мифология, этнография, фольклористика, лингвистика, социаль психология, дини тәгълимат, философия, этник

культурология, тарих кебек арадаш фәннәр яктылыгында, шул фәннәр казанышларын мул файдаланып алып барган. Кереш һәм алты бүлектән торган бу монографиянең колачын һәм эчтәлеген күз алдына китерү өчен, андагы бүлекләрнең исемнәрен генә атау да җитә. Менә алар: хезмәт – башлангыч поэзиянең материаль нигезе; шигъриятнең фикер һәм сәнгати җирлеге буларак мифология; иң элгәрге шигъри сүз сәнгатенең синкретик табигате һәм морфологиясе; иҗади шәхес күпкырлы һәм күп вазифалы сүз остасыннан башлана; язма шигъриятнең иң борынгы үрнәкләре; борынгы төрки поэзиянең тарихи поэтикасы. Шуңа игътибар итик: моңа кадәр тюркологиядә бу өлкәдәге фәнни хезмәтләр, нигездә, метрика, строфика һәм рифма кебек шигырь төзелешенең аерым якларын тикшерүгә генә кайтып калган булса, М. Бакиров хезмәтендә борынгы төрки поэзиянең материаль базасы да – шул чор кешеләренең хезмәте белән бәйләнеше, ул бәйләнешнең төрләре, эволюциясенең баскычлары билгеләнә, ә мифология исә шигъриятнең фикри-идеологик һәм сәнгати җирлеге буларак анализлана. Галим «хезмәтнең, гамәли эшчәнлекнең үзенчәлекле дәвамы булган йола-ритуаллар һәм мифологик идеология элек, үзара үрелеп, аерылгысыз бербөтен (комплекс) тәшкил иткән һәм нәкъ менә шушы йола-мифология синкретизмы борынгы шигъриятнең иң беренчел җирлеге хезмәтен үтәгән», дигән караштa тора. Ул шушы йола-миф синкретизмы җирлегендә барлыкка килгән иң борынгы жанрлар системасын барлап-реконструкцияләп чыга: барлыгы унбер баба жанрга мисаллар китерә; алар барысы да моңа кадәр аз билгеле яки бөтенләй билгеле булмаган, беренче башлап автор тарафыннан фәнни әйләнешкә кертелгән уникаль фактик материалга нигезләп тикшерелгәннәр. Ул чордагы әдәби жанрларны Урта гасырлар жанрлар системасы белән чагыштыру үзе үк бик кызыклы нәтиҗәләргә китергән.

Шушы ук хезмәттә «Сак-Сок» образларының килеп чыгышы Шәрык мифологиясе контекстында өйрәнелә. Автор аларны борынгы игезәкләр культына һәм үзе тапкан типологик һәм генетик тәңгәллекләргә нигезләп, Көнчыгышта барлыкка килгән борынгы уртак мифология һәм культура мирасына бәйләп аңлата. Бездәге «Сак-Сок»ны борынгыдан килгән уртак катлам җирлегендә туган милли версия итеп карый. Бу сюжетны көньякта Кубрат хан тарафыннан төзелгән Бөек Болгар дәүләтенең соңрак – аның варислары чорында таркалып юкка чыгу фаҗигасы белән бәйли, ягъни мифологик образларда Кубратның уллары һәм болгар кабиләләре арасында бердәмлек-татулык бозылуның һәлакәткә китерүе чагылыш тапкан булса кирәк, ди.

Монографиянең бер бүлегендә ыруг-кабиләнең коллектив иҗатыннан шаман-шагыйрьләр иҗаты аерылып чыгу процессы күзәтелә. Галим, тюркологиядә беренчеләрдән булып, һун бабаларыбызда һәм борынгы төрки сүз сәнгатендә матур сөйләү-ораторлык сәнгате булуын ачты, Орхон язмаларының да шул ук традициягә

нигезләнгәнлеген исбатлады. Бу сәнгатьнең Орхон-Енисей язмаларында сакланып калган үрнәкләрен, традицияләрен анализлады. Бу монографиядә М. Бакиров төрки поэзиядә йола-миф синкретизмы җирлегендә барлыкка килгән иң борынгы жанр төрләрен тәүге тапкыр барлап реконструкцияләде, система итеп күз алдына бастырды. Алар түбәндәгеләр: мәҗүси аллаларга һәм илаһи көчләргә багышланган гимннар, ода-алкышлар, корбан-келәү бәйрәмнәре һәм календарь-хуҗалык йолалары вакытында башкарылган келәүләр, йола әйтешләре, йола-уен җырлары, ырымнар, арбаулар, сыгытсыктаулар, шаман чакырулары, каргышлар, антлар. Бу жанрларның күпчелеге төрле төрки халыкларның борынгы иҗатыннан алынган, моңарчы фәндә тикшерелмәгән, беренче тапкыр автор тарафыннан фәнни кулланылышка кертелгән уникаль фактик материалга нигезләнеп барлыкка китерелгән.

Шул ук вакытта М. Бакиров һун чоры поэтик сүз сәнгатенең жанрларын барлап һәм реконструкцияләп кенә калмады, ә шул ерак чордан ук башлангыч алган сәнгатьчә фикерләү өлгеләренең төрки поэзиядәге күчемлелеген һәм дәвамлылыгын да эзлекле рәвештә күздән кичерде. Шунысы да әһәмиятле: хезмәттә башлангыч язма сүз үрнәкләре шул чорда төркиләр кулланган иң элгәрге алфавитлар белән бәйләп карала, узган чорларда алар тоткан тәңречелек, будда, манихей, христиан һәм ислам кебек төрле диннәр контекстында тикшерелә.

М. Бакировның бу хезмәтенә галимнәр һәм фәнни җәмәгатьчелек зур бәя бирде. Академик Мансур Хәсәнов «Шигърият чоңгылларына юл ячучы хезмәт» дигән рецензия бастырды («Мирас» журналы, 2002 ел, № 6) һәм болай дип язды: «Күпьеллык иҗат җимеше булган әлеге эшнең фәнни яңалыгы һәм галимнең кыюлыгы, тикшерү объектының тирән катламнарына үтеп керә белү сәләте бәхәссез. Тюркологиядә һәм татар әдәбият белемендә төрки әдәбиятның үзенчәлекле борынгы нигезләрен тикшергән аерым хезмәтләр элек тә бар иде. Әмма моңарчы бу кадәр ерак заманнарга һәм тирәнгә, ягъни бабаларыбыз тудырган шигъри-поэтик иҗатның пратөрки дәверенә, яралгы-эмбрион хәлдәге чорына берәүнең дә игътибар иткәне һәм бу кадәр тирән үтеп керә алганы юк иде әле».

2019 елда М. Бакиров тагын бер саллы китап – «Прототюрки: изначальная прародина, ранние племена и язык, история и этнокультура» монографиясен бастырып чыгарды. Бу хезмәтендә дә ул фән өчен гаять актуаль җитди проблемалар күтәрә. Әйтик, прототөркиләр теленең барлыкка килүе мәсьәләсен. М. Бакиров аны да, күптөрле арадаш фәннәр – тарих, археология, этнография, мифология, фольклор, тел гыйлеме, диннәр тарихы, философия, антропология һәм, гомумән, күп гасырлык матди һәм мәдәни казанышлардан киң файдаланып ачыклый.

Әлеге басма фәндә аеруча зур яңалык буларак кабул ителде. Азәрбайҗан галиме Тариел Азертюрк болай дип язды: «Профессор-тюр-

колог М.Х. Бакировның әлеге монографиясе хәзерге ориенталистика фәнендә үзенә бер аерым әһәмиятле, мөһим вакыйга булып тора, чөнки борынгы төркиләрнең этногенезы, этнокультурасы һәм этнолингвистикасы буенча булган азсанлы фәнни хезмәтләргә беренче тапкыр шундый яңа, уникаль һәм саллы хезмәт килеп өстәлде. Бу китапта моңа кадәр булмаган глобаль характердагы, яңа һәм оригиналь концепциянең барлыкка килүе бәян ителә; ул концепция шуннан гыйбарәт: иң борынгы чорда төрки телләр бердәмлеге Якын һәм Алгы Азиядәге бердәм ареаль союз составындагы тугандаш (агглютинатив) һәм тугандаш булмаган (флектив) телләр лексикалары һәм тарихи грамматика үзенчәлекләренең үзара аралашуы, кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән».

Ә тарих фәннәре докторы, профессор Гамирҗан Дәүләтшин М. Бакировның бу хезмәтенә язган рецензиясендә, аңа зур бәя биреп, түбәндәге фикерен әйтте: «Төркиләрнең оешу процессын М. Бакиров һинд-европа, ностратика, шулай ук бу төркемнәргә кермәгән шумер, урарту, хуррит, кавказ телләрендә сөйләшкән халыклар белән озак вакытлар буена тел-лөгать алмашып яшәү белән бәйли һәм төрки баба тел, дөресрәге, иң борынгы төрки диалектлар берлеге нәкъ менә Көнбатыш яки Алгы Азия ареалында хатт, элгәре яки иске мидия, элам, дравид, кути, кассит, этруск, сабир/савир кебек агглютинатив телләрнең үзара якынаюы, генетик-контакт кардәшлеге җирлегендә формалашканнар, дигән концептуаль нәтиҗәгә килә. Моның өчен ул әлеге агглютинатив телләрнең һәркайсына диярлек аерым бүлекчәләр багышлый һәм аларның телләреннән, матди һәм рухи культураларыннан төркиләр белән уртак катламнар аерып чыгарып, үзенең төп концепциясен ышандырырлык итеп нигезли».

2022 елда М. Бакиров фәнни җәмәгатьчелекне тагын бер яңа хезмәте – «Тайны происхождения наших предков» исемле монографиясе белән сөендерде. Бу хезмәтендә дә галим үзенең тикшеренү прицилларына тугрылыклы кала.

Монография ике бүлектән тора. Аның беренчесе «Болгар һәм татарларның аз билгеле булган этник тамырлары» дип атала. Анда галим түбәндәге мәсьәләләргә туктала: болгарлар – җирле һәм күчеп килгән кабиләләрнең үзара кушылуыннан барлыкка килгән; хәзәрләр һәм барсиллар этник тарихларының болгарлар белән кушылып үрелүе; савир/суварлар – болгарларның этник берлеге кабиләдәшләре; болгар, татар һәм кыпчакларның бердәм этнос булып берләшүе. Шушында ук ул Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының нәкъ менә Болгар дәүләтендә язылганлыгын күп дәлилләр китереп исбатлый; шул ук чорда иҗат ителгән, моңа кадәр фәндә билгеле булмаган «Ана вә угыл» поэмасы текстын (246 юл) фәнни кулланылышка кертә.

М. Бакиров прото- һәм пратөрки теленең иң борынгы һәм иң архаик сүзлек составын чагылдырган, борынгы чордагы Алгы Азия һәм Төньяк Африка территорияләрендәге ареаль телләр союзында

гамәлдә булган лексик -семантик сүзлекне барлыкка китерде (әлеге сүзлек Алгы Азия һәм Төньяк Африка территорияләрендәге ареаль телләр союзындагы барлыгы 752 лексик праформаны үз эченә ала). Бу сүзлек үзе генә дә галимнең зур уңышы санала ала һәм ул киләчәктә шушы өлкәдә эшләүчеләр өчен кыйммәтле чыганак булып хезмәт итәчәк.

Әлеге монографиядә тикшерелгән мәсьәләләрнең тагын берсе – чуваш милләтенең формалашу тарихын аңлату. Моңа кадәр галимнәр арасында чувашларны төрки халыклар ареалына кертеп карауучылар да булды. М. Бакиров моңа кискен каршы чыга: күптөрле лексик мисаллар китерә һәм чувашларның чыгышлары белән үк фин-угор телле халык икәнлеген исбатлый.

Галим этник тарихның тирән катламнарына үтеп керә алган, фәнни тикшеренүләренең концептуаль нәтиҗәләре нәкъ менә шуны раслый.

М. Бакиров борынгы төркиләрнең иң борынгы ватаны Якын Көнчыгышта булганлыгын фәндә беренче булып һәм кире кага алмаслык дәлилләр белән исбатлады. Бу исә – тюркология һәм Көнчыгышны өйрәнү фәнендә зур казаныш. Шундый киң масштаблы, өр-яңа фикерләр белән тулы фәнни хезмәтләр язуы М. Бакировның тирән фикерле галим икәнлеген тагын бер тапкыр раслый.

М. Бакировның хезмәтләре турындагы мәгълүмат инглиз телендәге «Кто есть кто?» һәм Мәскәүдә нәшер ителгән «Российские фольклористы» дигән еллык фәнни-библиографик җыентык-белешмәлекләргә кертелде. Аның хезмәтләренә бөтенроссия күләмендә күренекле галимнәр – якут галиме Табуроков («Проблема сравнительного стиховедения». Якутск, 1986), үзбәк галимнәре У. Туйчиев («Узбек поэзиясидә гаруз системасы». Ташкент, 1986), Т. Хамраев («Древнетюркский книжный стих». Алма-ата, 2002), шулай ук Зәки Әхмәтов, М. Хамраев, Г. Хөсәенов (Уфа) зур бәя бирделәр.

М. Бакиров бүгенге көндә дә тынгысыз эзләнүләрен дәвам итә. Быел ул «Мең дә бер фикер» дигән яңа китабын чыгарды.

Ул даими рәвештә җанлы әдәби процесста да катнашып килә; шигырь белгече буларак, үзенең сүзен гел ишеттереп тора. Үзе дә шигырьләр яза; «Хан кызы» дигән драма әсәре язып та сокландырды. Аның Р. Харис, Зөлфәт, Х. Әюпов, Ф. Садриев иҗатлары, Т. Галиуллин трилогиясе хакындагы мәкаләләре дә язучыларыбызның иҗатын киң планда һәм тирән итеп анализлавы, аларга дөрес бәя бирүе белән аерылып тора.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: М. Бакировның фәнни тикшеренүләрен Казан федераль университетында алып барган укытупедагогик эшчәнлегеннән аерып карап булмый. Ул дистә еллар буе шушы уку йортында «Әдәбият белеменә кереш», «Әдәбият теориясе», «Татар халык тел-авыз иҗаты» буенча лекцияләр укыды, студентларны фәнни ачышлар дөньясына алып керде. Аның җитәкчелегендә татар әдәбияты өлкәсендә берничә кандидатлык диссертациясе

якланды. Хәзерге вакытта ул Казандагы Традицион мәдәниятне үстерү буенча республика үзәгенең әйдәп баручы укытучысы һәм фәнни хезмәткәре булып эшли. Студентлар аның дәресләре турында сокланып сөйлиләр, «Безнең Марсель абыебыз бар!» дип горурланалар.

Үзенең күпьеллык тырыш һәм нәтиҗәле, фидакяр фәнни-педагогик һәм иҗтимагый эшчәнлеге өчен Марсель Бакиров «Дуслык» ордены белән бүләкләнде.

Марсель Бакиров бүген дә халкыбызның этник тарихы, әдәбияты, теле, мәдәнияте тарихы мәсьәләләрен җентекләп-нечкәләп тикшерүләрен туктатмый. Без аңа исәнлек-саулык, киләчәктә дә бөтен төрки дөньяны сокландырырлык яңа ачышлар ясавын, яңадан-яңа фәнни уңышларга ирешүен телибез.

***Шәрипов Әнвәр Мәгъдәнур улы,***
*филология фәннәре докторы*
*(Яр Чаллы)*

УДК 371.214.41=512.145

***М.М. Шәкүрова,***
***Л.М. Гыйниятуллина***

# ТАТАРСТАН ГАЛИМНӘРЕНЕҢ ФӘННИ-МЕТОДИК МИРАСЫ: СӘГАДӘТ МӨГАЛЛИМ УЛЫ ИБРАҺИМОВ
## (галим-методистның тууына 95 ел)

Статья посвящена деятельности учёного-методиста С.М. Ибрагимова. Основное внимание уделяется анализу лингвометодических трудов учёного. Выявлена роль С.М. Ибрагимова в истории национального образования РТ. Исходя из внимательного изучения научных работ, учебников татарского языка, считаем, что методические выводы и предложенные положения учёного не потеряли своей актуальности в настоящее время, когда обучение татарскому языку в общеобразовательных организациях ведется в свете внедрения обновлённого Федерального государственного образовательного стандарта.
**Ключевые слова**: С.М. Ибрагимов, татарский язык, аналитические конструкции, синтаксическая стилистика, методика преподавания.

The article is devoted to the activities of the scientist and methodologist S.M. Ibragimov. The main attention is paid to the analysis of the scientist's linguistic and methodological works. The role of S.M. Ibragimov has been revealed in the history of national education of the Republic of Tatarstan. Based on a careful study of scientific works and textbooks of the Tatar language by a linguo-methodologist, we believe that the methodological conclusions and proposed provisions of the scientist have not lost their relevance at the present time when teaching the Tatar language in general education organizations is carried out in the light of the implementation of the updated Federal State Educational Standard.
**Keywords:** S.M. Ibragimov, tatar language, analytical constructions, syntactic stylistics, teaching methods.

Сәгадәт Мөгаллим улы Ибраһимов – татар теле синтаксисы һәм стилистикасы, мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен күпсанлы программалар, дәреслекләр авторы, галим-методист. Гомумән, татар тел белеме гыйлемле, талантлы һәм бөтен гомерен, барлыгын фәнгә багышлаган галимнәргә бик бай. Шулар арасында Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, Казан дәүләт университеты доценты, филология фәннәре кандидаты С.М. Ибраһимов аерым урын алып тора. Күренекле галим «Татар телендә аналитик төзелмәләр» дигән монографиясендә, татар тел белемендә һәм тюркологиядә беренчеләрдән булып, башка аналитик чаралар белән бергә мөнәсәбәтле сүзләрне дә җентекләп тикшерде, мөнәсәбәтле сүзләрнең үзенчәлекләрен системалы рәвештә күрсәтеп, аларны теркәгеч сүзләр һәм ияртүче теркәгечләр белән чагыштырып, төп үзенчәлекләрен билгеләде.

С.М. Ибраһимов 1928 елның 25 маенда Азнакай төбәгенең Таллы Бүләк авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Ютазы районы Кәрәкәшле авылы мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1946–1951 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында белем ала, укытучы (Мөслим, 1951–1954), татар теле һәм әдәбияты инспекторы (Мөслим, Лениногорск, 1954–1958) вазифаларын башкара, газетада эшли. 1960 елда С.М. Ибраһимов Казан дәүләт университеты аспирантурасына укырга керә, кандидатлык диссертациясен дә уңышлы итеп яклый (1964). Аннары Казан дәүләт университетының татар теле кафедрасында, 1989 елдан татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы кафедрасында эшли. Гыйльми эш алып бару белән беррәттән, ул бик күп вакытын һәм көчен татар телен укытуга багышлый, урта мәктәпләр өчен программалар һәм дәреслекләр, методик кулланмалар һәм дидактик материаллар төзүдә катнаша: «Синтаксик стилистикадан күнегүләр» (1968), «Синтаксистан күнегүләр җыентыгы» (1970, М.З. Зәкиев белән берлектә), «Татар теле: Синтаксис. 7–8 нче сыйныфлар өчен дәреслек» (1973, М.З. Зәкиев белән берлектә), «Татар теле. Синтаксис. 7 нче сыйныф өчен» (Ф.С. Сафиуллина белән берлектә, 1993). «Татар теле. 9 нчы сыйныф, рус мәктәпләрендә укучы татар балалары өчен дәреслек» (Ф.С. Сафиуллина белән берлектә, 1997) һ.б. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: С.М. Ибраһимовның (М.З. Зәкиев һәм Ф.С. Сафиуллина белән берлектә язылган) мәктәп һәм вуз программалары, VII, IX татар һәм XI сыйныф рус урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен чыккан югары сыйфатлы татар теле дәреслекләре галимнең күпьеллык гыйльми тикшеренүләре, укыту тәҗрибәсе нигезендә эшләнгән. Әлеге дәреслекләр бүген дә ничәмә-ничә буынны тирән белемле, грамоталы белгечләр итеп тәрбияләүдә классик өлге булып торалар [Шәкүрова, 2012, б. 144]. Мисал өчен, 1994 елда С.М. Ибраһимов авторлыгында (Ф.С. Сафиуллина белән берлектә язган) «Татар теле: Унберьеллык урта мәктәпнең 7 нче сыйныфы өчен дәреслек» чыга. Биредә гади җөмлә синтаксисы һәм тыныш билгеләре, синтаксик берәмлекләр, җөмлә һәм аның төрләре, җөмләнең баш кисәкләре, җөмләнең иярчен кисәкләре, җөмләдә сүзләр тәртибе, бер составлы җөмлә белән ике составлы җөмлә синонимлыгы турында тулы мәгълүмат, кызыклы биремнәр, күнегүләр бирелә. Дәреслектә ФДБС туры килерлек эш төрләре, сораулар һәм җаваплар, схемалар бар [Шәкүрова, 1994, б. 123–140].

С.М. Ибраһимов – күпсанлы мәкаләләр авторы да. Ул аларны даими рәвештә «Совет мәктәбе», «Мәгариф», «Совет тюркологиясе» журналларында һәм төрле фәнни җыентыкларда бастырып килә. Мәсәлән, «Укучыларның тел күнекмәсен үстерүдә аналитик һәм синтетик төзелештән файдалану» дигән мәкаләсендә (1963) сөйләм телен үстерүдә яисә рус балаларына татар теле укытуда аналитик һәм синтетик формалы җөмләләрне куллану һәм аларның синонимлыгы турында сүз алып барыла. 1969 елда «Татар теле белеме мәсьәләләре»

җыентыгында басылган «Татар телендә синтаксик синонимнарны өйрәнү һәм аларны билгеләүнең кайбер мәсьәләләре» дигән мәкаләсендә синтаксик синонимнарга җентекләп туктала.

Татар тел гыйлеме өчен әһәмиятьле фәнни журналлардан саналган «Советская тюркология»дә 1987 елда «Формирование и функционирование татарского языка» исемле фәнни язмалар җыентыгына аннотация буларак язылган тагын бер мәкаләсе дөнья күрә. С.М. Ибраһимов җыентыкта чыккан М.З. Зәкиев, Я.Ф. Кузьмин-Юмадин, Ф.Й. Йосыпов, М.М. Нигъмәтуллов, Г.И. Одинокова, А.С. Зинина, З.З. Сәитов кебек галимнәрнең мәкаләләренә кыскача аннотация яза.

С.М. Ибраһимовның «Татар телендә аналитик төзелмәләр» (1964), «Чагыштырулы төзелмәләр һәм аларның синонимнары» (1966), «Синтаксик синонимнар һәм аларның төрләре» (1970), «Газета теле» (1971), «Татар телендә синтаксик синонимнар» (1976), «Синтаксик стилистика» (1989) һ.б. фундаменталь хезмәтләре бүген дә актуаль. Мәсәлән, «Татар телендә аналитик төзелмәләр» дигән хезмәтендә синтетик җөмләне – аналитик иярчен җөмләгә, гади җөмләне аналитик иярченле кушма җөмләгә әйләндерү, берничә гади җөмләдән аналитик (яки синтетик) бәйләнештәге кушма җөмләләр төзү һ.б. үзенчәлекләрен ачыклый. Бер үк мәгънәдәге кирәксез кабатлауларны булдырмау, кирәк урында бер төрне икенчесе белән алмаштыру өчен, телебездә бик күп чаралар кулланырга, фикерне укучыга төгәл җиткерүдә шуларның иң уңышлысын сайлап алырга тәкъдим итә.

1971 елда чыккан «Газета теле» дип аталган кулланмасының беренче бүлегендә автор, төрле газеталарның телен өйрәнеп, аның нинди юнәлештә үсә баруын, бу эштәге уңышларны, булган кимчелекләрне яктырту, киләчәк өчен төп бурычларны билгеләү максатыннан язылган мәкаләләргә күзәтү ясый [Ибраһимов, 1971, б. 39]. Әлеге хезмәтнең икенче бүлегендә газета теленең үзенчәлекләре билгеләнә: газета телен төрле терминнар, халыкка аңлаешсыз сүзләр белән чуарламаска; ясалма сүзләрдән, калькалардан котылырга; сүзтезмәләрнең компонентлары арасында килешә алу-алмаулары мәсьәләсен дә читләтеп үтмәскә; бәйләүче чараларның күптөрлелегеннән файдаланырга; яңа төшенчәләр, яңа сүзләр кулланганда, тел хасиятләренә игътибар итәргә кирәклек һ.б. ассызыклана.

С.М. Ибраһимовның «Татар телендә синтаксик синонимнар» дигән китабы (1976) әлегә татар тел белемендә аз тикшерелгән, әмма сөйләм өчен зур әһәмияте булган синтаксик синонимнарны билгеләүгә, аларның төрләрен, кулланылышын өйрәнүгә багышланган. Мәгънәдәш сүзләрнең сөйләмне баетудагы һәм стильне камилләштерүдәге урыны күрсәтелгән. Синтаксик синонимнарны читләтеп, исәпкә алмыйча эш итүнең стильгә зарар китерү ихтималы да истә тотыла: «Сөйләм камил булсын өчен, әйтергә теләгән фикер төгәл аңлаешлы чыксын өчен лексик синонимнар белән генә эш итү җитми, шулай

ук синтаксик синонимнарның нәрсә икәнен төшенү, аларның төрләрен күзаллау, урынлы куллана белү дә бик кирәк» [Ибраһимов, 1976, б. 3].

Галимнең 1989 елда чыккан «Синтаксик стилистика» дигән китабы татар сөйләме өчен әһәмиятле саналган синтаксик стилистика мәсьәләләрен үз эченә ала. Әлеге хезмәттә ул әдәби сөйләм, стиль, функциональ стиль дигән терминнарга аңлатма бирә, хәзерге татар әдәби сөйләменә түбәндәге стильләрне кертә: матур әдәбият стиле, публицистика стиле, фәнни стиль, рәсми эш кәгазьләре стиле, хатлар стиле [Ибраһимов, 1989, б. 15]. Анда сөйләм берәмлекләрен стилистик куллану, синтаксик синоним һәм омоним күренешләре тулы яктыртыла. «Башка синонимнарны бик иркен кулланырга мөмкин булып та, бары тик ***буенча*** бәйлек сүзен һәрвакыт кирәгеннән артык алуны, шул чара исәбенә җиңел генә котылырга тырышуны һич тә мактап булмый» дип, сөйләмдә ялыктыргыч бертөрлелектән котылырга чакыра [Ибраһимов, 1989, б. 103]. Газета-журнал битләрендә, матур әдәбиятта *буенча* бәйлек сүзе белән төзелгән сүзтезмә һәм җөмләләрнең саны бүген дә артканнан-арта бара.

С.М. Ибраһимов әлеге хезмәттә сөйләмдә синтаксик омонимнарның (төзелешләре белән бердәй булып, берничә мәгънәне аңлата торган сүзтезмәләрнең, җөмләләрнең) бер төре булган стиль омонимнарын булдырмау турында да сүз алып бара: бу төр омонимнар «…стильне матурламыйлар, бәлки фикерне төгәл, ачык, анык һәм дөрес итеп әйтеп бирергә комачаулык ясыйлар, укучыга җөмлә тиз генә барып җитми, берничә төрле хөкем йөртергә урын кала» [Ибраһимов, 1989, б. 112]. Мондый омонимнардан качу (нинди дә булса бер сүз иярткүче сүздән читләштерелгән булырга мөмкин; бер исем белән икенче кешенең фамилиясен янәшә кую; тартымлы сүз алдагы сүз белән бәйләнештә каралу һ.б.) укучыларның язма эшләрендә, инша, хикәяләрдә, газета-журнал мәкаләләрендә, әдәби әсәрләрдә фикерне төгәл бирергә мөмкинлек ача: *Григорий Федоров «эшеннән» тәмам туйган иде* (А. Расих). Бу җөмләдә Федоровның исеме Григорий дип аңлашылырга мөмкин. Кирәк: *Федоров «эшеннән» Григорий тәмам туйган иде* [Ибраһимов, 1989, б. 115]. Әлеге хезмәттән алынган тагын бер мисалга тукталып үтик: *Казанга кайткач, Вәли картның киңәшен онытмады* (Г. Әпсәләмов). Кирәк: *Картның киңәшен Вәли Казанга кайткач онытмады.* Биредә сүз тәртибен үзгәртеп язу омонимлыктан коткарган. Биредәге *карт* сүзе *Вәли* белән бернинди бәйләнештә тормый, бу ике сүз ике кешене аңлата.

Татар телендә актив һәм пассив төзелмәләр турында иң төпле хезмәтләрнең берсе буларак, С.М. Ибраһимовның «Татар телендә синтаксик синонимнар»ын атап үтәсе килә. Ул башка төр синтаксик синонимнар белән беррәттән пассив төзелмәләрне дә тикшерә һәм аларның актив төзелмәләр белән синонимлыгын ачыклый, төрләрен аерып чыгара.

Гомумән алганда, галимнең бу хезмәтләре фикер тирәнлеге, фән логикасы, искиткеч зур фактик материалга нигезләнүе белән татар тел белемендә югары бәяләнде.

Сәгадәт Мөгаллим улы Ибраһимовның тормышы һәм иҗат юлы гаять кызыклы. Ул чын мәгънәсендә үз эшен белеп, яратып башкаручы галим-методист, тәҗрибәле укытучы иде. Аның методик кулланмалары, мәктәп дәреслекләре бүген дә үрнәк булып торырлык.

**Әдәбият**

*Ибраһимов С.М.* Газета теле. Казан: КГУ, 1971. 52 с.

*Ибраһимов С.М.* Татар телендә синтаксик синонимнар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1976. 168 б.

*Ибраһимов С.М.* Синтаксик стилистика. Студентлар өчен кулланма. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1989. 150 б.

*Ибраһимов С.М.* Сандугач теле кирәк: Синтаксик стилистика. Казан: Мәгариф, 2008. 159 б.

*Сафиуллина Ф.С., Ибраһимов С.М.* Татар теле: Унберьеллык урта мәктәпнең 7 нче сыйныфы өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 1994. 175 б.

*Шәкүрова М.М.* Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы. Казан: «Ихлас», 2012. 144 б.

*Мәкалә «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасының 3.19 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Шәкүрова Мөслимә Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Гыйниятуллина Лилия Миңнулла кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, Институтның гыйльми сәркатибе*

УДК 82-131(049.32)

***Ф.З. Яхин***

## КИТАП КҮЗӘТҮ:
## ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ ҺӘМ ДАСТАННАР
**Мухаметзянова Л.Х. Эпическая культура татар: дастаны.**
**Казан: ИЯЛИ, 2023. 120 с.: ил.**
**(серия «Обычаи и традиции татарского народа»)**

Автор рецензирует научно-популярное издание «Эпическая культура татар: дастаны», вышедшее в свет в серии «Обычаи и традиции татарского народа» под авторством доктора филологических наук, главного научного сотрудника отдела народного творчества ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ Л.Х. Мухаметзяновой. Рецензент обращает внимание на обобщённое изложение в книге ключевых сведений об эпическом творчестве татар, о стиле, образах, сюжетах, мотивах, многочисленных рукописных списках самых распространённых образцов жанра; отмечает широкий охват архивных и опубликованных текстов татарских дастанов в различных вариантах; определяет концептуальные основы научно-популярного исследования и вклад автора в популяризацию татарского эпоса.

**Ключевые слова:** научно-популярное издание, книга, автор Л.Х. Мухаметзянова, эпическая культура народа, эпос-дастан, фольклористика, этнолитературоведение, татарский народ.

The author reviews the popular scientific publication «Epic Culture of the Tatars: Dastans», published in the series «Customs and Traditions of the Tatar People» under the authorship of Doctor of Philology, Chief Researcher of the Department of Folk Art of the IYALI named after. G. Ibragimova AN RT L.Kh. Mukhametzyanova. The reviewer draws attention to the general presentation in the book of key information about the epic work of the Tatars, about style, images, plots, motifs, numerous handwritten lists of the most common examples of the genre; notes the wide coverage of archival and published texts of Tatar dastans in various versions; defines the conceptual foundations of popular science research and the author’s contribution to the popularization of the Tatar epic.

**Keywords:** popular science publication, book, author L.Kh. Mukhametzyanova, epic culture of the people, epic dastan, folkloristics, ethnoliterary studies, Tatar people.

Лилия Хатип кызы Мөхәммәтҗанованың Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында «Обычаи и традиции татарского народа» сериясендә рус телендә «Эпическая культура татар: дастаны» [Мөхәммәтҗанова, 2023] дип исемләнгән фәнни-популяр китабы дөнья күрде. Хезмәтнең фәнни тикшеренү объекты – татар халкының дастаннары. Эпос-дастаннарны барлау, эчтәлекләрен ачыклау, бәяләү белән бәйле гыйльми эш – тарих фәне, әдәбият һәм тел белемнәре белән бәйле киң кырлы хәбәрдарлык таләп итә торган өлкә. Һәм ул гуманитар

фәннәрнең берьюлы берничә тармагына мөрәҗәгать итеп эшләүне, шуңа күрә һәр әсәргә комплекслы анализ методикасын аңлап һәм белеп якын килүне сорый.

Эпик культураның өстенлеге шунда, ул шартлы укучы ролендәге дастан тыңлаучыны тормыш хакыйкатьләрен эпик киңлекләрне колачлап таный белергә өйрәтә, кешене иҗтимагый шәхес буларак тәрбияләүдә һәм үстерүдә төп рухи-мәдәни рольләрнең берсен башкара. Л.Х. Мөхәммәтҗанова моны ачык аңлап эш итүе сәбәпле, татар дастаннары һәм аларның төп үзенчәлекләре мәсьәләсен үзәккә куеп, өйрәнелү тарихларына да берникадәр тукталып, эчтәлекләрен аңлатуны алга чыгара. Халыклар тарихында һәм аларның рухи-мәдәни үсешендә дастаннар тоткан урынны язма һәм фольклор традицияләре бәйләнеше юнәлешендә билгеләү ягы да кызыклы эшләнелгән, автор тарафыннан шактый төгәл формалаштырылган үз методологик карашлары нигезенә корылган. Шуңа да әлеге фәнни-популяр хезмәтне, галимәнең башка фәнни әсәрләре янәшәсенә куеп, әдәбият белемендә һәм фольклористикада фундаменталь юнәлешләрнең берсе булган дөнья эпосы хакында игътибар ителерлек мәгълүматларны тудыруда һәм ныгытуда, өлгергән һәм җитеш хәлдә аларны халыкка җиткерүдә, милли эпосны башка халыкларның эпик иҗаты янәшәсенә куюда бер адым дияргә мөмкин. Китап милли эпосны хәтта бөтен дөнья масштабындагы эпослар белән бер дәрәҗәгә куеп популярлаштыру омтылышы буларак та кабул ителә.

Хезмәттә, фәнни-популяр кысаларга күчерелеп, авторның дастан дип аталган халык иҗаты жанрына бәйле гыйльми күзәтүләре һәм теоретик карашлары да урын ала. Китап ике бүлектән тора, күтәрелгән мәсьәләләр Л.Х. Мөхәммәтҗанованың башка фәнни мәкаләләре һәм монографияләрендәге белән аваздаш, укучы күңеленә барып җитәрлек хәлдә эзлекле ачылалар. Яңалыгы – авторның үз методологик карашларын бәян итүеннән, һәр мәсьәләгә шул нигездә якын килә белүеннән гыйбарәт. Керешнең фәнни-популяр китапларга хас структурага корылуы да дөрес. Татар халкында популярлашкан эпос-дастаннарга хас үзенчәлекләргә игътибар бирелү дә – хезмәтнең эчтәлеген билгеләүче төп факторларның берсе. Телдән башкарыла килгән дастаннарның, язма-китаби форматта теркәлеп, авторлык төсен ала баруын галимәнең жанр трансформациясе күренеше буларак тарихи үсеш шартларына бәйле тикшерүе һәм үзаң күтәрелешенә нисбәтле аңлатуы кызыклы һәм ышанычлы фәнни дәлилләр белән ныгытыла, аңлаешлы стильдә бәян ителә.

«Дастаны – хранители традиций народа» («Дастаннар – халык традицияләрен саклаучылар») дип исемләнгән беренче бүлек алты бүлекчәдән төзелгән. Авторның, эпосны өйрәнүдә дөньякүләм кабул ителгән гыйльми принципларны да исәпкә алып, милли эпик хәтеребез мәсьәләсенә иҗади якын килүе кызыклы, бу үзенчәлеге аңа хезмәтен фәнни-популяр юнәлешкә корырга мөмкинлек биргән.

«Татарский дастан и его главная особенность» («Татар дастаны һәм аның төп үзенчәлеге»), «От Поволжья до Сибири...» («Идел буеннан Себергәчә...»), «Сказитель дастанов или образ переписчика эпос-дастана» («Дастан сөйләүче яки эпос-дастанны күчерүче образы»), «Как найти границу между книжной и устной традицией в эпосе?» («Эпоста китаби һәм сөйләмә традицияләр аермасын ничек табарга?), «Место рукописных дастанов в татарском эпическом наследии» («Татар эпик мирасында кульязма дастаннарның урыны»), «Исторические пути формирования татарского эпоса» («Татар эпосы формалашуның тарихи юлы») – болар беренче бүлекнең бүлекчә исемнәре булып, эчтәлеген ачык күз алдына китерерлек итеп эшләнгәннәр. Аларда сүз татар эпосының барлыкка килүе, формалашуы һәм үсешендә гомуми эволюция хакында бара. Бүлек татар дастаннарының төп хасиятенә төшенергә, таралыш ареалын күзалларга ярдәм итә. Автор китаби дастаннарның традицион сөйләмә эпостан башлангыч алуын ассызыклый, язма төргә күчереп үстерелгән татар дастаннарын халыкның укымышлылык дәрәҗәсенә бәйле иҗат төре дип аңлата. Экспедиция вакытында илнең татарлар күпләп яши торган төбәкләрендә милли мәдәният вәкилләреннән үзе язып алган фактик материалларны да Л.Х. Мөхәммәтҗанова хезмәтендә уңышлы файдалана. Ясалган йомгак-нәтиҗәләре ышандыра. Китап берничә вариантлы татар дастаннары сюжетларын популярлаштыруга, иҗтимагый тормышта аларның ролен арттыруга да хезмәт итә.

Китапның «Дастаны в письменной эпической культуре татар: варианты, поэтика, фольклорные и литературные пласты» («Татар язма эпик мәдәниятендә дастан: вариантлар, шигърилек, халык иҗаты һәм әдәби катламнар») дигән икенче бүлегендә халкыбызның берничә дастаны анализ объекты итеп алына: җиде бүлекчәнең аерым һәркайсы «Идегәй», «Чура батыр», «Түләк китабы», «Күр углы», «Каһарман Катил», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Таһир белән Зөһрә» дастаннарына багышланган. Бүлекчәләрдә бу ядкярләргә эзлекле күзәтүләр уздырыла. Ул дастаннарда, бер яктан, гомумтөрки һәм дөнья халыклары эпик иҗатлары эчендә татар дастаннарының мәдәни дәрәҗәсе һәм урыны билгеләнә, икенче яктан, дастани мирасыбыз хакында гыйльми хәбәрләр фәнни-популяр телдә сөйләнелә, алар татар дастани мирасын популярлаштыруга хезмәт итә. Билгеле булганча, Түләк, Идегәй, Каһарман Катил, Чура батыр, Күр углы, Таһир-Зөһрә, Ләйлә-Мәҗнүн кебек каһарманлык һәм мәхәббәт үрнәкләрен бирүгә корылган сюжетларга иҗат ителгән дастан вариантлары татарларда элекке заманнарда күпләп тудырылган. Китапның бу бүлегендә әлеге дастаннарның барлыкка килү һәм таралу фактларына һәм шигъри үзенчәлекләренә мөнәсәбәтле мәсьәләләр кузгатыла, эчтәлекләрендә һәм үсешендә халык тарихына бәйле катламнарга игътибар юнәлтелә. Фольклор әсәрләренә хас үзенчәлекләрнең берсе – вариантлылык һәм бу хасият дастаннарга да карый.

Һәр бүлектә китапны кызыксынып укучыга темага муафыйк тәфсилле фикер җиткерелә, татарларның эпик культурасында төп рольне ислам дине уйнаган булуы ассызыклана. Автор, дини эчтәлектәге дастаннарга аерым игътибар биреп, аларны татар мәдәниятенә ислам йогынтысы нәтиҗәсендә формалашкан һәм үскән әсәрләр дип бәяли, бу төр милли дастаннарга карата булган кызыклы теоретик фикерләре белән уртаклаша, шул рәвешле татар эпосының ислам дини карашларыннан аерылгысыз икәнлегенә игътибарны юнәлтә. Әмма шунысы кызыклы, нугай татары булсын, себер, кырым, әстерхан татарымы – фольклорларында уртак мотивлар, темалар, каһарманнар, мәгънәләр, вакыйгалар шактый охшаш, бер үк канвада үстерелә, христиан диендәге керәшеннәрдә, яки яһүди динен тоткан татарларда башка икән дия алмыйбыз. Л.Х. Мөхәммәтҗанова эпос-дастаннарның китаби юнәлештә яшәешенең төп шартларыннан берсе итеп халыкның күп гасырлардан бирле ислам мәдәнияте йогынтысында яшәвен күрә, шул ук вакытта моны башка диннәрдәге татарларны исәпкә алмыйча аңлата. Аның карашынча, татар дастаннары исламга бәйле үзенчәлекле китаби үсеш кичергән. Мондый фикере белән, автор, бәлки, хаклыдыр да, әмма шул ук вакытта мәсьәләнең бу ягы, ягъни ислам кабул ителгәнчегә кадәр татар дастаннары торышы, әлегә өйрәнелмәгән. Ә бәлки, чыннан да, татар дастаннары, Л.Х. Мөхәммәтҗанова аңлатканча, Коръәнне көйләп укуга бәйле китаби үсеш алганнардыр? Исламнан читтәге шул ук керәшеннәрдә, мәсәлән, дастаннарның үсеш алмаган булуы да авторның шушы фикерен яклый.

«Татар эпик мәдәнияте: дастаннар» («Эпическая культура татар: дастаны») китабында башка юнәлештәге аргументлар да фәнни җәһәттән дә, гади укучы өчен дә кызыклы һәм фикер уятуга хезмәт итә. Китап татар дастаннарының язма мәдәнияттәге һәм гомумән дөнья цивилизациясендәге урынын һәм ролен ассызыклый, татар җәмәгатьчелегендә дастаннарга игътибарны арттыру кирәклеге мәсьәләсен дә куя. Автор әлеге хезмәтендә, нигездә, фольклордагы эпик һәм әдәбияттагы язма традицияләрнең үзара йогынтысы татар эпик мәдәниятенә ни рәвешле тәэсир итүне ачыклый һәм милли традицияләр кысасында татар дастанының ролен ача. Мәдәниятнең борынгы катламнарына, борынгы төрки эпосы һәм Урта гасырлар Көнчыгыш әдәбиятына ясалган экскурс уңышлы башкарылган.

Китапта татар дастаннарының башка төрки халыкларның эпик иҗат мирасыннан үзенчәлекле аермаларын барларга омтылыш күзәтелә. Моны татар фольклористикасының яңа баскычка күтәрелергә омтылышы дип бәялибез, алга таба да шушы зур белемнәр сорый торган юнәлеш көчәйтелер дип көтәбез, дәлилләр белән конкрет ачыклап күрсәтелгәндә, кызыклы ачышларга юлыгыр идек. Әлегә бу юнәлештә эшләнгән китапның гыйльми-практик әһәмияте шактый киң булып күренә, хәтта, әйтер идек, дөньяга этник караш мәсьәләләрен хәл иткәндә дә андагы карашларга нигезләнеп фикер йөртә алабыз.

Л.Х. Мөхәммәтҗанованың бу хезмәте дастаннарыбызны фольклорда, әдәбиятта, төрки һәм башка телле дөнья мәдәниятләрендә эпос жанрының бик әһәмиятле урын тотуын танытуы һәм татар эпик мәдәнияте чикләрен киңәйтүе белән кызыклы.

**Әдәбият**

*Мухаметзянова Л.Х.* Эпическая культура татар: дастаны. Казань: ИЯЛИ, 2023. 120 с.: ил. (серия «Обычаи и традиции татарского народа»).

***Яхин Фәрит Зәкиҗан улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

**2023 елның 3 октябрендә** Казанның Бауман урамында Татарстан Фәннәр академиясенең беренче президенты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Мансур Хәсән улы Хәсәнов истәлегенә мемориаль такта ачылды. Тантаналы чарада Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, министрлыклар һәм югары уку йортлары җитәкчеләре, Татарстан Республикасының танылган галимнәре һәм мәдәният эшлеклеләре катнашты. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов, Мансур Хәсән улының оештыру таланты һәм дәүләт структураларының актив ярдәме белән, Татарстан Фәннәр академиясенең республикабыз һәм Россия Федерациясе икътисади үсешенә зур өлеш кертүче фәнни оешмага әверелүен билгеләп узды.

**2023 елның 4 октябрендә** Уфа шәһәрендә М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогика университеты оештырган «Педагогик традицияләрнең дәвамлылыгы һәм туган тел һәм әдәбиятны укытуда алдынгы тәҗрибә» дип исемләнгән II Төбәкара фәнни-методик семинар узды. Ул Россия Федерациясендә билгеләнгән Укытучы һәм остаз елы һәм татар әдәбияты классигы Роберт Миңнуллинның тууына 75 ел тулуга багышланган иде. Семинар эшендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре дә катнашты. Чарада Мәскәү, Төмән шәһәрләреннән, Башкортстан һәм Татарстан республикалары шәһәрләре һәм районнарыннан фәнни хезмәткәрләр, укытучылар, студентлар, язучылар һәм җәмәгать эшлеклеләре чакырылган иде.

**2023 елның 5 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре онлайн-форматта «Тел. Шәхес. Мәдәният» («Язык. Личность. Культура») дип аталган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция эшендә катнашты. Чара И.Я. Яковлев исемендәге Чуваш дәүләт педагогия университеты (Чабаксар шәһәре) базасында узды. Конференция И.Я. Яковлевның тууына 175 ел тулуга һәм Чуваш дәүләт педагогия университетына галим исеме бирелүнең 65 еллыгына багышланган иде.

**2023 елның 15 октябрендә** Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музеенда ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан «Татарстан сәнгать белгечләре» сериясендә нәшер ителгән «Галина Аркадьевна Могильникова» китабы тәкъдим ителде. Чара XX гасырның икенче яртысында Татарстанның әйдәп баручы сәнгать белгече, республиканың атказанган мәдәният хезмәткәре Галина Могильникованың (1928–2001) тууына 95 ел тулуга багышланды. Басма турында кичәдә сәнгать белеме докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге мөдире Р.Р. Солтанова, хезмәтнең авторы – сәнгать белеме кандидаты И.Ф. Лобашева, сәнгать белеме кандидаты, Сәнгать белеме үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре О.Л. Улемнова сөйләде.

**2023 елның 17–19 октябрендә** Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «Европа цивилизациясенең язмачылык тарихы һәм Россия халыкларының язма мәдәнияте»

халыкара конференциясе узды. Конференцияне оештыручылар – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Россия Фәннәр академиясенең Санкт-Петербург Тарих институты, Россия Фәннәр академиясенең Рус әдәбияты институты (Пушкин йорты), Россия Фәннәр академиясе китапханәсе, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе. Халыкара фәнни конференциянең төп асылы Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм РФА Санкт-Петербург Тарих институты «Европа цивилизациясе язмачылык тарихы» интернет-порталының уртак проектын тәкъдим итүдән гыйбарәт иде. Конференция эше төрле юнәлешләргә бүлеп алып барылды, төрле секцияләрдә Казаннан, Россиянең башка шәһәрләреннән һәм чит илләрдән килгән галимнәр чыгыш ясады. Конференция кысаларында «Европа һәм Көнчыгыш цивилизациясенең язмачылык тарихы» күргәзмәсе оештырылды. Анда XV гасыр – XIX гасыр башы Россия һәм Көнбатыш Европа илләренең эш һәм китап язмачылыгы истәлекләре, XIII гасыр – XIX гасыр башына караган, гарәп графикалы дөньяви һәм дини характердагы кульъязма документлар, РФА СПбТИ Фәнни-тарихи архивында, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә, ТР ФА А. Халиков исемендәге Археология институтында, ТР Милли китапханәсендә сакланган сирәк кульъязмалар, нумизматика һәм эпиграфика раритетлары күрсәтелде. Күргәзмә ТР Милли китапханәсендә 2023 елның 15 декабренә кадәр эшләде.

**2023 елның 17–20 октябрендә** М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогика университетында Россиядә педагог һәм остаз елына багышланган «XXI гасырда фольклор һәм фольклористика: гамәли тикшеренүләрнең актуаль юнәлешләре һәм перспективалары» дип аталган II Халыкара фәнни-гамәли конференция үтте. Конференция эшендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәрләре Лилия Хатип кызы Мөхәммәтҗанова һәм Ләйлә Хәсән кызы Дәүләтшина катнашты, галимнәрнең видеочыгышлары татар фольклористикасының актуаль мәсьәләләренә багышланган иде.

**2023 елның 18 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Идел-Урал буе археологиясе» җидетомлыгы тәкъдим ителде. Бу басма – Евразия континентының әһәмиятле һәм уникаль тарихи-мәдәни өлкәләренең берсенә ярты гасырдан артык дәвам иткән археологик тикшеренүләр тәҗрибәсенә заманча академик караш. Басманы әзерләү 2016 елдан ук «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында башкарылды. Басманың авторлар коллективы составында 100 гә якын галим эшләгән, алар – Казан, Мәскәү, Уфа, Ижау, Самара, Йошкар-Ола, Чабаксар, Саранск, Әстерхан, Сыктывкар, Киров фәнни үзәкләреннән һәм югары уку йортларыннан әйдәп баручы археологлар. Презентацияне ТР Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов ачып җибәрде. Чарада шулай ук Венгриянең Казандагы Генераль консулы Сергей Сюч, Үзбәкстан Республикасының Казан шәһәрендәге Генераль консулы Насриев Фәриддин Бадриддин улы, Кытай Халык Республикасының Казандагы Генераль консуллыгы вице-генконсулы Хань Мин-юй, Цинь Сунмао Генераль консуллыгының икенче секретаре һәм Төркиянең

Казандагы Генераль консуллыгы вице-консулы Джанкат Шамил Оруч катнашты.

**2023 елның 19 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә аспирантлар чыгарылышына багышланган тантаналы чара узды. Алты әзерлек юнәлеше буенча 11 аспирант дәүләт йомгаклау аттестациясен уңышлы узды, аспирантураны тәмамлаучыларга «Тикшеренүче. Укытучы-тикшеренүче» квалификациясе бирелү турында дипломнар тапшырылды. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов аспирантураны тәмамлаучыларга сәламләү сүзе белән мөрәҗәгать итте, әлеге дипломның югары статусын билгеләп, кандидатлык диссертациясен яклауның алда торган иң мөһим бурыч булырга тиешлеген искәртте.

**2023 елның 19–26 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге хезмәткәрләре 2023 елгы эпиграфик экспедицияләр сезонын Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендәге мөселман зиратында кыр тикшеренүләре белән тәмамлады. Бу сәяхәт – әлеге каберлекне тулы күләмдә өйрәнүнең икенче этабы. Троицк шәһәре үзенең татар каберлеге белән данлыклы: анда XIX гасыр – XX гасыр башында Троицкида туып-үскән сәүдәгәрләр, галимнәр, дин әһелләре, һөнәрчеләр һ.б.га куелган берничә мең кабер ташы сакланып калган. Әлеге некропольнең үзенчәлеге – тарихи яктан файдалы мәгълүматка бай кабер ташлары булуда. Ун көн дәвам иткән әлеге кыр тикшеренүләре барышында Институт галимнәре Азат Ахунов һәм Венер Усманов тарафыннан 250 гә якын кабер ташы теркәлде һәм тасвирланды. Шулай ук элек билгеле булмаган таш кисүчеләрнең исемнәре дә ачыкланды.

**2023 елның 23–25 октябрендә** Бакуда ЮНЕСКО һәм Япония Траст фондының (Japan FiT) «Ефәк юлының Бөтендөнья мирасы номинациясе процессына ярдәм» (III Фаза) проекты кысаларында «Ефәк юлы: Идел-Каспий коридоры» беренче еллык субрегиональ конференциясе узды. Чара ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы үзәге һәм Халыкара Үзәк Азия тикшеренүләре институты (МИЦАИ, Сәмәрканд шәһәре), Азәрбайҗан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Азәрбайҗан Республикасының ЮНЕСКО каршындагы Даими вәкиллеге һәм Азәрбайҗан Республикасының ЮНЕСКО эшләре буенча Милли комиссиясе белән берлектә оештырылды. Конференциядә Россия, Казакъстан, Төркмәнстан, Англия, Япония, Иран вәкилләре катнашты. Конференциягә Татарстан Республикасыннан А.Х. Халиков исемендәге Археология институты директоры, тарих фәннәре докторы, ТР Фәннәр академиясе академигы Айрат Габит улы Ситдыйков вәкил булып барды. Киләчәк буыннар өчен «Ефәк юлы»ның мәдәни мирасын саклау һәм популярлаштыруда бу чараның әһәмияте гаять зур.

**2023 елның 24–26 октябрендә** Казанда VI Бөтенроссия татар журналистлары форумы узды. «Татмедиа» агентлыгы һәм Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан оештырылган әлеге мәртәбәле җыен Бөтендөнья татар конгрессында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев белән очрашудан башланды. Форумда татар газеталары һәм телевидениесенә

бәйле мәсьәләләр каралды, бергәләп эшләү юнәлешләре билгеләнде, ахырда «Хәбәр» дип аталган Бөтенроссия конкурсы нәтиҗәләре игълан ителде.

**2023 елның 25–27 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында чираттагы «Татар гыйлеме» халыкара яшьләр фәнни мәктәбе уздырылды. Ел саен уздырыла килә торган әлеге чара быел төрки халыкларның эпик мирасына багышланган иде. «Татар гыйлеме» халыкара яшьләр фәнни мәктәбен оештыруның максаты – фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү дәрәҗәсен күтәрү, талантлы яшьләрне фәнне үстерүнең өстенлекле юнәлешләренә караган фундаменталь фәнни тикшеренүләрдә катнашуга җәлеп итү, халыкара кооперация исәбенә фән һәм мәгарифнең дәрәҗәсен күтәрү һәм яшь галимнәрнең, аспирантларның һәм магистрантларның мобильлеген арттыру. «Татар гыйлеме» фәнни мәктәбендә әйдәп баручы галимнәрнең милли эпос проблемаларына кагылышлы фәнни докладлары, глобальләшү шартларында төрки халыкларның эпик мирасы потенциалын ачу һәм үстерү мәсьәләләре буенча лекцияләре һәм семинарлар тыңланды. Чарада, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казакъстан, Кыргызстан, Калмыкия республикалары, Мәскәү, Уфа галимнәре, Татарстан Республикасының фәнни һәм фән-мәгариф учреждениеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре һ.б. катнашты. Халыкара яшьләр фәнни мәктәбе эшенә йомгак ясап, 27 октябрьдә Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы К.М. Миңнуллин барлык катнашучыларга сертификатлар тапшырды.

**2023 елның 26 октябрендә** «Татар гыйлеме» халыкара яшьләр фәнни мәктәбе кысаларында Татарстан Фәннәр академиясендә ике күргәзмә оештырылды: Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты тарафыннан Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивында сакланган документлар нигезендә әзерләнгән «Идегәй» – татар халык дастаны» һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Б.М. Альменов иллюстрацияләре һәм аның исемендәге мәктәп укучылары рәсемнәреннән торган, татар дастаннарына багышланган «Дастан. Вакытлар һәм буыннар бәйләнеше» күргәзмәләре.

**2023 елның 26 октябрендә** Чиләбе өлкәсенең Миасс шәһәрендә XIX гасырның икенче яртысы күренекле төрки мәгърифәтчесе Мифтахетдин Акмулланың иҗади мирасына багышланган «Акмулла укулары» дип аталган өченче төбәкара конференция узды. Аның эшендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре дә катнашты. Чара Чиләбе өлкәсе Хөкүмәте ярдәме белән «Россия халыклары Ассамблеясы» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы һәм Чиләбе өлкәсе мөселманнарының төбәк Диния нәзарәте тарафыннан оештырылды. Татарстан галимнәре үз чыгышларында мәгърифәтче шагыйрьнең тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле төрле мәсьәләләрне күтәрде. ТӘһСИ галимнәре шулай ук Акмулла каберенә чәчәкләр салуда, шагыйрьне искә алу чарасында катнашты, «Блик» балалар-яшүсмерләр китапханәсенә Институтта дөнья күргән яңа китапларны тапшырды.

**2023 елның 27 октябрендә** Казанда Сара Садыйкова исемендәге

«Калфаклы сандугач-2023» татар җыры һәм музыка уен коралларының XII төбәкара ачык фестиваль-конкурсы узды. Фестиваль-конкурс 2004 елдан эшләп килә. Быел ул Россия Федерациясендә – «Укытучылар һәм остазлар елы», Татарстан Республикасында «Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы»на багышланып, «Гореф-гадәтләр аша – киләчәккә» девизы астында үтте. Фестивальдә, башкалабыздан тыш, республикабызның төрле районнарыннан, Чувашия Республикасыннан, Мәскәү шәһәреннән, Төркиядән вәкилләр катнашты. Бәйрәм С. Садыйкованың фестиваль гимнына әверелгән «Казан кичләре» җыры белән тәмамланды. Гран-прига Чувашия Республикасының Батыр районы балалар сәнгать мәктәбенең «Тамчы» уен кораллары ансамбле лаек булды.

**2023 елның 30–31 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган «Хәзерге дөньяда традицион мәдәниятне саклау һәм үстерү тәҗрибәсе. Халык кул сәнгатьләре» дип аталган II Халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Чарада Азәрбайҗан, Казакъстан, Үзбәкстан, Ижау, Йошкар-Ола, Саранск, Чабаксар, Уфа, Ярославль галимнәре, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, республиканың фәнни һәм белем бирү оешмалары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре һ.б. катнашты. Пленар утырышны Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы Ким Миңнуллин ачты. Техник фәннәр докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов үзенең сәламләү сүзендә республикада һәм Фәннәр академиясе институтларында халык сәнгатен саклау һәм үстерү юнәлешендә барган эшне ассызыклап, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган һәм үткәргән беренче конференциянең дә 2022 елда – Россия халыкларының мәдәни мирасы елында узуы очраклы булмавын билгеләп үтте. Конференциядә катнашучыларга сәламләү сүзе белән педагогика фәннәре докторы, профессор, Казан дәүләт мәдәният институты ректоры Роза Әхмәдиева; Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек бүлеге башлыгы Айрат Фәйзрахманов; Казакъстан һөнәрчеләр берлеге рәисе, Казакъстанның матди булмаган мәдәни мирасы буенча Милли комитет әгъзасы Айжан Беккулова, Россия Халык кул сәнгатьләре ассоциациясе рәисе Геннадий Дрожжин мөрәҗәгать итте. Пленар утырыштан соң, конференция үз эшен тукыма һәм чигү буенча мастер-классларда һәм секция утырышларында дәвам итте.

**2023 елның 30–31 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе бинасы фойесында «Хәзерге дөньяда Идел һәм Урал буе халыкларының традицион мәдәнияте» дип аталган күргәзмә эшләде. Анда «Хәзерге дөньяда традицион мәдәниятне саклау һәм үстерү тәҗрибәсе. Халык кул сәнгатьләре» дип аталган II Халыкара фәнни-гамәли конференциядә катнашучылар һәм кунаклар игътибарына Татарстан һәм Идел буе республикалары – Башкортстан, Чувашия, Мордовия һәм Марий Эл осталары ясаган костюм комплекслары һәм халык сәнгате эшләнмәләре тәкъдим ителгән иде, шулай ук тукыма һәм чигү буенча мастер-класслар уздырылды. 31 октябрьдә Татарстан

Республикасы Фәннәр академиясе Президиумы әгъзалары да экспозиция белән танышты.

**2023 елның 31 октябрендә** Башкортстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университеты, Татар федераль милли-мәдәни автономиясе иҗтимагый оешмасы, Башкортстан Республикасы татарларының милли-мәдәни автономиясе төбәк иҗтимагый оешмасы тарафыннан һәм Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык ярдәме белән Уфа шәһәрендә педагог һәм остаз елына багышланган «Мәдәниятләр диалогы контекстында милли тел: тикшеренү һәм укыту» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе оештырылды. Чарада дәүләт хакимияте органнары вәкилләре, фән һәм мәгариф оешмалары хезмәткәрләре, иҗтимагый-сәяси өлкәнең аерым тармакларыннан экспертлар, туган тел һәм әдәбият укытучылары катнашты. Конференция «Этносара диалог һәм гражданлык килешүен үстерүдә Россиянең милли-мәдәни автономияләре» программасы кысаларында узды. Конференциядә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты Гөлназ Мөхәрләмова туган тел (татар теле) һәм әдәбияттан яңа буын дәреслекләрдә мәдәниятләр диалогы принибының тормышка ашырылуы мәсьәләсенә багышланган чыгыш ясады.

**2023 елның 1 ноябрендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Төркиянең Казандагы генераль консуллыгы вице-консулы Җанкат Шамил Оруч белән очрашу узды. Фикер алышу барышында татар, төрек һәм башка төрки әдәби телләр, аларның үсеше мәсьәләләрен өйрәнүдә күп кенә уртаклыклар булуы билгеләп үтелде. Кунакны, аерым алганда, татар теленең тарихы, этимологиясе һәм лексикография мәсьәләләре кызыксындырды. Институтның гыйльми сәркатибе, филология фәнәре докторы Л.М. Гыйниятуллина, лексикография бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты Р.Т. Сәфәров һәм гомуми лингвистика бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Б.К. Миңнуллин әлеге юнәлешләр буенча тикшеренү эшчәнлеге турында сөйләделәр, галимнәренең хезмәтләре белән таныштырдылар. Җанкат Шамил Оруч Институт коллективына тикшеренү эшчәнлегендә уңышлар теләде һәм алга таба хезмәттәшлек итү теләген җиткерде.

**2023 елның 1 ноябрендә** Татарстан Милли китапханәсендә «Тинчуринның сигез фотоаппараты» дип исемләнгән күргәзмә ачылды. Биредә Кәрим Тинчурин үзе төшергән фотосурәтләр тәкъдим ителде. Чара К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының 90 еллыгына багышлап үткәрелде. Фотосурәтләрнең кайберләре киң җәмәгатьчелеккә беренче тапкыр тәкъдим ителде. Хәзерге вакытта әлеге экспонатлар К. Тинчурин театры архивында саклана. Зур кыйммәткә ия әлеге фотосурәтләрне театрга күренекле татар язучысы, җәмәгать эшлеклесе Рабит Батулла тапшырган. Ә аңа, үз чиратында, әлеге истәлекләрне Заһидә Тинчурина мирас итеп калдырган булган.

**2023 елның 3 ноябрендә** Санкт-Петербург шәһәрендә Россия Милли китапханәсенең яңа бинасында кыска гына гомере эчендә Көнчыгышны өйрәнүче (филолог һәм тарихчы), теолог һәм алдынгы мәгърифәтче буларак танылып

өлгергән Хөсәен Фәезхановка (1823–1866) багышланган күргәзмә ачылды. Экспозициянең үзәгендә – «Материалы по истории Крымского ханства» хезмәте, аны төзегән өчен Х. Фәизханов татар-мөселманнар арасыннан беренчеләрдән булып Император Рус Археология җәмгыяте әгъзасы итеп сайланган. Күргәзмәнең зур өлешен Х. Фәезхановның биографиясе һәм фәнни мирасы турында фәнни мәкаләләр, хезмәтләр (авторлары: Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин, Ә. Вәлиди һәм М. Усманов һ.б.) алып тора. Х. Фәезханов хезмәтләренең заманча басмалары «Мәдинә» нәшрият йорты тарафыннан, нәшриятның баш мөхәррире, теология докторы, профессор Дамир Мөхетдинов җитәкчелегендә әзерләнгән. Күргәзмәне нәшрият йорты коллекциясеннән Х. Фәизхановның фикердәшләре һәм замандашлары портретлары тулыландыра.

**2023 елның 3 ноябрендә** Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов Халыклар бердәмлеге көне кысаларында үткәрелгән Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елын ябу тантанасында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фән эшләре буенча урынбасары, ареаль лингвистика бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Олег Ришат улы Хисамовка күпьеллык нәтиҗәле фәнни-тикшеренү, педагогик эшчәнлеге һәм гуманитар фәннәрне үстерүгә лаеклы өлеш керткәне өчен Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәт хатын тапшырды.

Казан Экспо Халыкара күргәзмәләр үзәгендә узган шул ук чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге хезмәткәрләре – сәнгать фәннәре докторы, Үзәк мөдире Солтанова Рауза Рифкать кызы һәм сәнгать фәннәре кандидаты, өлкән фәнни хезмәткәр Шкляева Людмила Михайловна мәдәният үсешенә керткән өлешләре өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Мактау грамоталарына лаек булдылар. Хезмәттәшләребезне ихлас күңелдән котлыйбыз һәм яңа фәнни ачышлар, һөнәри казанышлар телибез!

**2023 елның 4 ноябрендә** Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы, доцент, «Фәнни Татарстан» журналының баш редактор урынбасары Лилия Хатип кызы Мөхәммәтҗановага «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән исем бирелү турындагы Указга кул куйды. Әлеге Указда бу дәрәҗәле исем аңа «күпьеллык нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге, татар халкының телен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә әһәмиятле өлеш кертүе өчен бирелә» диелгән. Хезмәттәшебез Лилия Хатип кызын чын күңелдән котлыйбыз, яңа фәнни уңышлар, һөнәри казанышлар телибез!

**2023 елның 5–8 ноябрендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре Нурия Гәрәева Казан делегациясе составында 5–8 ноябрьдә Сәмәркандта узган «Үзбәкстанның мәдәни мирасы – Яңарыш нигезе» дип аталган VII Халыкара конгресс эшендә катнашты. Форум кысаларында дөнья җыентыкларында үзбәк коллекцияләренә, сәнгатенә, кулъязма мирас үрнәкләренә, Үзәк Азия музейларына һәм китапханәләренә

багышланган конференцияләр эшләде. Конгресста «114 Коръән» эксклюзив проекты аеруча кызыксыну уятты. Н. Гәрәеваның доклады Казан коллекцияләрендәге Урта Азиядә күчерелгән кульязма Коръәннәргә багышланган иде.

**2023 елның 8 ноябрендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре – Сәнгать белеме үзәге мөдире, сәнгать фәннәре докторы Р.Р. Солтанова, халык иҗаты бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Л.Х. Дәүләтшина һәм Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәре Г.Г. Гыйлемҗанова танылган этномузыколог Эльмира Каюмова истәлегенә багышланган «Кыр этномузыкологиясенең актуаль проблемалары» дип аталган түгәрәк өстәл эшендә катнаштылар. Чара Россия Федерациясендә педагог һәм остаз елы кысаларында Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында узды. Анда күренекле фән һәм мәдәният эшлеклеләре, галимнәр, педагоглар Татарстанда этномузыкология үсеше, халык көйләрен җыю һәм өйрәнү, фольклор фондларын системалаштыру белән бәйле мәсьәләләр турында фикер алышты. ТӘһСИ хезмәткәрләре үзләренең чыгышларында шулай ук Э. Каюмованың эшчәнлеге турында истәлекләре белән уртаклаштылар, галимәнең хезмәтләренең бүгенге көн фәне өчен аерым кыйммәтен һәм аларны яңадан нәшер итү зарурлыгын билгеләп үттеләр.

**2023 елның 8 ноябрендә** легендар татар режиссёры Марсель Сәлимҗановның туган көнендә Камал театры сәхнәсеннән аның исемендәге премия лауреатлары игълан ителде. Премияне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов тапшырды. Агымдагы елда әлеге премиягә Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфиев, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, драматург Мансур Гыйләҗев һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, драматург, режиссёр Илгиз Зәйниев лаек булды. Республика театр сәнгате өлкәсендәге әлеге премия 2014 елда гамәлгә куелган. Ул 2 елга бер тапкыр 3 кешегә бирелә. Быел ул бишенче тапкыр тапшырылды.

**2023 елның 9 ноябрендә** Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә язучы Нурихан Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романы буенча ясалган рәсем күргәзмәсе ачылды. Әлеге күргәзмә әдипнең тууына 95 ел тулуга багышланган. Күргәзмә авторы – рәссам Руслан Ибраһим. Рәссамның картиналары Казакъстан шәһәрләре буйлап сәяхәт кылды һәм 25 октябрь көнне язучының юбилей кичәсендә Г. Тукайның Казандагы әдәби музеенда бер көнлек күргәзмәгә куелды. Сурәтләр рәссамның шәхси стилендә акрил белән эшләнгән. ТР Милли китапханәнәсендә ачылган күргәзмәдә «Алпар» төркеме милли музыка инструментларында уйнады, төрки рун язуы, татарларның борынгы тарихына багышланган лекция һәм мастер-класслар оештырылды. Күргәзмә ноябрь ахырына кадәр эшләде.

**2023 елның 9 ноябрендә** Казакъстан Республикасы Семей шәһәрендә Советлар Союзы Герое,

шагыйрь Муса Җәлил бюстын ачу тантанасы узды. Чарада Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев катнашты.

**2023 елның 11 ноябрендә** Мәскәүнең Татар мәдәни үзәгендә Роберт Миңнуллинның тууына 75 ел тулу уңаеннан «Яшәргә икән, яшәргә» дип аталган җырлы-шигъри кичә узды. Бу хакта Мәскәү шәһәре Татар милли-мәдәни автономиясе төбәк иҗтимагый оешмасының матбугат хезмәте хәбәр итте. Концерт программасында Татар мәдәни үзәге артистлары башкаруында «Әнкәмнең догалары», «Соңдыр шул, соңдыр», «Ак каеннар арасында», «Кайтабыз да китәбез шул» һәм башка җырлар яңгырады. Чараның координаторы – Россиянең атказанган артисты Илдар Шиһапов.

**2023 елның 12–14 ноябрендә** Казанда «Тәрбия. Белем. Тел» шигаре астында I Бөтенроссия «Туган тел» форумы узды. Форум Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан оештырылган иде. Чарада Россия Федерациясенең 30 төбәгеннән һәм Татарстан Республикасыннан барлыгы 800 кеше – татар теле һәм әдәбияты укытучылары, милли мәгариф өчен җаваплы методистлар, татар теле белеме, татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы өлкәсендәге галимнәр, дәреслек авторлары, иҗтимагый оешма җитәкчеләре катнашты. Форум агымдагы елда оештырылган Бөтенроссия татар теле укытучылары ассоциациясенең беренче җыелышы буларак үтте. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре дә Институт директоры, филология фәннәре докторы К.М. Миңнуллин җитәкчелегендә Бөтенроссия «Туган тел» форумында катнаштылар.

14 ноябрь көнне «Корстон» сәүдә-күңел ачу үзәгендә Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов катнашында форумның пленар утырышы узды. Утырышны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев алып барды. Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов форум делегатларын сәламләде. Утырыш кысаларында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты эшчәнлеге дә тәкъдим ителде. Экспозициядә татар теле һәм әдәбияты буенча яңа буын укыту-методик комплекслары, Институтның электрон проектлары, «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясеннән фәнни-популяр басмалар урын алды һәм форумда катнашучыларда зур кызыксыныну уятты.

**2023 елның 13–15 ноябрендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәрләре – сәнгать белеме кандидаты Н.В. Герасимова һәм А.К. Җәләлиева Царицыно дәүләт музей-тыюлыгында (Мәскәү) узган IV Халыкара Андреев фәнни укулары эшендә катнашты. Быелгы традицион Укулар халык сәнгатенә һәм аны популярлаштыру тәҗрибәсенә багышланган иде. Чарада Россиянең төрле төбәкләреннән һәм күрше дәүләтләр – Белоруссия, Азәрбайҗан, Кыргыз Республикасы, Үзбәкстан һәм Таҗикстан белгечләре һәм галимнәре тарафыннан кырыкка якын доклад укылды. Н.В. Герасимованың Төмән өлкәсенә экспедицияләр барышында җыелган материалларга нигезләнгән доклады Себер татарлары халык сәнгатенең

хәзерге торышына багышланган иде. А.К. Җәләлиева үз чыгышында Татарстанның заманча сәнгать керамикасы үзенчәлекләре турында сөйләде.

**2023 елның 15 ноябрендә** Казандагы Татар китабы йортында «Шәхесләребез» сериясендә дөнья күргән «Шәриф Камал» китабын тәкъдим итү чарасы узды. Анда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге хезмәткәрләре дә катнашты. Чараны Татар әдәбияты тарихы музее һәм Шәриф Камал мемориаль фатиры (Татар китабы йорты) җитәкчесе, китапны төзүчеләрнең берсе Айдар Шәйхин ачып җибәрде. Әлеге китапның фәнни концепциясен филология фәннәре докторы, академик Дания Заһидуллина эшләгән (кереш мәкалә авторы да ул). Д. Заһидуллина үзенең чыгышында XX гасыр башы татар әдәбиятында сыйфат үзгәрешләренә нигез салган Ш. Камал иҗатын яңа фәнни нигезләрдә өйрәнү кирәклегенә басым ясап, истәлекләргә, документларга, хатларга, фоторәсемнәргә бай әлеге җыентыкның шуңа хезмәт итүен ассызыклады. Чарада шулай ук филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов та катнашты.

**2023 елның 21 ноябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты М.М. Шәкүрова күренекле татар филологы, педагог, Хезмәт Герое Мөхетдин Корбангалиевнең (1873–1941) тууына 150 ел тулу уңаеннан оештырылган «Хәрефләр әфсенләүче» дигән күргәзмәдә һәм түгәрәк өстәлдә катнашты. Чараны Татар әдәбияты тарихы музее һәм Шәриф Камалның мемориаль фатиры (Татар китабы йорты) директоры Айдар Шәйхин ачып җибәрде. Профессор М.Х. Корбангалиевнең яңа фоторәсемнәре, документлары, кулъязмалары урын алган күргәзмә чарада катнашучыларда зур кызыксыну уятты. Күргәзмәне ачу тантанасында белгечләр генә түгел, ә бу атаклы гаиләнең нәсел дәвамчылары да чыгыш ясады.

**2023 елның 22 ноябрендә** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Э.И. Сафина Россиядә сүзлекләр көне уңаеннан Яр Чаллы шәһәренең 52 нче урта гомуми белем бирү мәктәбендә оештырылган «Телебез җәүһәрләре» исемле чарада катнашты. Мәктәп укучылары, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханәчеләр, вакытлы матбугат хезмәткәрләре, журналистлар, Язучылар берлеге әгъзалары катнашындагы әлеге чарада Эльвира Сафина Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлегендә төзелгән сүзлекләр, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең TATZET платформасында урнашкан сүзлекләрнең электрон фонды турында сөйләде. Татар теленең 6 томлык аңлатмалы сүзлеге һәм башка төр сүзлекләр, электрон фонд турындагы презентация һәм соңгы елларда басылып чыккан сүзлекләрне туплаган күргәзмә чарада катнашучыларда зур кызыксыну уятты.

**2023 елның 23 ноябрендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге җитәкчесе Э.М. Галимҗанова, бүлекнең фәнни хезмәт-

кәрләре Ә.Х. Алиева һәм Ф.Г. Фәйзуллина Яр Чаллы шәһәренең Үзәк китапханәсендә уздырылган чарада катнаштылар. 2023 ел Укытучылар һәм остазлар елы булуын исәпкә алып, биредә укытучылар, Яр Чаллы педагогика институты студентлары, китапханәчеләр һәм, гомумән, татар җәмәгатьчелеге вәкилләре белән очрашу оештырылды. Чарада татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакыйның тууына 145 ел тулу уңаеннан дөнья күргән «Гаяз Исхакый. Көндәлекләр»нең беренче китабы тәкъдим ителде, Институтның төп эшчәнлеге, аерым бүлекләрнең эш үзенчәлекләре, зур фәнни проектлар турында сүз барды. Чарада катнашучылар Институт хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнеп нәшер ителгән китаплар белән таныштылар. Әлеге басмаларның бер өлеше Яр Чаллы шәһәрендәге китапханә фондларына бүләк ителде.

**2023 елның 22–23 ноябрендә** ТӘһСИнең Сәнгать белеме үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Айгөл Салихова «А.Н. Островский. Талант һәм социум» дип аталган Халыкара фәнни конференция эшендә катнашты, «А. Островский әсәрләре Марсель Сәлимҗанов интерпретациясендә» дигән темага доклад белән чыгыш ясады. А.Н. Островскийның тууына 200 ел тулуга багышланган әлеге чара Мәскәүдә «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында узды. Конференциядә А.Н. Островский пьесаларына мөнәсәбәтле сәхнәдә милли һәм дөнья театры традицияләренең бәйләнешенә кагылышлы фәнни проблемалар турында фикер алышу оештырылды.

**2023 елның 22 ноябрендә** РИНЦ 2022 ел өчен фәнни журналлар рейтингын бастырды (https://www.elibrary.ru/titles_compare.asp). Рейтинг нәтиҗәләреннән күренгәнчә, «Поволжская археология» («Идел буе археологиясе») журналы иң яхшы журналлар рәтенә керә, «Тарих. Тарих фәннәре» рейтингында 6 нчы урынны били. Археология буенча ватан басмалары арасында бу журнал 4 урында тора. Журнал Scopus мәгълүмат базасында индексацияләнә һәм «РФА журналларының ак исемлеге»нә кертелгән. Ул РФ ВАК исемлегендә һәм RSCI рейтингында журнал К1 категориясенә керә.

**2023 елның 24 ноябрендә** Габдулла Тукайның Казандагы әдәби музеенда язучы, журналист һәм тәрҗемәче Әхмәтгәрәй Хәсәнинең тууына 140, аның тормыш иптәше, «Аң» журналының җаваплы сәркатибе Зәйнәп Хәсәниянең тууына 135 ел тулуга багышланган әдәбимузыкаль кичә узды. Чарада Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре катнашты. Әдәбият бүлеге баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы, профессор Дания Фатих кызы Заһидуллина һәм Язма мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Ләйсән Рәдиф кызы Надыршина, чыгыш ясап, Хәсәниләрнең XX йөз башы мәдәни тормышындагы роле, алар нәшер иткән «Аң» журналының татар әдәбияты һәм журналистикасы үсешенә керткән өлеше һ.б. турында сөйләделәр, институтта сакланган, Хәсәниләр белән бәйле ядкярләр турында мәгълүмат бирделәр.

**2023 елның 24–27 ноябрендә** Казанда Татарстан Республикасы җитәкчелеге ярдәмендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе башлангычы белән «Дала Евразиясе халыклары тарихы һәм мәдәниятенең актуаль проблемалары» дигән

темага халыкара түгәрәк өстәл оештырылды. Ул Дала Евразиясе халыкларының һәм илләренең тарихи-мәдәни мирасы барлыкка килүенең уртак проблемаларын эксперт дәрәҗәсендә карауга багышланды. Түгәрәк өстәл эшендә Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Владивосток, Уфа, Әстерхан, Йошкар-Ола шәһәрләре фәнни һәм фәнни-мәгариф үзәкләреннән, шулай ук Монголия (Улан-Батор шәһәре), Казакъстан (Алмата шәһәре), Азәрбайҗан (Баку шәһәре), Кытай (Пекин шәһәре), Үзбәкстаннан (Сәмәрканд шәһәре) 60 тан артык әйдәп баручы галим, шулай ук Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең фәнни хезмәткәрләре, аспирантлар катнашты. Әлеге халыкара чарада катнашучыларны Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Р.Н. Миңнеханов һәм «Ватан тарихы» фонды башкарма директоры Р.Г. Гагкуев сәламләде.

**2023 елның 26 ноябрендә** Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясендә танылган шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Роберт Миңнуллинның тууына 75 ел тулуга багышланган кичә узды. Анда Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты. Кичәдә балалар һәм яшьләр арасында шагыйрь истәлегенә уздырылган конкурска нәтиҗә ясалды. Бәйгедә катнашкан 135 кеше арасыннан 12 җиңүче билгеләнде.

**2023 елның 26–27 ноябрендә** Азәрбайҗанда Татарстан делегациясе катнашында Татар мәгарифе көннәре узды. Делегация составына Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре, Казан федераль университеты, Татарстан Мәгариф үсеше институты галимнәре, Казанның мәгариф оешмалары җитәкчеләре керде. Татар мәгарифе көннәре кысаларында Татарстанның Азәрбайҗандагы Даими вәкиллеге базасында Каюм Насыйри исемендәге белем бирү-мәдәни үзәге ачылды. Яңа ачылган үзәктә укытучылар, укучылар, студентлар һәм Баку шәһәре татар диаспорасы вәкилләре катнашында мәдәни программа оештырылды. Очрашуларда мәгариф өлкәсендә тәҗрибә уртаклаштылар. Мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин Татарстандагы мәгариф системасы белән таныштырды, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов югары белем бирү өлкәсендә Азәрбайҗан Республикасы белән хезмәттәшлек турында сөйләде. Шулай ук Татарстанның Азәрбайҗандагы вәкиле Морат Гаделшин белән очрашу булды. Аның сүзләренчә, Азәрбайҗан Республикасында Татар мәгарифе көннәрен үткәрү башкарма хакимият органнары вәкилләре, педагоглар һәм җәмәгатьчелек лидерлары арасында мәгариф, мәдәни һәм милләтара элемтәләрне ныгыту өчен нәтиҗәле мәйданчык булды.

**2023 елның 28 ноябрендә** Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына тәҗрибә уртаклашу максаты белән Хакасия Республикасыннан галимнәр килде. Хакасия тел, әдәбият һәм тарих фәнни тикшеренү институтының тел секторы мөдире, филология фәннәре кандидаты Ирина Максимовна Чебочакова һәм тел секторының өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Вия Васильева Субракова ТӘһСИ эшчәнлеге, соңгы елларда басылып чыккан фәнни хезмәтләр белән таныштылар. Галимнәрне аеруча сүзлекләр төзү практикасы кызыксындыра, шул сәбәпле алар Институтның лексикография бүлеге хезмәткәрләре белән уртак эш ту-

рында киңәшергә, консультацияләр алырга планлаштыра. Эш барышында лексикография бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты Ринат Таһир улы Сәфәров кунакларны яңа сүзлекләр һәм сүзлекләрнең электрон фонды белән якыннан таныштырды. Әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, филология фәннәре кандидаты Фәридә Инсан кызы Таһирова терминология белән эш итү, яңа сүзләр һәм аларны сүзлекләрдә чагылдыру, орфография һәм язуны нормалаштыру проблемаларының татар телендә хәл итү юллары турында сөйләде.

**2023 елның 28–29 ноябрендә** Россия Дәүләт сәнгать китапханәсендә (Мәскәү) узган Унөченче «Күпмилләтле мәдәният контекстында милли театр» исемле традицион Михоэлс укуларында сәнгать фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге мөдире Рауза Солтанова татар театрының беренче профессиональ рәссамы П.П. Беньковка (1879–1949) багышланган доклад белән чыгыш ясады. «Күпмилләтле мәдәният контекстында милли театр» – бүгенге көндә проблематикасы, бер яктан, – турыдан-туры сәнгать белеме, театр тарихы, культурология һәм башка гуманитар дисциплиналар, икенче яктан, чыганак ресурслары, коллекцияләр, архивлар белән бәйле бердәнбер халыкара фәнни форум. Традиция буенча, Укулар ике елга бер тапкыр үткәрелә. Әлеге укулар кысаларында «Оскар Марикс – белорус сценографиясенә нигез салучы» дип аталган күргәзмә дә ачылды.

**2023 елның 29 ноябрендә** КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында язучылар Аяз Гыйләҗев һәм Арпад Галгоциның тууына 95 ел тулуга багышланган «Халыклар күңеленә үтеп керик!» кичәсе булды. Ул Казан федераль университеты, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр фәнни белем бирү үзәге ярдәме белән оештырылды. Кичәне КФУ доценты, әдәбият галиме Миләүшә Хәбетдинова алып барды. Чарада «Аяз Гыйләҗев» (Казан: Җыен, 2023), Аяз Гилязов «В чьих руках топор?» (Казань: Татар. кн. изд-во, 2023), Galgóczy K. «Galgóczy Árpád» (Будапешт, 2023) китаплары тәкъдим ителде, Аяз Гыйләҗевның гаилә архивыннан фотосурәтләр күргәзмәсе ачылды. Кичәдә Аяз Гыйләҗевның улы Искәндәр Гыйләҗев, Арпад Галгоциның хатыны Каталин Галгоци, Хатыйп Миңнегулов, Фоат Галимуллин, Әлфәт Закирҗанов һ.б. галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре чыгыш ясады. Халыкара бәйгеләр лауреаты, җырчы Рөстәм Насыйбуллин җырларын бүләк итте.

**2023 елның 29 ноябрендә** классик язучы Гадел Кутуйның 120 еллыгы уңаеннан, ул яшәгән йортта (Мөштәри урамы, 33 йорт) яңартылган истәлек тактасы ачылды. Чарада Гадел Кутуйның оныгының кызы Диана Нурисламова да катнашты. Ул Гадел Кутуйның тууына 120 ел тулу уңаеннан документаль фильм төшереләчәген әйтте.

**2023 елның 30 ноябрендә** Мәскәүдә, Россия язучылар һәм нәшриятчылар берлекләре ассоциациясендә «Иң күп укучы төбәк-2023» Бөтенроссия конкурсының бүләкләү тантанасы узды. Әлеге конкурста Татарстан Республикасы җиңүче дип танылды. Россия китап берлеге президенты Сергей Степашин

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәевка конкурсның төп бүләген тапшырды. Тантаналы чарада Татарстан Республикасы Мәдәният министрының беренче урынбасары Юлия Адамова, Татар китап нәшрияты генераль директоры Илдар Сәгъдәтшин һәм Роберт Миңнуллин исемендәге Республика балалар китапханәсе директоры Ирина Мөхәммәтгәрәева катнашты. Жюри һәм конкурсны оештыручылар Татарстанның Роберт Миңнуллин исемендәге Республика балалар китапханәсен «Күчмә китапханә» проекты өчен бүләкләде.

**2023 елның 4 декабрендә** филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фән буенча урынбасары Олег Хисамов «Вәлиев укулары» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясендә Идел-Урал һәм Себер татарларының тел тәңгәллегенә багышланган доклад белән чыгыш ясады. Танылган тарихчы һәм археограф, тарих фәннәре докторы Фоат Тач-Әхмәт улы Вәлиевнең тууына 105 ел тулуга багышланган әлеге чара 2023 елның 1–2 декабрендә Тубыл шәһәрендә узды. Конференциядә Ф.Т. Вәлиев һәм аның Себер татарларын өйрәнүгә кerткән өлеше, Себер татарларының этногенезы проблемалары, Көнбатыш Себер төрки халыкларының матди һәм рухи мәдәнияте, җирле татар торак пунктлары тарихы һ.б. темалар буенча фикер алышу оештырылды.

**2023 елның 6 декабрендә** Санкт-Петербургның Татар мәдәни үзәгендә татар шагыйре, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилгә багышланган иҗат кичәсе узды. Ул «Җәлил укулары» VI Халыкара әдәби конкурсы һәм «Татар кунак йорты» мәдәни-агарту проекты кысаларында оештырылды. Аны Татарстанның Санкт-Петербург шәһәрендәге һәм Ленинград өлкәсендәге Даими вәкиллеге үткәрде. Быел конкурс көндезге һәм дистанцион форматларда үткәрелде һәм катнашучыларның бер өлеше конкурсның киләсе этабына Казан шәһәренә җибәрелде. Яшь укучылар һәм «Җәлил укуларында» даими катнашучылар шигырьләрне татар һәм рус телләрендә укыды. Кунакларга алар башкаруында җыр-биюләр дә тәкъдим ителде. Чара азагында конкурста катнашучыларга Татарстанның Санкт-Петербург шәһәрендәге һәм Ленинград өлкәсендәге Даими вәкиленең Рәхмәт хатлары тапшырылды.

**2023 елның 6 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының 5 нче гимназиясе базасында туган тел һәм әдәбият укытучылары өчен «Яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру шартларында туган телне (татар телен) һәм әдәбиятны яңа УМКлар нигезендә укыту» проблемасы буенча төбәкара семинар кысаларында узган дәресләрне карадылар. Семинарны оештыручыларның берсе – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. Чарада Татарстан Республикасы Яшел Үзән районының туган татар теле һәм әдәбияты укытучылары катнашты, шулай ук семинар эшенә Курган өлкәсенең Шадрин һәм Шатров районнары педагоглары онлайн форматта кушыл-

ды. Семинарның максаты – ФДББС таләпләрен тормышка ашыруда гомуми белем бирү оешмаларының инновацион тәҗрибәсен үзләштерү. Дәресләр ТӘһСИдә эшләнгән УМКларны кулланып үткәрелде. Түгәрәк өстәл кысаларында дәресләргә уңай бәя бирелеп, җентекле анализ ясалды, шулай ук бердәм белем бирү киңлеген формалаштыру шартларында туган телләрне өйрәтү системасындагы үзгәрешләргә бәйле мәсьәләләр турында фикер алышу узды.

**2023 елның 11 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К.М. Миңнуллин Татарстанның халык шагыйре, Башкортстанның атказанган мәдәният эшлеклесе Роберт Миңнуллинның 75 еллыгына багышланган «Курай булып кайтырмын...» дип исемләнгән Төбәкара түгәрәк өстәл эшендә катнашты. Чара күрше республиканың Язучылар берлеге тарафыннан Милли әдәби музей һәм Әхмәт-Зәки Вәлиди исемендәге Милли китапханә белән берлектә оештырылган иде. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең соңгы елларда нәшер ителгән 100 дән артык исемдәге хезмәте Башкортстан Республикасының Әхмәт-Зәки Вәлиди исемендәге Милли китапханәсенә бүләк итеп тапшырылды.

Сәфәр барышында К.М. Миңнуллин шулай ук Россия Фәннәр академиясе Уфа федераль тикшеренү үзәгенең Тарих, тел һәм әдәбият институты директоры Зөһрә Рәхмәтуллина белән очрашты. Алар Татарстан һәм Башкортстан Фәннәр академияләре хезмәттәшлеге кысаларында уртак проектларны гамәлгә ашыру турында фикер алыштылар.

**2023 елның 11–14 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре – әдәбият белеме бүлеге баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Д.Ф. Заһидуллина һәм чагыштырма татар белеме лабораториясе мөдире, филология фәннәре кандидаты М.И. Ибраһимов Кыргызстан Республикасы Мәдәният, мәгълүмат, спорт һәм яшьләр сәясәте министрлыгы чакыруы буенча Кыргызстан Республикасы башкаласы Бишкәк шәһәрендә мәшһүр язучы, җәмәгать эшлеклесе, дипломат Чыңгыз Төрекул улы Айтматовның тууына 95 ел тулуга багышланган «Без бер көймәдәбез: Чыңгыз Айтматовның рус телендәге иҗаты» дип исемләнгән Халыкара форумда катнаштылар.

Форумда Россия, Азәрбайҗан, Беларусь, Казакъстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан һ.б. илләрдән 40 лап галим, сәнгать әһелләре чакырылган иде. Чараларда язучының сеңлесе Роза Айтматова, туганнары һәм оныклары да катнашты. Форум Чыңгыз һәм Төрекул Айтматовлар җирләнгән Ата Бейит зиратында чәчәк салудан һәм Токтогул Сатылганов исемендәге Милли филармониядә чараның ачылышыннан башланып китте. Татарстан делегациясе «Чыңгыз Айтматов иҗаты һәм совет чорының төрки телле әдәбиятлары: кануннан арыну», «Чыңгыз Айтматов һәм әдәбиятларны чагыштырма өйрәнү» дип исемләнгән ике доклад тәкъдим итте, моннан тыш Форум кысаларында, шулай ук Кыргызстан Республикасының Дәүләт тарих музеенда һәм Кыргызстан Республикасының Алыкул Осмонов исемендәге Милли китапханәсендә Чыңгыз Айтматовның әнисе ягыннан нәселе, Татарстан Республикасында Чыңгыз Айтматов иҗатын популярлаштыру буенча

алып барылган эшләр хакында чыгышлар ясалды. Галимнәр Нәгыймә ханымның каберенә бардылар.

**2023 елның 12 декабрендә** Казанда «Милли хәзинә» балалар һәм яшьләр өчен халык иҗаты фестивале гала-концертында җиңүчеләрне бүләкләделәр. Фестиваль Казан федераль университеты һәм Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән берлектә оештырылган иде. 9–11 сыйныф укучылары һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары студентлары арасында иҗади эш бәйгесендә җиңүчеләр нәфис сүз, яшь язучы, яшь журналист, җыр, инструменталь башкару, хореография, вокаль һәм уен кораллары ансамбле, вокаль һәм хореография ансамбле, мода театры, декоратив-гамәли иҗат, мәгълүмат мохите дизайны, реклама һәм нәшрият эше, рәсем, театр, педагогик эссе, тәрҗемә номинацияләрендә бүләкләнделәр.

**2023 елның 13 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында танылган язучы Чыңгыз Айтматовның тууына 95 ел тулуны билгеләп үтү чараларының республика планы кысаларында «Чыңгыз Айтматов иҗаты – төрки халыкларны бәйләп торган мирас» темасына түгәрәк өстәл үткәрелде. Чарада чорның тарихи-мәдәни һәм иҗтимагый-сәяси яссылыгында Ч. Айтматовның шәхесе, язмышы һәм иҗаты; Ч. Айтматов һәм төрки дөнья: әдәби-мәдәни һәм тел аспектлары; Ч. Айтматовның Россия һәм дөнья рухи мәдәниятен үстерүгә керткән өлеше; Ч. Айтматов мирасын популярлаштыру, саклау һәм мәңгеләштерү мәсьәләләре каралды. Түгәрәк өстәлдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнгән, Кыргызстанда яшәүче татарларның тарихын һәм мәдәниятен яктырткан түбәндәге хезмәтләр дә тәкъдим ителде: 1) Бикбулатова А.Р., Абдрахманов Б.Дж. Политические репрессии в Кыргызстане: судьбы татар. Казань: ИЯЛИ, 2022. 300 с; 2) Кубатова А.Э. Татарское просветительство и реформаторское движение в Кыргызстане (конец XIX – нач. XX в.). Казань: ИЯЛИ, 2022. 256 с.

**2023 елның 15 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты танылган прозаик, драматург Шамил Усмановның тууына 125 ел тулуга багышланган «1920–1930 еллар татар әдәбиятында Шамил Усманов иҗаты» дип аталган түгәрәк өстәл утырышын оештырды. Фикер алышуга түбәндәге сораулар чыгарылган иде: Ш. Усмановның тормышы һәм күпкырлы эшчәнлеге; татар совет әдәбияты һәм Ш. Усманов прозасы; 1920–1930 еллар татар драматургиясен үстерүдә Ш. Усманов иҗатының роле; 1920–1930 елларда илдә сәяси-иҗтимагый һәм мәдәни мохит һәм репрессияләр; Ш. Усманов шәхесе һәм иҗаты әдәбиятта һәм сәнгатьтә; Ш. Усманов иҗатын өйрәнүнең торышы һәм бурычлар.

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

– авторның фамилиясе, инициаллары
– мәкалә исеме (татар һәм рус телендә)
– аннотация (рус һәм инглиз телендә)
– төп сүзләр (рус һәм инглиз телендә)
– сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12, 1 нче кат, 10 нчы бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек*
*итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2023. № 4

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 26.12.2023. Басылды: 09.01.2024.
Офсет кәгазе. Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Гарнитура «Times».
Басма табак 12. Тираж 300 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
нәшриятында басылды
(нәшрият адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал бушлай таратыла